# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2023 1 (37)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «2023–2030 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программалары кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т.,
СӘЛАХОВА Ә.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

## БУ САНДА


### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Мирхәев Р.Ф.* Татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә топонимнарның стилистик кулланылышы *(хоронимнар һәм ойконимнар мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . 7

*Сабитова И.И.* Румын татарлары авыз иҗатында сомокомпонентлы паремия һәм фразеологизмнар . . . . . . . . . . 15

*Булатова Ә.К.* Диалекталь сүзләрнең этимологиясе *(Чувашия Республикасына комплекслы экспедиция вакытында теркәлгән лексик берәмлекләр мисалында)* . . . . . . . . . . . . . 24

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Шәрипов Ә.М.* Сирин иҗатында 1930 еллар совет чынбарлыгы чагылышы *(дәвамы)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29

*Сафиуллина Р.Ф.* «Ибраһим Әдһәм» дастанының татар һәм төрек версияләрендә дини-суфичыл әдәбият идеяләре . 45

*Надыршина Л.Р.* XX йөзнең 90 нчы елларында татар поэмасының үсеш юллары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54

### ГАЯЗ ИСХАКЫЙГА – 145

*Фәйзуллина Ф.Г., Ханнанова Г.М.* Гаяз Исхакый көндәлекләре буйлап мәдәни сәяхәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Брусько З.М.* Татар халкының традицион күзаллауларында авырлы хатын образы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74

*Фазлетдинов И.И.* Башкортстандагы татар авылларына нигез салыну турындагы риваятьләр: тарихи аспект . . . . . . . . 83

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Тычинских З.Ә.* XVI–XVIII гасырларда Көнбатыш Себернең мөселман элитасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93

### СӘНГАТЬ

*Шевченко Е.Н.* Шиллерның «Юлбасарлар»ы татар сәхнәсендә . 107

### ФӘЛСӘФӘ

*Булатова Д.С.* «Миф», «эпос», «тарих» төшенчәләренең үзара бәйләнеше турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115

### ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

*Юсупова Н.М.* Азәрбайҗан шагыйре Әләскәр иҗаты һәм төрки шигърияттә «гыйшык әдәбияты» традицияләре . . . . 122

*Хөббитдинова Н.Ә.* Башкорт әдәбиятында фольклор интертексты мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

**ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР**

*Гази Кашшаф*. Ибрай Гази иҗаты. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Йосыпов Ф.Й.* В.В. Радловның Казан чоры фәнни, педагогик эшчәнлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143

*Мортазина Л.Р.* Галимәтелбәнат Биктимерия – мәгърифәтче һәм педагог . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Хуҗин Ф.Ш.* Борынгы бабаларыбыз нинди телдә сөйләшкән? *Профессор Марсель Бакировның «Тайны происхождения наших предков (историко-лингвистическое исследование)» дигән китабын укып чыккач туган фикерләр* . . . . . . . . . . . 164

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ


*Мирхаев Р.Ф.* Стилистическое употребление топонимов в произведениях татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX века *(на примере хоронимов и ойконимов)* . . . . . . . . 7

*Сабитова И.И.* Сомокомпонентные паремии и фразеологизмы в устном творчестве румынских татар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15

*Булатова А.К.* К этимологии татарских диалектных слов *(на материале лексем, зафиксированных в ходе научной комплексной экспедиции в Чувашию)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 24


### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ


*Шарипов А.М.* Отражение советской действительности в творчестве Сирина *(продолжение)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 29

*Сафиуллина Р.Ф.* Идеи суфийской религиозной литературы в татарской и турецкой версиях дастана «Ибрахим Адхам» . . . . 45

*Надыршина Л.Р.* Пути развития татарской поэмы в 1990-х гг. . . . 54


### ГАЯЗУ ИСХАКИ – 145


*Файзуллина Ф.Г., Ханнанова Г.М.* Мир искусства в дневниках Гаяза Исхаки . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62


### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО


*Брусько З.М.* Образ беременной женщины в традиционном мировоззрении татарского народа. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74

*Фазлетдинов И.И.* Предания об основании татарских сел Башкортостана: исторический аспект. . . . . . . . . . . . . . . . . . 83


### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ


*Тычинских З.А.* Мусульманская элита Западной Сибири в XVI–XVIII вв.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93


### ИСКУССТВО


*Шевченко Е.Н.* «Разбойники» Шиллера на татарской сцене . . . 107


### ФИЛОСОФИЯ


*Булатова Д.С.* О соотношении понятий «миф», «эпос», «история» (Пафос, Эпос, Логос) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115


### ЛИТЕРАТУРА ТЮРКСКИХ НАРОДОВ


*Юсупова Н.М.* Творчество азербайджанского поэта Ашуга Алескера и традиции «любовной лирики» в тюркской поэзии . . 122

*Хуббитдинова Н.А.* Вопросы фольклорного интертекста в башкирской литературе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

**НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ**

*Гази Кашшаф*. Творчество Ибрагима Гази . . . . . . . . . . . . . . . 136

**ПЕРСОНАЛИИ**

*Юсупов Ф.Ю.* Казанский период научной, педагогической деятельности В.В. Радлова. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143

*Муртазина Л.Р.* Галимательбанат Биктимерия: просветительница и педагог . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156

**НОВЫЕ КНИГИ**

*Хузин Ф.Ш.* На каком языке говорили наши предки? *Мысли, возникшие после прочтения книги профессора Марселя Бакирова «Тайны происхождения наших предков (историко-лингвистическое исследование)»* . . . . . . . . . . . . . 164

**НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ**

УДК 81'373.21

***Р.Ф. Мирхәев***

# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ПРОЗАСЫ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ТОПОНИМНАРНЫҢ СТИЛИСТИК КУЛЛАНЫЛЫШЫ
## (хоронимнар һәм ойконимнар мисалында)

Статья посвящена раскрытию стилистического потенциала топонимов, в частности хоронимов и ойконимов, зарегистрированных в произведениях татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX века. Как показало исследование, эти лексические единицы играют немаловажную роль в формировании стилистической структуры первых татарских романов. В работах ученых поэтический ономастикон старотатарских письменных текстов до настоящего времени рассматривается лишь фрагментарно. Этим и определяется актуальность данного исследования.

**Ключевые слова:** стилистика, старотатарский письменный литературный язык, язык татарской просветительской прозы, поэтический ономастикон, топонимы, хоронимы, ойконимы.

The article is devoted to revealing the stylistic potential of toponyms, in particular horonyms and oikonyms, registered in the works of Tatar educational prose of the late 19th – early 20th century. As the study showed, these lexical units play an important role in shaping the stylistic structure of the first Tatar novels. In the works of scientists, the poetic onomasticon of the Old Tatar written texts has been considered only fragmentarily so far. This determines the relevance of this study.

**Keywords:** stylistics, Old Tatar written literary language, language of Tatar educational prose, poetic onomasticon, toponyms, horonyms, oikonyms.

Тел белемендә лексика әдәби дискурс кысаларында чагылыш таба торган стилистик яктан тамгаланган образлы һәм модаль коннотацияләрне чагылдыруның төп чарасы буларак билгеләнә. Әлеге, нигездә, традицион рәвештә күп мәгънәле һәм мәгънәдәш сүзләр кертеп карала торган телнең стилистик ресурслары [Кожина, 1977, с. 93] ономастик берәмлекләр, безнең очракта топонимнар хисабына да киңәйтелергә мөмкин.

Ялгызлык исемнәрнең язучылар һәм шагыйрьләрнең әсәрләрендә кулланылыш үзенчәлекләре галимнәрнең күз уңында күптәннән тора. Аларның хезмәтләрендә төп игътибар бу төр сүзләрнең әдәби текстны оештыру барышында нинди вазифалар башкаруын, аның структурасында тоткан урыннарын, шулай ук онимнарны әдәби әсәрләрдә куллануның лингвистик, поэтик-стилистик һәм социаль-тарихи шартларын ачыклауга бирелә [Гарипова-Хасаншина, 2004, с. 4].

Татар тел белемендә поэтик ономастика өлкәсендәге фәнни тикшеренүләргә нигез Г.Ф. Саттаров тарафыннан аның мәшһүр татар

язучысы Г. Ибраһимовның әсәрләрендә антропонимнар һәм топонимнарның кулланылыш үзенчәлекләрен анализлауга багышланган фәнни мәкаләсендә салына [Саттаров, 1993]. Алга таба галимнең фикерләре аның шәкертләре тарафыннан үстерелә [Гаррапова, 2000; Биктимирова, 2003; Гарипова-Хасаншина, 2004; Зиннатуллина, 2005].

Теле безнең тарафтан XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар теленең социаль яктан тамгаланган функциональ төре буларак карала торган [Мирхаев, 2016; 2017] мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә теркәлгән ялгызлык исемнәр, шул исәптән топонимнар, үзләренең стилистик табигате ягыннан күпкырлы булулары белән аерылып торалар. Аерым алганда, алар без тикшергән авторларның индивидуаль стильләре характерын билгеләүче төп компонентларның берсен тәшкил итәләр. Шуңа да карамастан, татар тел белемендә мәгърифәтчелек прозасының поэтик ономастикасы әлегә кадәр фәнни тикшеренүләр объекты буларак аерып чыгарылмады. Безнең хезмәтнең актуальлеге һәм яңалыгы нәкъ менә югарыда күрсәтелгән моментлар белән билгеләнә. Аның кысаларында топонимнарның аерым төрләрен тәшкил иткән хоронимнар һәм ойконимнарның беренче татар романнарында башкарган стилистик функцияләре анализланды.

***Хоронимнар.*** Безнең тарафтан каралган текстларда дәүләтләр һәм административ берәмлекләрне атап килгән хоронимнарның стилистик табигате турыдан-туры аларның социаль яктан тамгаланган лексик берәмлекләр булуы белән бәйләнгән. Соңгысы үз чиратында әлеге төр сүзләрнең төрле илләр, өлкәләр һәм районнар арасындагы икътисади һәм мәдәни элемтәләрне гәүдәләндерү чарасы буларак кулланылышында чагылыш таба. Мәгълүм булганча, ислам динен кабул иткәннән соң, татар халкы гасырлар дәвамында мөселман дөньясы белән тыгыз элемтәдә торган һәм бу бәйләнеш XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында тагын да көчәя. Бу үз чиратында мәгърифәтчелек прозасы әсәрләре телендә дә чагылыш таба. Мисаллардан күренгәнчә, аларда теркәлгән хоронимнарның күпчелек өлешен традицион рәвештә Көнчыгыш илләренең атамалары тәшкил итә: ***Төркия, Мисыр, Һиндстан, Гарәбстан, Иран, Төркестан*** *мәдрәсәләрендә ысулы тәдрис гомумән өйлә улды* [Бигиев, 1908, б. 10]; *Көллият әсәре* ***Иран вә Һиндстанда*** *күп мәртәбә табиг иделмешдер* [Фәхретдинев, 1899, б. 17]; ***Мисырда*** *улган якшәнбә вәгазьләре ирләргә хас улмай, хатынлар арасында һәм вардыр* [шунда ук, б. 70].

Бирелә *Төркия* хоронимын аерым билгеләп үтү сорала. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар җәмгыятендә рухи-мәдәни планда Госманлы дәүләте белән якынаю тенденцияләре көчәя. Моңа билгеле бер дәрәҗәдә Россия мөселманнарының төрек солтанын үзләренең яклаучысы итеп кабул итүләре дә сәбәпче була. Нәтиҗәдә күрсәтелгән атаманың семантикасы әлеге күренешнең бер чагылышы булып торган мәгънә төсмерләре белән байый: ***Төркиядән*** *ислам пашпортлары алып, мөселман улып кайткан кемсәләре күрдегемез бар* [Бигиев, 1890, б. 52]; *Русиядән кидеп,* ***Төркиядә*** *Әхмәт вә Мәмәт намла-*

*рыны алмыш адәмләре һәркайусын чирмеш вә мөртәд димийурыз* [шунда ук, б. 52].

Шуның белән бергә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татарлар үзләрен гомумроссия иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисади пространствосының аерылгысыз бер өлеше буларак кабул итә башлыйлар. Бу үз чиратында милли топонимиконда *Русия* хоронимының активлашуына китерә һәм әлеге тенденция мәгърифәтчелек әсәрләре телендә дә чагылыш таба: ***Русия** уртасында Идел нәһерендән узак дәгел бер татар авылы мәүҗүддер* [Акъегет, 1886, б. 2]; ***Русиядә** сакин ун милиун ислам кардәшләрене йадына алды* [шунда ук, б. 7].

Безнең тарафтан каралган текстларда социаль яктан тамгаланган хоронимнарга XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына кадәр милли топонимиконда сирәк кулланылган һәм, нигездә, җир читендә урнашкан ниндидер серле дәүләтләрнең атамалары буларак кабул ителгән Ерак Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа илләрен белдерә торган сүзләр дә керә. Ләкин алга таба җәмгыятьтә мәгърифәтчелек идеяләренең таралуы татарларда алар белән кызыксынуның һәм алар белән бәйле белемнәрнең артуына китерә. Нәтиҗәдә әлеге илләр диңгез аръягындагы ниндидер әкияти җирләр булудан туктап, билгеле бер административ системаларга һәм структураларга нигезләнгән реаль политик берәмлекләр буларак кабул ителә башлыйлар: <...> ***Кытай вә Япон** үлкәләрене күрмәк,* <...> [Фәхретдинев, 1899, б. 7]; *Фради **Италиядә** музыкачы, вә Хомули дә Мисырда музыкачы иде!* [Фәхретдинев, 1903, б. 26].

Югарыда күрсәтелгән хоронимнарның социаль яктан тамгаланган булуы алар нигезендә формалашкан стиль чараларының табигатендә дә чагылыш таба. Безнең тарафтан каралган текстларда әлеге атамалар, нигездә, градацияләр составында кулланылалар: ***Кырым, Җәзаир, Италия, Швеция** һавалары, ушандак су вә сахралары һәм таулары мәдех иделенер;* <...> [Фәхретдинев, 1899, б. 8]; *Болгар халыклары **Германия, Швеция, шимали Русия, Сибирия мәмләкәтләренә** сәфәр идеп сәүдә кылырлар иде* [шунда ук, б. 28]; ***Кырым, Кытай, Иран, Һиндстан, Әфганстан, Тунис, Мисырда улган төрекләр** ошбу дидекләремездән таралмышлардыр* [шунда ук, б. 57]; ***Һиндстан, Төркия, Мисыр, Сүрия, Америкада таралган газеталардан** гарәби, төрки, фарси лисанларында мөтәҗәддид җәридәләр күрелер иде* [шунда ук, б. 75]; <...> ***Япон, Корә, Сиам, Бразилия әхвәлләрендән** бәхәс итмәйә,* <...> [Фәхретдинев, 1903, б. 66].

Татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә теркәлгән хоронимнарның социаль һәм стилистик яктан тамгаланган булуы алар һәм *йир, мәмләкәт, дәүләт* лексемалары нигезендә ясалган тезмә ил атамаларында да чагылыш таба. Текстларда әлеге төр конструкцияләрдән түбәндәгеләр теркәлде: *Ике йыл бундан мөкаддәм менла Хисаметдин **Госманлы йирендән** тәхсиле гыйлем илә ватаны Нуна кайтды* [Акъегет, 1886, б. 3]; *Бәнем игътикадыма күрә тәгъриф*

*итдекең олуг* ***Гарәб йиренең*** *харап улмасына сәбәп <...>* [Акъегет, 1886, б. 23]; *Муса Салихов* ***Төрек-Госманлы мәмләкәтенә*** *качып китә* [Бигиев, 1887, б. 31]; *Катил улмаса,* ***Госманлы мәмләкәтенә*** *качарга ирадә кылмас иде* [шунда ук]; ***Төркия, Мисыр мәмләкәтләренә*** *йөрмәк, <...>* [Фәхретдинев, 1899, б. 7]; *<...> Иран –* ***Персия мәмләкәтенә*** *качып, <...>* [Бигиев, 1890, б. 51];*<...>* ***Иран мәмләкәтендә*** *Тәһран шәһәрендән имеш* [Фәхретдинев, 1899, б. 32]; *Мәзкүр илче һәйәте* ***Хорезм мәмләкәтендән*** *киләрәк, <...>* [Фәхретдинев, 1903, б. 2]; *Хәтта кичән сәнә* ***Венгрия (Маҗарстан) мәмләкәтендән*** *яшь бер мөгаллим бар иде* [Фәхретдинев, 1903, б. 50]; ***Госманлы дәүләтенә*** *табигъ улан бу Мәмәт әфәнде кеби шөбһәле зәватлар Русиядә аз дәгелдер* [Бигиев, 1890, б. 51].

Мисаллардан күренгәнчә, тезмә ил атамаларының семантикасында да татарларның башка дәүләтләр һәм регионнар белән икътисади һәм мәдәни элемтәләре өлкәсендә электән килгән тенденцияләр чагылыш таба.

Татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә социаль яктан тамгаланган хоронимнарның башка төркемен Россия империясе губерналары һәм өязләренең административ үзәкләре булып торган шәһәрләрнең исемнәре һәм иске татар язма әдәби теленең традицион берәмлекләреннән саналган гарәп асыллы *вилаять,* шулай ук рус теленнән кергән *губерна, уезд // өйәз* лексемаларыннан торган тезмә атамалар тәшкил итә. Язучылар әлеге конструкцияләргә, нигездә, татарларның традицион яшәеш урыннары саналган һәм алар хуҗалык эшчәнлеге алып барган регионнар турында сөйләгәндә мөрәҗәгать итәләр. Мондый төр тезмә хоронимнардан без тикшергән текстларда түбәндәгеләр теркәлде: ***Казан вилаяте (губернасы)ның*** *мәркәзе – ошбу шәһәрдер* [Фәхретдинев, 1899, б. 3]; *Мәсәлән,* ***Оренбург губернасында (вилаятендә)*** *йөз ислам карйәсенә, <...>* [шунда ук, б. 47]; *Урынлары* ***Оренбург, Уфа, Самар, Пермь, Табул вилаятьләрендә*** *улып, җөмләсе бер миллион микъдарында хисап иделенәдер* [шунда ук, б. 56]; *<...>* ***Нижгород губернасы Сергач уезды*** *карйәләрендән бер карйәдер* [Бигиев, 1890, б. 2]; *Олуг табибларның мәслихәте Хәдичә туташның мәразында гыйлаҗ бу иде:* ***Самар губернасында*** *кыргыз кымызы эчмәклек* [шунда ук, б. 53]; *<...>* ***Казан губернасы Лайыш өйәзе*** *«Н...» карйәсендәнсез...* [Фәхретдинев, 1903, б. 114]; *<...> бундан калкып* ***Верхурал вә Уса өйәзләрене*** *сәяхәт итмәгә китдеге көндән бирү <...>* [шунда ук, б. 51].

Татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә кулланыла торган хоронимнар арасында социаль яктан тамгаланган булулары белән географик өлкәләрнең атамалары да аерылып тора. Мәсәлән, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында атаклы мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Исмәгыйль Гаспралының (1851–1914) эшчәнлеге нәтиҗәсендә Кырым Россия империясенең төрки-мөселман халыклары тарафыннан үзенә күрә бер мәгариф һәм фән үзәге буларак кабул ителә башлый. Бу *Кырым* хоронимының семантикасында да чагылыш таба:

<...> ***Кырымда** нәшер улынан җәгърафия, тарих, табигатә даир фән китапларыны сатып алып,* <...> [Акъегет, 1886, б. 61].

Ә *Сибирйа* хоронимы татарларның Россия империясендәге башка регионнар белән икътисади элемтәләре үсү нәтиҗәсендә әлеге чорда милли сәүдә капиталы мәнфәгатьләре даирәсенә кергән төбәк атамасы буларак кулланылышка кереп китә: *Шимди исә Җиһангир Казанда улмайынча, алты-йиде айлык сәфәр уларак **Сибирйа тарафына** камиртсә – сәүдә хезмәтләрейлә китмеш иде* [Бигиев, 1890, б. 12].

Шуның белән бергә аның стилистик табигате кылынган җинаятьләр өчен җәза буларак билгеләнгән каторгага җибәрелү урынын атап килүендә дә чагылыш таба: *Юк, Алла сакласын, бу кичмеш дәүләт вә рәхәтдән **Сибирйа** вә каторжный хезмәткә төшкәнче, күпергә вә күпердән суга төшү биш мәртәбә әфзалдыр* [шунда ук, б. 40].

Алга таба текстларда социаль характердагы мәгънә төсмерләре белән мәгърифәтчелек дискурсының аерылгысыз өлешен тәшкил иткән публицистик экспрессивлыкка ирешү чарасы буларак кулланылган һәм XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына кадәр милли топонимиконда сирәк чагылыш тапкан *Яурупа*, *Америка*, *Африка*, *Азия* хоронимнары да байый: ***Яурупа** дәүләтләре ач бүреләр кеби у бәрәкәт мәгъдәне улан мәмләкәте йотмайа агызларыны тәмамән ачтылар* [Бигиев, 1908, б. 11]; ***Яурупа** шәһәрләренә күрше улдыклары сәбәптән «мода» динелгән зарарлы хасталык бунлар арасында күрелергә башламышдыр* [Фәхретдинев, 1899, б. 4]; *Бу делләр сәбәбендән кирәк Русиядә, кирәк **Яурупа** вә **Америкада**, кирәк Иран, Әфган, Һинд тарафларында сәүдә итмәк мөмкин улачактыр* [шунда ук, б. 13]; *Аллаһы Тәгаләнең исемене дә белмәй адәм ите ашап тереклек идүче **Африка** вәхшиләре арасында* <...> [шунда ук, б. 72]; <...> *бөтен **Азияйә** намы мәгълүм улан Салих бай* <...> [Фәхретдинев, 1903, б. 76].

***Ойконимнар.*** Безнең тарафтан каралган текстларда торак пунктларны атап килгән ойконимнарның стилистик табигате шулай ук аларның социаль яктан тамгаланган лексик берәмлекләр булуында чагылыш таба. Мәгърифәтчелек дискурсы кысаларында иҗтимагый характердагы мәгънә төсмерләренә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында күпчелек өлеше авыл җирлегендә көн күргән татарларның төрле яшәеш сфераларын чагылдырган шәһәр исемнәре ия була. Мәсәлән, күрсәтелгән чорда Казан шәһәренең татар дөньясындагы әһәмияте тагын да арту сәбәпле *Казан* ойконимы милләтнең бергә туплану үзәгенең атамасы буларак кабул ителә башлый. Нәтиҗәдә аның семантикасы яңа мәгънәләр белән байый: ***Казанда** өч-дүрт йирдә таш пулат ивләре бар иде* [Бигиев, 1887, б. 14]; *Менә без дә углымызны **Казанга** мәдрәсәгә укырга йибәрәмез* [Бигиев, 1890, б. 4]; *Бунларның һәм олуг вә гүзәл фасад илә бина иделмеш мәсҗедләре **Казан шәһәрене** зиннәтләп торалар* [Фәхретдинев, 1899, б. 3]; *Бу китап **Казанда** ташка басылган!* [Фәхретдинев, 1903, б. 30].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татарларның иҗтимагый, икътисади һәм рухи-мәдәни тормышында Россия дәүләтенең баш-

калалары – Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре дә мөһим урын алып торган. Бу чорда алар татар җәмгыяте вәкилләре, аерым алганда сәүдә һәм алдынгы карашлы даирәләр тарафыннан империянең бөеклеген гәүдәләндергән гомумроссия һәм дөньякүләм масштабтагы икътисади һәм мәдәни үзәкләр буларак кабул ителә башлый. Нәтиҗәдә әлеге шәһәрләрнең атамалары – *Москва, Мәскәү* (а) һәм *Петербург* (ә) ойконимнарының семантикасы өстәмә мәгънә төсмерләре белән байый:

а) *Белешләремез Гали бай вә Сибгатулла әфәнде тиҗарәтлә мәшгуль улып, бу көн **Москвада,** сабах үз шәһәрләрендә, у бересе көн гайре бер мәркәзе тиҗарәтдә вакыт кичермәкдә иделәр* [Акъегет, 1886, б. 19]; *<...> үзем дә хезмәтләрлә **Мәскәүгә** кидәмен* [Бигиев, 1890, б. 18];

ә) *Мөфти хәзрәтләре мөһим бер кеше улмаса, **Петербурга** вармаз иде, <...>* [Акъегет, 1886, б. 41]; ***Петербургда** университетта хәтме көтеб кылмыш адәм улса да, <...>* [Бигиев, 1887, б. 8].

Алга таба безнең тарафтан каралган текстларда социаль мәгънә төсмерләренә татарларның традицион яшәеш урыннары саналган һәм алар хуҗалык эшчәнлеге алып барган регионнарның үзәкләрен атап килгән ойконимнар да ия була: *Чүнкә бу поезд, ягъни такым илә мөфти хәзрәтләре Петербургдан **Уфайа** кичәчәк имеш* [Акъегет, 1886, б. 41]; ***Шәһре Нижнийдә** мөселманлар мәүҗүд улдыгы сәбәбдән, бу чәйханәдә һәм мөселманлар юк дәгел иде* [Бигиев, 1890, б. 36]; *Ул хәзердә Казанда юк, **Сембергә** китде* [Бигиев, 1887, б. 17]; *Ивдә, бүген генә **Сембердән** кайтып килде, хәзер барып рөхсәт сорармын* [шунда ук, б. 19]; *Әхмәди бай <...> **бәлдәи Самардан** биш-алты чакрым йирдә кира хак илә бер дача ялламыш иде* [шунда ук, б. 53].

Татарлар арасында гомумроссия иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисади пространствосы белән интеграция процессларының көчәюе сәбәпле XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында милли топонимиконга империянең башка шәһәрләрен атап килгән топонимнар да үтеп керә: *<...> хәзердә **Тифлистә** мануфактура малыйла төҗҗар вә сахибе әмләк улып вә кәндесенә **Тифлистә** нөфүз кәсеп идеп, <...>* [Акъегет, 1886, б. 70]; *Соңра Мәскәү, **Костромадан** кичеп, <...>* [Фәхретдинев, 1899, б. 33]; *Дөрест, франсыз мөхәррирләре яздыгына күрә, бу юл дөньяда иң озын юл улачактыр. 1899 елда тәмам улып, **Порт-Артурга** йитеп тукталачактыр* [шунда ук, б. 40].

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә теркәлгән ойконимнарның социаль яктан тамгаланган булуы алар нигезендә формалашкан стиль чараларының табигатендә дә чагылыш таба. Әлеге планда бу атамалар, нигездә, татарларның традицион яшәеш ареалы чикләрен һәм хуҗалык эшчәнлеге масштабларын чагылдырган градацияләр составында кулланылалар: *<...> әксәресе башка шәһәрләрә, мәсәлән: **Нижний, Казан, Мәскәү, Петербург вә Ростов-Дон кеби йирләрә** хезмәт вә тиҗарәт ичүн кидийурлар* [Бигиев, 1890, б. 2]; *<...> ул тараф малларыны **Оренбург, Троицки, Семипалат, Петропавел,***

***Казан, Нижний Новгород*** *базарларына китереп актарырлар иде* [Фәхретдинев, 1899, б. 11]; *Бу карйәйә* ***Петербург, Москва, Казан, Вйатка, Харков, Томски, Иркут,*** *хәтта Финлйандийәләрдән адәмләр килер* <...> [Фәхретдинев, 1903, б. 50].

Моннан тыш безнең тарафтан каралган текстларда татарлар тарафыннан гасырлар дәвамында дин, мәдәният, мәгариф һәм фән үзәкләре буларак кабул ителгән мөселман илләре шәһәрләренең атамалары да социаль яктан тамгаланган булуы белән аерылып торалар. Бу аларның семантикасын шулай ук өстәмә стилистик төсмерләр белән баета: *Хисаметдин менла исә дәгел нәхүләр, сарыфлар, гыйльме фикъһедән, гыйльме хикмәтдән* ***Истанбулда*** *шәкердлектә тәмам хәбәрдар улды* [Акъегет, 1886, б. 3]; ***Истанбулда*** *укымыш* [шунда ук, б. 8]; *Бер-ике сәнә* ***Исламбулда*** *торып, соңра ивә кайтсаң да ярар* [Бигиев, 1890, б. 62]; <...> *ике ай мөкаддәм* ***Тәһрандан*** *сәфәр идеп,* <...> [Фәхретдинев, 1899, б. 32]; <...> ***Тәһран шәһәренә*** *юлланачак улдым* [шунда ук, б. 38]; <...> ***Багдаддан*** *чыкып кайтып кердекләренә кадәр улан әхвале,* <...> [Фәхретдинев, 1903, б. 2]; ***Йәнбәгдән Мәдинәйә*** *вармак ичүн кәрван улмадыгындан,* <...> [шунда ук, б. 124].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар җәмгыятенә Көнбатыш цивилизациясенең кыйммәтләре үтеп керә башлый. Нәтиҗәдә милли топонимиконда Европа шәһәрләрен атап килгән ойконимнар урын ала. Безнең тарафтан каралган текстларда алар шулай ук билгеле бер стилистик вазифалар башкаралар. Аерым алганда, мәгърифәтчелек дискурсы кысаларында иҗтимагый, икътисади һәм мәдәни прогрессны гәүдәләндергән әлеге топонимнар ярдәмендә татар милләте күрсәтелгән өлкәләрдә ирешергә тиеш булган чикләр билгеләнә: <...> ***Париж, Лондон, Берлин шәһәрләренә*** *вармак;* <...> [Фәхретдинев, 1899, б. 25]; <...> ***Берлин, Липсих, Һамбург кеби*** *олуг сәүдә базарларына кадәр мал күчереп вармаклары һәм мөмкин дәгелдер* [шунда ук, б. 62]; *Әмма асыл нөсхәсе 1809 да* ***Лондонда*** *табиг иделдеге мәрвидер* [Фәхретдинев, 1903, б. 25].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләренең поэтик ономастикасы хоронимнар һәм ойконимнарның кулланылышы ягыннан үзендә иске татар әдәби теленең язма традицияләрен дәвам иттерү һәм сәнгатьчә сүз кулланылышына яңа берәмлекләр кертү кебек ике тенденцияне чагылдыра. Шуның белән бергә һәм Көнчыгыш, һәм Көнбатыш, рус телләреннән үтеп кергән топонимнар текстларда иҗтимагый характердагы образлы мәгънә төсмерләрен бирү өчен хезмәт итәләр. Бу үз чиратында аларның бай стилистик потенциалга ия булулары турында сөйли.

## Әдәбият

*Акъегет М.* Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. 70 б.

*Бигиев З.* Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә. Роман. Казан: типогр. Г.М. Вечеслава, 1887. 77 б.

*Бигиев З.* Гөнаһе кәбаир. Роман. Казан: Типогр. Г.М. Вечеслава, 1890. 72 б.

*Бигиев З.* Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр). Казан: типолитогр. И.В. Ермолаевой, 1908. 108 б.

*Биктимирова А.Р.* Лингвистическая и ономастическая поэтика татарских народных песен: дис. ...канд. филол. наук. Казань, 2003. 194 с.

*Гарипова-Хасаншина В.М.* Поэтическая ономастика прозы Гумара Баширова: дис. ...канд. филол. наук. Казань, 2004. 241 с.

*Гаррапова Р.Х.* Поэтическая ономастика прозы Мухаммата Магдеева: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2000. 265 с.

*Зиннатуллина Г.Х.* Поэтическая ономастика прозы Амирхана Еники: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005. 214 с.

*Кожина М.Н.* Стилистика русского языка. Учеб. пособие для студентов фак. рус. яз. и литературы пед. ин-тов. М.: Просвещение, 1977. 223 с.

*Мирхаев Р.Ф.* Языковая ситуация в татарском обществе конца XIX – начала XX века // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2016. № 12. Ч. 3. С. 141–143.

*Мирхаев Р.Ф.* Старотатарский литературный язык и социальная структура татарского общества в конце XIX – начале XX вв. // Гуманитарные науки и образование. 2017. № 1 (29). С. 127–130.

*Саттаров Г.Ф.* Г. Ибраһимов әсәрләрендә исем-атамалар // Казан утлары. 1993. № 6. Б. 180–184.

*Фәхретдинов Р.* Сәлимә яки гыйффәт. Гафил бән Габдулла әсәре уларак бер хикәятдер. Казан: типогр. Б.Л. Домбровского, 1899. 80 б.

*Фәхретдинев Р.* Әсма яки гамәл вә җәза. Оренбург: типогр. М.-Ф.Г. Каримова, 1903. 130 б.

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145’373

***И.И. Сабитова***

# РУМЫН ТАТАРЛАРЫ АВЫЗ ИҖАТЫНДА СОМОКОМПОНЕНТЛЫ ПАРЕМИЯ ҺӘМ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР

В статье анализируются соматические термины, которые являются древнейшим слоем основного лексического фонда тюркских языков. Анализ словаря «Atalar sözi» Надрата Махмута и Анвара Махмута показывает консервативность и устойчивость названий частей тела. Выявленные сомокомпонентные паремии и фразеологизмы румынских татар имеют параллели в татарском языке, что позволяет судить о заимствовании, взаимовлиянии и взаимопроникновении контактирующих языков.

**Ключевые слова:** соматизм, фольклор, паремия, фразеологизм, татарский язык, лексика, румынские татары, язык румынских татар, параллели.

The article deals with somatic terms, which are the oldest layer of the main lexical fund of the Turkic languages. The analysis of the dictionary «Atalar sözi» by Nadrat Mahmut and Anwar Mahmut shows the conservatism and stability of the names of body parts. The identified paroemias with somatic components and phraseological units of the Romanian Tatars have parallels in the Tatar language, which makes it possible to judge the borrowing, mutual influence and interpenetration of the contacting languages.

**Keywords:** somatism, folklore, paroemia, phraseological unit, Tatar language, vocabulary, Romanian Tatars, language of Romanian Tatars, parallels.

Мәкаль-әйтемнәр халыкның тәҗрибәсен, дөньяга карашын чагылдыра, кыскалык һәм форма тотрыклылыгы белән характерлана. Алар фольклорның кечкенә жанрлар тибы – паремиягә керә. Әйтем төгәлләнгән фикерне тәшкил итмәгән тотрыклы, образлы тәгъбир булса, мәкаль, – җәмгыять тарафыннан үз ителеп, уртак кулланылышта йөргән кыска һәм тирән мәгънәле, гадәттә нәсыйхәт бирә торган калыплашкан гыйбарә, тапкыр сүз.

Хәзерге тел белемендә «бердәмлеге, таркалмавы, компонентлары арасында мәҗбүри бәйләнеш булуы, бөтенлеге, сөйләмгә әзер килеш килеп керүләре белән аерылып торган сүзтезмәләрне фразеологизм» дип атыйлар [Русско-татарский толковый..., 2016, б. 197]. Паремия һәм фразеологизмнарда теге яки бу халыкның тарихы һәм мәдәнияте үзенчәлекләре белән бәйле бай лингвистик материал чагылыш таба. Халыклар үзләре дә төрле булган кебек, бу материал башка тел системаларында да төрле. Шул ук вакытта хәтта туган булмаган телләрнең паремия һәм фразеологизмнары еш кына охшаш, чөнки алар гомумкешелек кыйммәтләрен белдерә. И.И. Срезневский фикеренчә, нәкъ менә телдә халыкның тарихи формалашкан дөнья, тормыш, кыйммәтләр системасы турындагы күзаллаулары чагыла [Срезневский, 2007, б. 19].

Татар лингвофольклористикасында паремияләр (мәкаль-әйтемнәр, канатлы әйтелмәләр) һәм тел белемендә фразеологизмнар шактый тирәнтен өйрәнелгән, сүзлекләр төзелгән [Җәләй..., 1957; Ахунҗанов, 1972; Әхәтов, 1982; Исәнбәт, 1963; Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987 һ.б.]. Әлеге хезмәтләрнең күбесендә соматик паремия һәм фразеологизмнар аерым тематик бүлекләрдә теркәлгән. Махсус сүзлекләр белән беррәттән татар теленең аңлатмалы, тәрҗемәле сүзлекләрендә дә сомокомпонентлы паремия һәм фразелогик берәмлекләргә зур урын бирелгән.

Фразеологизм – лингвистиканың бер тармагы, шуңа аны лингвокультурологик аспектта тикшерү фразеологик берәмлекнең тел тамгасы буларак мөстәкыйльлеген тирәнрәк анализларга мөмкинлек тудыра.

Гомуми фразеологик мәгънәне ясауда төп рольне фразеологизм структурасына кергән махсус компонент уйный. Шундый компонентларның берсе булып әгъза атамалары санала.

Соматизмнар татар теленең төп лексик фондына керә һәм борынгылыгы, зур күләмлелеге белән үзенчәлекле катламны тәшкил итә. Бүгенге көндә телдә кулланышта йөргән әлеге атамаларның күбесен башка төрки телләрдә генә түгел, монгол, тунгус-маньчжур, фин-угор телләрендә дә очратырга мөмкин. Татар теленең аңлатмалы һәм диалектологик сүзлекләренә теркәлгән күпсанлы атамалар шул турыда сөйли. Күренекле тел галиме, этимолог Р. Әхмәтьяновның «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә тән әгъзалары атамалары һәрьяклап анализланган, кайсы телләрдә кулланылганлыгы, аларның вариантлары, дериватлары һ.б. күрсәтелгән. Мәсәлән, **КУЛ I** «рука» < гом. төрки *қол* id., хак., тув., як. *хол* «кул; атның алгы аягы», чув. *хул* «кулның беләзектән иңбашка кадәрге өлеше», бор. монг. *kol* «алгы аяк» (Поппе 1938: 292), хәз. монг. *көл*, бур. *хүл* «тәпи» (хәер, бу сүз бүтән тамырдан да булырга мөмкин). *Қол* сүзе кайбер төрки телләрдә пассив лексик фондка карый, «кул» мәгъ. угыз телләрендә башлыча *әл*, *эл*, чув. *ал* кулланыла. Будагов II: 86–88; Räsänen 1969: 217 --- [Әхмәтьянов, 2015, б. 465].

Әгъза атамалары – теләсә кайсы тел системасында универсаль лексик төркемнәрнең берсе, һәм ул чагыштырма-тарихи, структурчагыштырма һәм лингвокультурологик аспектларда тикшеренүләрнең актуаль объекты булып тора. Соматизмнар борынгы катламны тәшкил итү сәбәпле, соматик терминологияне төрки һәм башка телләр белән чагыштырма планда өйрәнү хәзерге татар тел белеменең мөһим бурычларыннан санала. Атамаларның аерым регионнарда яшәүче татарларның авыз иҗатында кулланылыш үзенчәлекләрен, семантик үзгәрешләрне, шулай ук сүзьясалыш процессында катнашуын чагыштырып өйрәнү дә – әһәмиятле мәсьәләләр. Аерым текстларның лексик корпусларын тикшерү ысулларының берсе, билгеле бер чорда телнең гомуми торышы турында гына түгел, ә лексикасы формалашудагы төп тенденцияләр, үзара аралашкан телләрнең бер-берсеннән сүзләр алуы, телләрнең үзара йогынтысы турында да фикер йөртергә мөмкинлек бирә.

2020 елда «Фәнни Татарстан» журналында Добруҗа татарлары әкиятләрендәге әгъза атамалары татар әкиятләрендәге соматизмнар белән чагыштырылган мәкалә басылып чыккан иде [Сабитова, Муктат, 2020, б. 7–14]. Тәкъдим ителә торган әлеге мәкаләдә Румыниянең Добруҗа өязендә яшәүче румын татарлары фольклорындагы сомокомпонентлы фразеологизм һәм паремияләрне татар телендәге әгъза атамалары катнашында ясалган фразеологик берәмлекләр һәм паремияләр белән чагыштырып, янәшәлекләр, ягъни параллельләр табу максатын куйдык.

Күп кенә сомокомпонентлы паремия һәм фразеологик берәмлекләрнең башка телләрдә тулы яки өлешчә параллельләре бар. Әлеге берәмлекләрнең индивидуаль мәгънәләрен формалаштыруда соматизмнар мөһим функция башкара. Алар төрле халыкларның фразеология фондында шактый киң катлам тәшкил итә һәм зур тематик төрлелек белән аерылып тора.

Тикшеренү өчен материал «Atalar sözi» (‘Аталар сүзе’) сүзлегеннән тупланды [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004]. Китап Констанца шәһәренең «EX PONTO» нәшриятында дөнья күргән. Әлеге хезмәт кырымтатар галимнәре доктор Нәдрәт Мәхмүт һәм профессор, доктор Әнвәр Мәхмүт тарафыннан Румыниядә яшәүче татарлардан җыелган һәм басмага әзерләнгән.

Румын татарлары телендә уртак төрки катламга кеше әгъзалары, туганлык, фауна, флора, йорт кирәк-яраклары, гореф-гадәт, эш кораллары, көндәлек тормыш кирәк-яраклары, савыт-саба, кием-салым, азык-төлек, йорт хайваннары һ.б атамалар, саннар, фигыльләр һ.б. керә. Уртак лексика авыз иҗатында да еш очрый. Кайбер сүзләр шактый үзгәреш кичерү сәбәпле, аларның беренчел яңгырашы онытылган, архаизмнар булып кына сакланып калган. Бу күренеш паремия һәм фразеологик берәмлекләрдә дә чагыла.

Фразеологизм һәм паремияләр тупланган сүзлек «Аталар сүзе – акылның үзе» дигән эпитет белән башлана. «Aldsöz»дә (‘Алсүз’ – «Кереш»тә) авторлар: «Фольклорчылар аталар сүзен гыйбрәтле сүз, иске сүз, канатлы сүз, сүзләрнең солтаны, сүз җәлпәзәсе, сүзләрдән ясалган энҗеләр, телнең кодрәте (куәте), алтын сүз, тәрбияви сүз, баллы сүз кебек әйтемнәр белән атап килгәннәр» дип, яза [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 1].

«Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр» җыентыгының «Кереш»ендә дә «... татар халкында «мәкаль» һәм «әйтем»не атау өчен башка гарәпчә атамалар белән беррәттән, «борынгылар сүзе», «ата-баба сүзе», «картлар сүзе», «халык сүзе», «гыйбрәтле сүзләр» кебек исемнәр файдаланылган. ... Мондый атамалар мәкаль текстларының үзләрендә дә беркетелгән: «Амбар төбендә икмәк бар, картлар сүзендә хикмәт бар», «аталар сүзе – акылның үзе» һ.б. билгеләп үтелә [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 6].

«Atalar sözi» сүзлегендә фразеологизмнар һәм паремияләр 35 тематик төркемгә бүлеп каралган. Мисал итеп aile ‘гаилә’, yakşı –

yaman ‘яхшы – яман’, dost – duşman ‘дус – дошман’, dert – derman ‘дәрт – дәрман’, aywanlar ‘хайваннар’, kuşlar ‘кошлар’, kemırıcıler ‘кимерүчеләр’, balıklar ‘балыклар’ һ.б.ны күрсәтергә була. Insan ‘инсан’ төркеме үзе берничә төркемчәдән тора: keşı, insan ‘кеше, инсан’, ayak ‘аяк’, baş ‘баш’, moyın ‘муен’, sakal ‘сакал’, burın ‘борын’, karın ‘карын’, kaş ‘каш’, el, kol ‘кул’, kulak ‘колак’, damar ‘тамыр’, tırnak ‘тырнак’, köz ‘күз’, şaş ‘чәч’, yüz ‘йөз’, tük ‘төк’, yürek ‘йөрәк’, tıl ‘тел’, tış ‘теш’, can ‘җан’, awız ‘авыз’. Биредә шулай ук parmak ‘бармак’, öt ‘үт’, kemıg ‘сөяк’, bel ‘бил’, dudak ‘ирен’, bogaz ‘бугаз’, kırpık ‘керфек’, kursak ‘корсак’, arka ‘арка’, mıyık ‘мыек’, beden ‘бәдән’, bawır ‘бавыр’, tobık ‘тубык’, töş ‘түш’ атамалары да урын алган.

Чагыштыру өчен материал Г.Х. Әхәтов [Әхәтов, 1982], Н. Исәнбәт [Исәнбәт, 1963; 1989; 1990], «Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр» [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987], Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова [Гаффарова..., 2006] хезмәтләреннән һәм «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән [Татар теленең аңлатмалы..., 2015–2021] тупланды. «Atalar sözi» сүзлегеннән алынган мисаллар кириллицага күчерелеп бирелде.

Тулы параллельлек түбәндәге гыйбарәләрдә очрый.

*Баш җарылса, бүрек эчендә, кул сынса, җән(җиң) эчендә.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 206] – *Баш ярылса, бүрек эчендә, кул сынса, җиң эчендә.* [Гаффарова.., 2006, б. 42; Исәнбәт, 1963, б. 781; Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 300];

*Баш сау булса, мал табылыр.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 209] – *Баш исән (сау ) булса, мал табылыр* [Гаффарова..., 2006, б. 588; Татар теленең аңлатмалы..., 2015, б. 435];

*Баш кашырга да вакыт юк.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 207] – *Баш кашырга да вакыт юк.* [Гаффарова..., 2006, б. 40; Татар теленең аңлатмалы..., 2015, б. 436; Әхәтов, 1982, б. 30; Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 302];

*Башына төшкән башмакчы булыр.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 207] – *Башыңа төшсә, башмакчы булырсың.* [Гаффарова..., 2006, б. 42; Татар теленең аңлатмалы..., 2015, б. 438; Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 300];

*Башына дәүләт кошы кунган.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 206] – *Башка дәүләт кошы куну.* [Татар теленең аңлатмалы..., 2015, б. 46];

*Башына тартса, аягына җитми, аягына тартса, башына җитми.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 208] – *Башына тартса, аягына җитми, аягына тартса, башына җитми.* [Гаффарова..., 2006, б. 42; Исәнбәт, 1963, б. 535];

*Авырткан башка тимер тарак.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 210] – *Авырткан башка тимер тарак (таяк).* [Гаффарова..., 2006, б. 52; Татар теленең аңлатмалы..., 2015, б. 52; Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 299];

*Баш кисмәк булса да, тел кисмәк юк.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 207] – *Баш кисмәк бар, тел кисмәк юк.* [Гаффарова..., 2006, б. 40];

*Авызы бар, теле юк.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 237] – *Авызы бар, теле юк* [Исәнбәт, 1989, б.17];

*Күп авыз бер булса, бер авыз юк була.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 239] – *Күп авыз бер булса, бер авыз юк була.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 307];

*Авызыннан чыкканын колагы ишетмәс. Авызы әйткәнен колагы ишетмәс.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 238] – *Авызы ни сөйләгәнне (әйткәнен) колагы ишетми.* [Әхәтов, 1982, б. 16];

*Аяк җиргә тимәде.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 205] – *Аяк җиргә (идәнгә) тимәү.* [Әхәтов, 1982, б. 25; Гаффарова..., 2006, б. 388; Исәнбәт, 1989, б. 123; 1963, б. 531]; *Аяк җиргә тимәү.* [Татар теленең аңлатмалы..., 2015, б. 285]; *Аяк җиргә тими.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 317];

*Бер аягы монда, бер аягы анда.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 205] – *Бер аягы анда, берсе монда булу.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 318]; *Бер аягым монда, берсе анда.* [Татар теленең аңлатмалы..., 2015, б. 519]; *Бер аягың анда, бер аягың монда булсын.* [Гаффарова..., 2006, б. 46];

*Аягың кермәгән җиргә башыңны сокма (тыкма).* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 204] – *Аягың кермәгән җиргә башыңны тыкма.* [Исәнбәт, 1963, б. 537];

*Кул җарасы гәшәр (бетәр), Тел җарасы гәшмәс (бетмәс).* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 214] – *Кул ярасы бетәр, тел ярасы бетмәс.* [Исәнбәт, 1963, б. 803];

*Кул кайда, авыз шунда.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 216] – *Кул кайда, авыз шунда.* [Исәнбәт, 1963, б. 802];

*Кулы кыймылдаганның, авызы да кыймылдар.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 218] – *Кулы кыймылдаганның авызы да кыймылдар.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 311];

*Кул кулны җуар.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 216] – *Кул кулны юар.* [Исәнбәт, 1963, б. 862];

*Каш җагаман (ясыйм) дип күз чыгарыр.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 213] – *Каш (төзәтәм) ясыйм дип күз чыгару.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 303; Гаффарова..., 2006, б. 89; Исәнбәт, 1963, б. 786; 1989, б. 363; Әхәтов, 1982, б. 72]; *Каш төзәтәм дип күз чыгарма.* [Татар теленең аңлатмалы..., 2017, б. 190];

*Каш белән күз арасында.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 230] – *Каш белән күз арасында.* [Исәнбәт, 1989, б. 363];

*Кара маңа бер күз белән, карыйм саңа ике күз белән.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 230] – *Кара миңа бер күз белән, карыйм сиңа ике күз белән.* [Исәнбәт, 1963, б. 783];

*Карганың күзен карга чукымас* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 230] – *Карга(ның) күзен карга чукымас.* [Гаффарова...,

2006, б. 88]; *Карга(ның) күзен карга чыгармас.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 140];

*Тел кылычтан кәскендер (үткендер). Тел иттәндер, тимер кылычтандыр, Тел кылычтан кәскендер (үткендер).* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 220] – *Тел кылычтан үткендер.* [Гаффарова..., 2006, б. 131; Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 306];

*Тешсез авыз – ташсыз тирмән.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 224] – *Тешсез авыз – ташсыз тегермән.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 308]. *Тирмән* сүзе, бүгенге көндә диалекталь сүз буларак, татар теле сүзлекләрендә теркәлгән һәм сөйләмнәрдә бүген дә кулланышта йөри;

*Тырнагың булса, башың кашы.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 224] – *Тырнагың булса, башың кашы.* [Исәнбәт, 1963, б. 812; Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 317].

Бер соматизм урынына икенче атама кулланган очраклар да күзәтелә:

*Борының кермәгән җиргә башыңны сокма (тыкма).* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 212] – *Борының кермәгән җиргә бармагыңны тыкма.* [Исәнбәт, 1963, б. 777]. *Бармагың сыймаган җиргә башың тыкма.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 300];

*Тешең авыртса, телең тый, күзең авыртса, кулың тый. Карының авыртса, авызың тый, күзең авыртса, кулың тый.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 223, 212] – *Күзең авыртса, кулың тый, эчең авыртса, авызың тый.* [Гаффарова..., 2006, б. 105]; *Күзең авыртса, кулың тый, эчең авыртса, тамагыңны тый.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 304];

*Тырнак бармактан аерылмас.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 224] – *Тырнак иттән аерылмас.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 317];

*Чәче озын, акылы кыска.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 232] – *Сакалы озын, акылы кыска.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 303];

*Колак ике, тел бердер, бер коныш (сөйлә), ике ишет.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 218] – *Авыз бер, колак ике: сөйлә бер, тыңла ике.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 306]; *Тел бер, колак ике.* [Исәнбәт, 1990, б. 124];

Өлешчә янәшәлек яки вариантлык:

*Буе зур, акылы юк. Буе дәвә буедай, акылы бер төймәдәй.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 211] – *Буйга үскән, акылы үсмәгән.* [Гаффарова..., 2006, б. 55];

*Авызы пешкән сөтне үфереп (өреп) эчәр.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 238] – *Авызы пешкән салкын суны да өреп эчкән; Авызың ашка пешсә, сөтне дә өреп кабарсың; Бер авызың пешкәч, икенче өреп кабасың.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 307]; *Авызы пешкән өреп капкан.* [Гаффарова..., 2006, б. 11.];

*Аягыңны юрганыңа күрә суз.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. ] –*Түшәгеңә карап аягыңны сузу.* [Әхәтов, 1982, б. 141; Исәнбәт, 1963, б. 537]; *Юрганыңа карап аягыңны сузу.* [Әхәтов, 1982, б. 158];

*Тел белән урак ура.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 222] – *Теле белән кош тота.* [Гаффарова..., 2006, б. 132; Әхәтов Г.Х., 1982, б. 128; Исәнбәт, 1990, б. 124]; *Тел белән тегермән кору; тел белән тегермән тарту; тел белән чумар ишү.* [Татар теленең аңлатмалы..., 2019, б. 515];

*Сакалы агарган, акылы агармаган.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 232] – *Сакалына чал кергәнче, күкрәгенә акыл кермәгән.* [Исәнбәт, 1990, б. 63];

*Кулың озын булмасын*! [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 215] – *Кулы озын.* [Исәнбәт, 1989, б. 415]; *Кулы озын булу.* [Татар теленең аңлатмалы..., 2017, б. 486];

*Кулдан киткән кулга кайтмас. Кулдан чыккан кулга кермәс.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 217] – *Кулдан китү.* [Исәнбәт, 1989, б. 415; Татар теленең аңлатмалы..., 2017, б. 483];

*Тел – башка бәладер. Теле озын булганның башы бәладән чыкмас.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 220, 222] – *Тел әйтер дә качар, башка бәласе калыр.* [Гаффарова..., 2006, б. 131];

*Теле татлы, кулы саран.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 222] – *Теле татлы, күңеле каты.* [Гаффарова..., 2006, б. 132];

*Ике аяк бер папешкә сыймас.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 205] – *Бер казанга ике тәкә башы сыймас.* [Гаффарова..., 2006, б. 46]. *Ике тәкә башы бер казанга сыймас.* [Гаффарова..., 2006, б. 73; Татар теленең аңлатмалы..., 2016, б. 475]. Румын татар теленә *папеш* сүзе румын теленнән кергән 'papuc', татарча *башмак*, *чүәк* сүзенә туры килә;

*Коры кул белән ау ауламаслар.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 218] – *Буш кул белән.* [Исәнбәт, 1989, б. 197; Татар теленең аңлатмалы..., 2015, б. 868]; *Коры кул белән.* [Татар теленең аңлатмалы..., 2017, б. 383];

*Уйдәге (өйдәге) диварның да колагы бар. Туфракның да колагы бар.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 219] – *Диварларның да колагы бар.* [Гаффарова..., 2006, б. 972];

*Казан карасы китәр, йөз карасы китмәс.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 234] – *Йөз карасы.* [Гаффарова..., 2006, б. 83; Исәнбәт Н., 1989, б. 322]; *Йөз каралыгы (карасы)* [Татар теленең аңлатмалы..., 2016 б. 726];

*Телнең кәмеге юк. Тел кәмексездер, әмма кәмек сындырыр.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 220, 221] – *Телнең сөяге юк. Тел сөяксез, ни сөйләмәс.* [Гаффарова..., 2006, б. 62;] *Сөяксез тел ни сөйләмәс.* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 436]. *Кәмек* татар телендә «кимек – йомшак сөяк» дигәнне аңлата;

*Башны ташка орудан башыңа акыл килмәс.* [Nedret Mahmut, Enver Mahmut, 2004, б. 208] – *Башны ташка орсаң – таш ярылмый, баш ярыла* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987, б. 300].

Анализ румын татарларының сомокомпонентлы паремия һәм фразеологизмнарының хәзерге татар әдәби телендә тулы һәм өлешчә параллельләре, шулай ук бер атама урынына икенче атама кулланып ясалганнары да булганын күрсәтте. Тулы янәшәлек *авыз, аяк, баш, каш, кул, күз, тел, теш, тырнак* атамалары кергән гыйбарәләрдә очрый. Сан ягыннан килгәндә, *авыз, аяк, баш, кул* соматизмнары катнашында ясалганнары күбрәк. Өлешчә параллельләр *баш, буй, авыз, аяк, тел, кул, колак, сакал йөз* кебек сомокомпонентлы паремия һәм фразеологизмнарда күзәтелә. Бер соматизм урынына икенче атама кулланган очраклар да бар: *борын, колак, теш, тырнак, чәч.* Бу исә, бер яктан, кеше әгъзаларын атый торган лексиканың һәм мәгънә, һәм фонетик төзелеше ягыннан гаять тотрыклылыгын һәм бик борынгылыгын күрсәтсә.

Язма чыганаклар Румыниядәге татарларның килеп чыгышын Кырым белән бәйли. Биредә яшәүче төрки халыкның күбесе, хәзерге кырымтатар әдәби теле формалашканчы, Румыниягә Кырым ярымутравыннан күчеп утырган һәм безнең Казан татар теленә якын ногай диалектында сөйләшкән, дигән фикер бар. Фольклор әсәрләренең телен анализлау исә Румыния татарлары формалашуда Идел буе татарлары да зур роль уйнаган дигән нәтиҗәгә этәрә һәм тарихчы, тәрҗемәче, дипломат, сәясәтче, доктор, профессор Тасин Җәмилнең «тел генә түгел, традицияләр, фольклор уртаклыгы Добруҗа татарлары формалашуда Идел буе, ягъни Казан татарларының да өлеше бар» дигән фикерен раслый [Tahsin Gemil, 2021, б. 282–283].

**Әдәбият**

*Ахунҗанов Г.Х.* Татар теленең идиомалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. 119 б.

*Әхәтов Г.Х.* Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 178 б.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда. 1 т. (А–Л). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 543 б.

*Гаффарова Ф.Ф., Саберова Г.Г.* Татарча-русча идиомалар сүзлеге. Казан, 2006. 232 б.

*Җәләй Л., Борһанова Н.Б., Мәхмүтова Л.Т.* Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1957. 247 б.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959, 1963, 1967.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда. 2 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 954 б.

*Исәнбәт Н.* Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 495 б.

*Исәнбәт Н.* Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 365 б.

Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов / под ред. Ф.И. Тагировой и Ф.Ф. Гаффаровой. Казань: ИЯЛИ, 2016. 248 с.

*Сабитова И.И., Муктат Ф.И.* Халык авыз иҗаты әсәрләрендә соматизмнар (Добруҗа татарлары әкиятләре мисалында) // Фәнни Татарстан, 2020. № 3. Б. 7–14.

*Срезневский И.И.* Мысли об истории русского языка. М.: Либроком, 2007. 136 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I том: А–В. Казан: ТӘһСИ, 2015. 712 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: II том: Г–Й. Казан: ТӘһСИ, 2016. 748 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: III том: К. Казан: ТӘһСИ, 2017. 744 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: IV том: Л–Р. Казан: ТӘһСИ, 2018. 760 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: V том: С–Т. Казан: ТӘһСИ, 2019. 908 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: VI том: У–Я. Казан: ТӘһСИ, 2021. 912 б.

Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 591 б.

Dobruca kırımtatar ağzı sözlüğü. T. 1. A–D. Köstence, 2011. 550 b.

Dobruca kırımtatar ağzı sözlüğü. T. 2. E–O. Köstence, 2011. 567 b.

Dobruca kırımtatar ağzı sözlüğü. T. 3. Ö–Z. Köstence, 2011. 565 b.

*Nedret Mahmut, Enver Mahmut*. Atalar sözi. Köstence: EX PONTO, 2004. 470 b.

*Tahsin Gemil.* Tanarii: relatii cu otomani şi romani. Cluj Napoca: Presa Universitara Clujena, 2021. 430 b.

***Сабитова Илһамия Исламетдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145´373

***Ә.К. Булатова***

# ДИАЛЕКТАЛЬ СҮЗЛӘРНЕҢ ЭТИМОЛОГИЯСЕ
## (Чувашия Республикасына комплекслы экспедиция вакытында теркәлгән лексик берәмлекләр мисалында)

Ценнейшим источником изучения этимологии татарского языка являются диалектные слова. Семантическая реконструкция диалектной лексики позволяет проникнуть в историю функционирования слова в диахронии. Важную роль имеет диалектный материал, этимологизируемый исследователем, который сам и записывал его, так как есть возможность его проверить. В статье предлагается историко-этимологический анализ лексических диалектизмов, зафиксированных в речи татар, проживающих в Чувашской Республике, в ходе научной экспедиции в 2022 году.

**Ключевые слова:** диалектология, татарский язык, западный диалект татарского языка, лексема, этимология, дрожжановский говор, диалектная этимология.

Dialect words are the most valuable source for studying etymology. Semantic reconstruction of dialect vocabulary allows us to penetrate into the history of the functioning of the word in diachrony. Dialect material etymologized by the researcher who wrote it down himself has a particularly important role since it is possible to check it. The article offers a historical and etymological analysis of lexical dialectisms recorded in the speech of Tatars living in the Chuvash Republic during a scientific expedition in 2022.

Диалект системасында тел үсешенең хәзерге этабына хас булган күренешләр урын ала. Дөньяда барган техник прогресс авыл тормышының икътисади һәм иҗтимагый өлкәләренә зур йогынты ясый, шул рәвешле аерым сөйләшнең (сөйләшләрнең) яшәеше, аның әдәби тел белән бәйләнешлары да берникадәр үзгәрергә мөмкин. Телдә барган процесслар, шулай ук сөйләш вәкилләренең башкалар белән аралашуы нәтиҗәсендә, сөйләшкә хас үзенчәлекләрдә аерымлыклар барлыкка килә. Шуңа нисбәтле аерым сөйләшнең торышын һәм үсешен өйрәнү татар диалектологиясе өчен актуаль мәсьәлә булып кала.

Диалектлар – телнең беренчел универсаль формасы. Әдәби тел тәэсирендә алар үзгәрә, ләкин халык сөйләме диалекталь характерда булып калырга мөмкин. Милли татар теле барлыкка килгән чорда гомумхалык теле һәм диалектлар нисбәте үзгәрә. Яңа диалекталь үзенчәлекләрне үстерү тукталып торырга, диалектлар күбесенчә авыл халкының сөйләменә күчәргә мөмкин. Акрынлап алар әдәби телнең кайбер нормаларын кабул иткән диалектларга әверелеп, үзенчәлекләр арасындагы аермалар юкка чыга. Шул сәбәпле, диалектларны вакытында өйрәнү зарур. Диалектлардагы тел материалы – зур хәзинә,

анда чыннан да бихисап архаик сүзләр һәм әдәби телдә күптән югалган формалар саклана.

Әлеге мәкаләдә экспедиция барышында теркәлеп барган аерым лексик диалектизмнарның этимологиясе һәм кулланылыш үзенчәлекләре тикшерелә. ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Чувашия Республикасының Батыр, Комсомол, Шомыршы районнарына оештырылган комплекслы экспедициясе егерме бер торак пунктта (Озын Куак, Шыгырдан, Кызыл Камыш, Кызыл Чишмә, Яңа Чепкас, Татар Согыты, Татар Тимәше, Кече Шыгырдан, Кыр Бикшиге, Имәнкисәге (Батыр районы), Тукай, Урмай, Чичкан, Татар Шырты (Шырт), Әлебаш, Татар Юашкасы, Каенлык, Әхмәт (Комсомол районы), Өч Балтай, Байтирәк, Әсән (Шомыршы районы) авыллары) эшләде. Кыр тикшеренүләре барышында татар халкының милли-мәдәни мирасы, авыз иҗаты, сәнгате, музыкасы, археографиясе, эпиграфикасы белән бергә әлеге төбәктә яшәүче татарларның сөйләш үзенчәлекләре дә өйрәнелде, күп кенә лексик диалектизмнар теркәлде.

Этимологик эзләнүләр, берникадәр шартлы, фараз характерында булуга карамастан, аерым бер лексик берәмлекнең килеп чыгышын һәм телдә яшәешен ачыкларга ярдәм итә. Шул ук вакытта сүзнең этимологиясен билгеләү кыенлыклар тудыра.

Диалектизмнар – этимология фәне өчен бай чыганаклар. Тел белемендә диалекталь этимология дигән махсус юнәлеш тә яшәп килә. Әлеге термин диалекталь лексиканың генезисын (аерым сүзләр яки яисә лексик-семантик төркемнәр мисалында) тикшерүне һәм диалекталь лексика семантикасын анализлауны күздә тота. Ике очракта да диалектологиягә мөрәҗәгать итүнең үз спецификасы бар, бу материалның үзенчәлеге диалекталь лексика белән билгеләнә [Откупщиков, с. 15; Варбот, с. 41].

Диалектларда яшәп килгән бик күп сүзләр татар әдәби теленә үтеп кергән. Әмма җирле сөйләшләрдә генә кулланыла торган лексик берәмлекләр дә шактый. Сүзләр телнең универсаль законнары нигезендә эволюция кичерәләр. Кайчандыр телдә кулланылышта йөргән берәмлекләр тора-бара әдәби телдән төшеп калырга, пассивлашырга, искергән сүзләр булып китәргә, шул ук вакытта аерым бер диалект яисә сөйләштә (сөйләшләрдә) сакланып калырга мөмкиннәр. Шуны да искәртү зарур, әдәби телдән җуелган сүзләр аерым бер чыганакларда, белешмәлек-сүзлекләрдә теркәлеп калалар, диалект милли телнең сөйләмә формасы булганлыктан, андагы кулланылыштан төшеп калган сүзләрне исә инде табып, өйрәнеп булмаячак. Шул сәбәпле диалекталь сүзләрне теркәү, анализлау – актуаль һәм мөһим юнәлеш.

Чувашия Республикасында урнашкан татар авылларында татар теле көнбатыш диалектның чүпрәле сөйләшендә сөйләшәләр [Татар халык сөйләшләре, 2 кит., б. 195]. Лексик яктан татар теленең көнбатыш диалектында яшәгән лексемалар кулланыла. Шул ук вакытта әлеге сөйләшкә генә хас сүзләр дә шактый. Кайберләрен анализлап узыйк.

***Ыргача*** / ***ыргацы*** *[ɤrgača / ɤrgatsɤ]* – ‘гадәттә күннән, тупас тукымадан, брезенттан һ.б. тегелгән, эшләгәндә файдаланыла торган биләй, эш бияләе (руковицы, верхонки)’, диалекталь сүзлекләрдә әлегә кадәр теркәлмәгән. Мисал: / *Кырцылар ыргацы киеп эшлиләр* /. (Чичканлы авылы) Килеп чыгышы ягыннан *ыргыт-у* ‘ату, ору’ нигезеннән дип каралырга мөмкин: < гомумкыпчак *ырғыт-* «бросать, бросить; кидать, швырять» [Әхмәтьянов, Т. II, б. 505]. Лексема барлык торак пунктларда да кулланылышта йөри.

Без өйрәнгән төбәктә ***эленге*** *[elenge]* сүзе актив кулланыла, ул ‘берәр нәрсәне каплап яки аерып торган тукыма кисәге, пәрдә, тәрәзә пәрдәсе (занавеска)’ мәгънәсендә йөри һәм гомумтөрки *эл-ү* ‘әйберне салындырып, асып кую’ [ТТАС, т. IV, б. 699] фигыленә кайтып кала: гомумтөрки *ил-< иил- элү* [Әхмәтьянов, Т. II, б. 511]: / *Игәцем эленгене* ${}^{т}$*чуwаш аwылыннан апка*${}^{й}$*ткан ие* / (Әлебаш авылы). Әлеге сүз шулай ук көнбатыш диалектның ләмбрә сөйләшендә очрый [ТТЗДС, б. 804].

***Сәленцәк*** / ***сәлемчәк*** *[sälentsäk / sälemčäk]* лексемасы сөйләштә ‘атынгыч, таган (качели)’ мәгънәсендә кулланыла (ТТЗДС, 567 б.): / *Зур әтисе оланга сәленцәк ясап бирде* / (Татар Юашкасы авылы); торак пунктларда актив файдаланыла. Килеп чыгышы ягыннан *сәлен-ү* – **сәл-* гомумтөрки *сал-* ‘селкетү, җилфердәтү’, *сал* ‘җилфердек’ сүзеннән [Әхмәтьянов, т. II, б. 153].

***Чыхым*** *[čɤhɤm]* лексемасы казан татарлары, яисә чылаштырып сөйләшүчеләргә карата кулланыла [ТТЗДС, б. 775]: / *Сез бигрәк чыхымца сүләшәсез икән* / (Әсән авылы). Сүзнең этимологиясе ачык түгел, чылаштырып сөйләшүчеләргә карата үртәү формасы булырга мөмкин. Әлеге лексема чүпрәле сөйләшендә генә файдаланыла дип карала, диалектологлар тарафыннан әлеге сөйләш вәкилләрендә генә теркәлгән. Шуны да әйтергә кирәк, лексема актив кулланылмый. Кайбер торак пунктларда сүзне белмиләр, өлкән буын вәкилләренең кайберләре генә куллана.

***Неwеш*** / ***нүwеш*** / ***нүеш*** *[neweş / nüweş / nüeş]* лексемасы көнбатыш диалектның чистай, сергач, чүпрәле, мәләкәс, шарлык сөйләшләрендә очрый һәм ‘өй почмагы, йортның эчке почмагы (внутренний угол дома)’ мәгънәсенә ия [ТТЗДС, б. 500], әлеге сүз актив кулланылышта йөри: / *Алты нүwешле ызба* / (Өч Балтай авылы). (Әдәби телдә бу мәгънәгә туры килгән *почмак* сүзе семантик диалектизм буларак сөйләштә ‘аш бүлмәсе’ мәгънәсендә йөри). Килеп чыгышы турында бердәй фикер юк. *Нүвеш* < *мөйөш* – «‘*мөгез*’ белән ‘*мөеш*’ төшенчәләренең борынгы бердәйлеге шикле. М. Рясянен бу сүзне борынгы **тиŋil* ‘болын, елга борылышы’ сүзе белән чагыштыра, ләкин көнчыгыш диалектта *мөйәшә, мүәшә* варианты бу фикергә каршы» [Әхмәтьянов, б. 47].

***Кабак*** *[kabak]* – ‘капка, капу (ворота)’. Әлеге сүз татар әдәби телендә искергән, кулланылыштан төшеп калган дип карала [ТТАС, т. III, б. 54]. Лексема көнбатыш диалектта актив кулланыла: / *Кабак-*

*ларынны ацып куй, кунаклар килә* / (Шыгырдан авылы). Этимологиясенә килгәндә, *кап-у* нигезеннән булырга тиеш: борынгы төрки *qapиγ, qapïγ, qapaγ* ‘капка, ишек’ ← **қаап-* ‘ябу, каплау’ фигыленнән [Әхмәтьянов, т. I , б. 365].

Без язып алган диалектизмнар арасында башка телләрдән кергән алынма сүзләр дә яшәп килә. Мәсәлән, шундыйларга без *мажит* сүзен кертеп карый алабыз.

***Мажыт*** / ***мажит*** *[majɤt / majit]* ‘кашага, өй стенасының югары өлешенә, ишек, тәрәзә башларына эленә торган бизәкле озын тукыма; пәрдә (бордюр)’ [ТТЗДС, б. 462]. Рус теленнән кергән, *манжета* сүзеннән дип каралырга мөмкин. Чүпрәле сөйләшеннән тыш тархан сөйләшендә дә урын алган: / *Хәрендәшем мажытлар циккән ие* / (Байтирәк авылы). Җирле халык күп очракта элеге сүз һәм ул белдерә торган предметны *түрләмә* дип тә аңлата (диалектологик сүзлекләргә *түрләмә* урта диалектның лаеш, минзәлә сөйләшләрендә кулланыла торган һәм ‘кашага’ мәгънәсендәге диалектизм буларак күрсәтелә [ТТЗДС, б. 667]). Хәзерге көндә өйләргә кашагалар эленми, бирнәлеккә дә әзерләнми. Алар олы яшьтәге апаларның бирнә сандыкларында яисә авыл музейларында гына саклана, шуңа күрә сүз кулланылыштан төшеп калырга мөмкин. Шулай да, аерым ассоциатив билгеләрдән чыгып, әлеге сүз белән башка бер предметның атамасына күчәргә мөмкин дип фаразларга мөмкин: бер респондент өендә эленгән тәрәзә пәрдәсенең ламбрекенын *мажҫыт* дип атады (Татар Шырты авылы).

***Барига*** *[bariga]* – ‘бияләй’. Сүз көнбатыш диалектка караган күп сөйләшләрдә файдаланыла: / *Баригаларым бик матур килеп цыкты* / (Татар Шырты авылы). Этимологиясенә килгәндә, рус теленең *варега, варежка* лексемасыннан.

***Тәнкәл*** *[tänkäl]* лексемасы ‘артсыз урындык, утыргыч (табурет)’ мәгънәсендә йөри: / *Яна тәнкәл алган ием* / (Чичканлы авылы), урта диалектның дөбьяз, көнбатыш диалектның чүпрәле, тау ягы керәшеннәре сөйләшләрендә актив кулланылышта [ТТЗДС, б. 618]. Диалектизм чуваш теленнән, *тенкĕл* ‘артсыз урындык, табурет’ сүзеннән алынган [Электронный словарь].

***Ләкшә*** / ***эләкшә*** *[läkşä / eläkşä]* – татар теленең күп сөйләшләрендә кулланыла торган диалектизм, ‘токмач, ашка салыр өчен, җәймәне озынча итеп вак-вак кисеп ясалган камыр эшләнмәсе’ мәгънәсендә. *Ләкшә* сүзе рус теленең *лапша* сүзеннән алынган булырга мөмкин, рус диалектларында *локша, лохша*), шул ук вакытта борынгы төрки *laqš, laqša* ‘бодай оны; токмач’ [Әхмәтьянов, б. 535].

Кайбер торак пунктларда ***какал*** *[kakal]* лексик берәмлеге язып алынды, әлеге сүз диалектологик сүзлекләрдә шулай ук норлат сөйләшендә теркәлгән. Сүз ‘үрдәк (утка)’ мәгънәсендә йөри [ТТЗДС, с. 268]. Лексик берәмлек чуваш теленнән кергән – кăвакал ‘үрдәк’ [Электронный словарь].

***Лаука*** / ***лаукы*** *[lauka / laukɤ]* – ‘кечерәк кибет (магазинчик)’. Рус теленең *лавка* сүзеннән алынган. Көнбатыш диалект сөйләшләрендә

актив кулланыла торган лексик берәмлек: / *Лаукыга цыккан ием, товар кайткан ди* / (Шыгырдан авылы).

Шулай итеп, Чувашия Республикасына оештырылган комплекслы экспедиция барышында без әлеге төбәктә яшәүче татарларның телендә көнбатыш диалектның чүпрәле сөйләше үзенәчлекләре күзәтелә дигән нәтиҗәгә килдек. Безнең тарафтан берничә дистәдән артык лексик диалектизм теркәлде. Аларның күбесе – гомумтөрки сүзләр. Төбәктә татарлар башка милләтләр белән тыгыз аралашып яшиләр. Шул сәбәпле диалекталь лексиканың алынма сүзләр исәбенә дә баюы күзәтелә.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. Т. 1. 543 б; Т. 2. 567 б.

*Варбот Ж.Ж.* Из опыта диалектной этимологии // Этнолингвистика. Ономастика. Этимология. Материалы международной научной конференции. Екатеринбург, 2009. С. 41–42 // http://www.philology.ru/linguistics2/varbot-09.htm [дата обращения 10.03.2023]

Материалы к идеографическому словарю диалектов татарского языка / авт.-сост.: А.Г. Шайхулов, Л.У. Бикмаева, З.Р. Садыкова. Т. 1., ч. 2. Уфа: РИО БашГу, 2005. 506 б.

*Откупщиков Ю.В.* Очерки по этимологии. СПб.: Изд-во С.-Петерб. ун-та, 2001. 480 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 6 томда. Казан: ТӘҺСИ, 2015. Т. 1. 712 б.; Т. 2. 2016. 748 б.; Т. 3. 2017. 744 б. Т. 4. 2018. 760 б.; Т. 5. 2019. 908 б.; Т. 6. 2021. 912 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

Татар халык сөйләшләре: Ике китапта. 2 нче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретидинова һ.б. Казан: Татар. кит. нәшр. , 2008. 463 б.

Электронный словарь // http://samah.chv.su/s/ [дата обращения 10.03.2023]

***Булатова Әлфия Кәрим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82.091

***Ә.М. Шәрипов***

# СИРИН ИҖАТЫНДА 1930 ЕЛЛАР СОВЕТ ЧЫНБАРЛЫГЫ ЧАГЫЛЫШЫ

Статья посвящена творчеству татарского поэта Сирина (Батыршина Сирина Ханифовича) (1896–1969). Автор раскрывает малоизвестные страницы биографии поэта. В статье акцентируется внимание на творчестве поэта в 30-е годы XX столетия. В своем анализе автор прослеживает особенности развития творчества Сирина, изучает проблему синтетизма в татарском стихотворном жанре, реконструирует целостную картину жизненных реалий, запечатленных в стихотворениях поэта.
**Ключевые слова:** творчество поэта Сирина, основные жанровые стратегии, художественное развитие, поэтапные особенности.

The article is devoted to the work of the Tatar poet Sirin (Batyrshin Sirin Hanifovich) (1896–1969). The author reveals little-known pages of Pot's biography. The article focuses on the poet's work in the 30s of the XX century. In the analysis the author traces the peculiarities of the development of Sirin's creativity in the 30s, studies the problem of synthetism in the Tatar poetic genre, reconstructs a holistic picture of the realities of life captured in the poet's poems.
**Keywords:** creativity of the poet Sirin, the main genre strategies, artistic development, step-by-step features.

*(дәвамы)*
*Башы журналның 2022 елның 4 нче санында*

1930–1935 елларда Сирин иҗаты киң колач белән үсеп китә, үзенең иң югары ноктасына җитә. Ул халкыбызның үзенчәлекле, популяр шагыйрьләренең берсенә әверелә. Бу елларда ул шул заманның актуаль мәсьәләләрен күтәргән камил, атаклы әсәрләрен иҗат итә. Мәсәлән, зур күләмле «Булмый! Булмый!» шигыре (1930) шул вакытның иң көнүзәк мәсьәләсе – авыл хуҗалыгын коллективлаштыру темасына багышланган. Әсәр нигезенә «машиналы күмәк тормыш төзеп җибәр!» дигән идея салынган. Бу фикерне автор укучы күңеленә антитеза алымы ярдәмендә җиткерә: бер якта – «милек, минлек», ягъни хосусый милеккә нигезләнгән иске тормыш; икенче якта – «машиналы күмәк тормыш», ягъни иҗтимагый милеккә нигезләнгән яңа җәмгыять, яңа тормыш. Күмәк тормышның өстен һәм файдалы икәнлеген шагыйрь күмәк хуҗалыкка әле кермәгән авыл кешесе аңына да тәэсир итәрлек гади сүзләр белән бирә. Бу – авторның гади крестьян белән шигъри телдә сөйләшүе булып чыккан. Ул авыл кешеләрен бергәләп яшәргә, тормышның иске «чүп-чарларын җилгә җибәрергә» чакыра:

*Ашлыгыңны җилгәрәмсең,*
*Җилгәр,*
*Җилгәр.*
*Тормышыңның*
*Чүп-чарларын*
*Җилгә*
*Җибәр.*
*Бертуган күк*
*Бергә эшлик,*
*Бергә яшик.*
*Машиналы*
*Күмәк тормыш*
*Төзеп җибәр.*
*Аерым-аерым*
*Матур тормыш*
*Булмый, булмый!*
*Булмый, булмый!*

*Ашлыгыңны җилгәрәмсең, җилгәр, җилгәр* сүзләрен рефрен итеп куллана, һәр кулланган саен алар әсәрнең иҗтимагый мәгънәсен тирәнәйтә баралар.

Автор һәр кешенең үзе өчен генә яшәвенең ялгыш булуын, ялгыз милекчелекнең нигезсез, перспективасыз икәнлеген исбатлый. «Мин-минлек белән яшәү» аркасында кешеләр бер-берләреннән көнләшәләр, күршесе күршесенә карата астыртын ут йөртә, иске тормыш билгесе булган тешсез сука белән генә алга барып булмаячагын әйтә:

*Машинасыз тормыш авыр, юк иптәшең,*
*Майламаган тормышыңның тәгәрмәчен.*
*Якын итеп кенә матур бер сүз әйтим:*
*Сукалы карт, тормышыңны суксын яшен! –*

ди шагыйрь һәм крестьяннарны күмәкләшергә, колхозлар төзеп яшәргә чакыра.

Шагыйрь Әхмәт Исхак үзенең истәлекләрендә болай дип яза: «1923 елның суык бер кичендә миңа Казанда әдәби кичәдә булырга туры килде. Мин барып кергәндә, уртача яшьтәге, уртача буйлы, саргылтрак чәчле бер егет яңгыравык тавыш белән шигырь сөйли иде.

Шагыйрь Сирин белән без әнә шулай таныштык... 1931–1932 елларда аның тагын бер шигыре гаять зур популярлык белән халык арасына таралды. Бу аның ялгызак игенчеләрне күмәкләшүгә чакырган “Булмый! Булмый!” дигән шигыре иде. Аны укымаган артист һәм ул шигырь укылмаган кичә яки концерт булмагандыр. Казанда гына түгел, республикабызның авылларында да ул иң күп укылган һәм сөйләнгән шигъри әсәргә әверелде. Ул әсәрне хәтта татарның мәшһүр артисты Мөхтәр Мутинның Татар педагогия институтындагы кичәдә укыганын үз колагым белән ишеткәнем бар. Ул шигырь белән бәйле бик кызык вакыйганы миңа язучы Закир Гали сөйләде.

Пароходта барганда ул Әҗәкүл пристаненда шундый хәлгә юлыккан: пароход туктап торганда, бер үсмер малай пассажирларга кычкырып-кычкырып шул шигырьне укый икән:

*Аерым-аерым*
*Матур тормыш*
*Булмый, булмый!..*
*Ялгыз-ялгыз*
*Матур тормыш*
*Булмый, булмый!..*

Шулвакыт пристаньга бер татар милиционеры килеп чыккан һәм малайны, бик коры тотып, куып җибәргән:

– Йөрмә монда контр сүзләр таратып! Совет властенда булмаган нәрсә юк! Тай моннан, тай!

Бер очраганда бу вакыйганы мин Сириннең үзенә сөйләдем. Сирин рәхәтләнеп көлде.

Әйе, чын шигырь язмышы – кешеләр язмышы шикелле үк: алар да мәзәк хәлләргә юлыккалый шул. Һәм шагыйрь Сиринне мин әле дә һаман шулай яңгыратып көлеп торган, шат хәлендә күз алдыма китереп искә алам» [Исхак, 1987].

Язучы Локман Бадыйкшан да Сириннең 1930 еллар иҗаты турында болай ди: «Сириннең «Тамчылар» дигән шигыренә ул елларда кайсыдыр композитор көй дә язган. Без, укучылар, аны җырлап та йөрдек. Гомумән, ул елларда яшь шагыйрь Сирин шигырьләрен укучы мәктәп балалары гына түгел, бик күп татар яшьләре яттан белә иде. Ә инде «Булмый, булмый» дип аталган атаклы шигырен әниләренең итәкләренәябышып йөргән нәниләр дә «бытылдап» йөриләр иде. Менә шуның өчен дә шагыйрь Сирин татар поэзиясендә утызынчы еллар күгендә үзенә генә хас трибун шагыйрь булып калды да» [Бадыйкшан, 1997].

«Күп тарат!» (1930) шигырен Сирин Коммунистлар партиясенең XVI съезды карарларын йөреп аңлату өчен физкультурачылардан төзелгән эстафетага багышлаган. Ул анда рульдә утыручыларны съезд карарларын тизрәк халыкка җиткерергә, «уңга», «сулга» китмичә, туп-туры, Ленин юлыннан барырга чакыра.

«Микроскоплы күзләр» шигыре интернационализм идеясе белән сугарылган. Шагыйрь анда үзенең студент булуы белән горурлана, үзенең бер милләт эчендә генә чикләнеп калмавын әйтә:

*Милләт,*
*Милләт, диләр,*
*Милләтчеләр.*
    *Милләт сүзе*
        *бик тар,*
            *чикләнә.*
*Ә мин,*
    *менә,*
        *шундый аңлый беләм:*

*Һичбер*
*милләт эченә*
*бик - ләң - мәм!*

Шагыйрь милләтләр арасына коткы таратучыларга каршы чыга:

*Урыс та бар бездә,*
*татар да бар,*
*чуваш та бар*
*безнең арада.*
*Кайсы милләтчеләр*
*киртә сала*
*сезнең белән*
*безнең арага!*

Автор үзенең бөтен күңеле белән интернационализмны яклавын әйтә, шул идея белән зур биеклекләр яулап алачагына ышана:

*Бәйнәлмиләл күрә*
*безнең күзләр.*
*Бәйнәлмиләл тибә йөрәкләр.*
*Бәйнәлмиләл тыңлый*
*безнең колак,*
*Бәйнәлмиләл булгач теләкләр.*
*Без – студент,*
*микроскоплы күзләр*
*бездә,*
*гигант*
*белем ярышы!*
*«Без җитәрбез,*
*узып китәрбез»*
*Европаның*
*барышын!*

* * *

1932 елда да НКВД тарафыннан Сиринне чакыртулар, аңардан сорау алулар дәвам итә. Үзенең автобиографиясендә шагыйрь бу турыда болай яза:

«Бөтен эштән күңел кайтты. Язарга мөмкинлек юк. Яшәргә мөмкинлек, ашарга мөмкинлек юк. Үземне үзем үтерүгә генә мөмкинлек бар...

Бервакыт мине дә Язучылар союзы ябык лавкага беркеткән иде. Бер генә ай файдаланып калдым. Икенче айда сызып та ташлаганнар. Димәк, миңа ашамасам да ярый. “Яшәү мөмкинлеген кешегә кайда бирәләр соң? Минем дә ашыйсым, минем дә яшисем килә!” дип, урамда кычкырасым килде» [Батыршин, б. 153].

1933 елда Сирин үзенең төрмәдә булуын «Син кайда булдың?» диючеләргә» дигән шигырендә болай сурәтли:

*Мин булдым шунда,*
*Кайдадыр шунда,*
*Сандугачлар оя ясамый.*

*Мин булдым шунда,*
*Кайдадыр шунда,*
*Чыпчыклар да килеп сайрамый.*
*Мин булдым шунда,*
*Кайдадыр шунда,*
*Җәйге җылы җилләр исмиләр.*
*Мин булдым шунда,*
*Кайдадыр шунда,*
*Гөлсириннәр, гөлләр үсмиләр.*
*Булды көннәрем,*
*Бетте өннәрем,*
*Бер сүз сөйләшергә җөдәдем.*
*Иректә йөргән,*
*Матур көн күргән*
*Чебеннәрнең көнен көнләдем.*

Сирин мондый кулга алуларның яшерен рәвештә эшләнүен, кешеләрдә курку атмосферасы тудыруын, бу турыда беркем белән дә киңәшеп, сөйләшеп тә булмаганлыгын әйтә:

*Мин булдым шунда,*
*Кайдадыр шунда,*
*Октябрьгә үчле дошманнар...*
*Бер сүз әйтергә,*
*Их!*
*Сөйләшергә!*
*Беркем дә юк безнең дуслардан!*

Шигырь ахырына «Әче хатирә. 29/VII–33» дип язып куелган.

Киләчәкнең нинди булачагын белмәү, тотрыксызлык, һәр көнне, һәр минутта үзеңне алып китүләрен көтеп яшәү шагыйрь күңелендә давыл куптара. Шулай итеп, Сирин иҗатына хәтта үлем темасы да килеп керә (һәм бу гаҗәп тә түгел. – *Ә.Ш.).* Күңеленең бәргәләнүен Сирин «Хис» шигырендә (1933 елның 29 сентябрендә язылган) болай тасвирлый:

*Минем йөрәк,*
*Анда хисләр,*
*Көчле хисләр өзелеп тартыша.*
*Нишлим?*
*Кайсы җиңәр?*
*Йөрәк барыр*
*Кемгә, кайсына?*
*Муенгамы баулар салып,*
*Үз-үземне тотып асыйммы?*
*Әллә шунда –*
*Кабан буйларына барып,*
*Сасы күлгә күмим башымны?*
*Белмим!*
*Йөрәк сагышлы!*
*Әй, буа йөрәкне!*

Шагыйрь кая барып бәрелергә, кемнән ярдәм сорарга белми:

*Нишлим?*
*Кемнәр киңәш бирә?*
*Кемнәр аңлый минем хәлемне? –*

дигән сорау куя. Һәм ул хәтта әҗәлгә мөрәҗәгать итә, әҗәлне үзенә чакыра:

*Әй, әҗәл!*
*«Матур» әҗәл!*
*Килче әле минем каршыга!*
*Килче, бәгърем,*
*Сөй син мине,*
*Булчы минем карчыгам!*

Күңеле белән Сирин инде чыннан да бу тормыштан китәргә әзерләнә, тормыш белән хушлашуга кадәр барып җитә. 1934 елның 23 ноябрендә язган «Хушыгыз!» шигырендә (аның бер варианты «Кыш сайрамый сандугач» дип атала) мондый юллар бар:

*Хушыгыз, әй, дусларым,*
*Дус-ишләрем, хуш, мин китәм.*
*Мәңге дә кайтмам инде,*
*Күрешмәбез инде бүтән.*
*Ут төртәм таудай теләккә,*
*Җан сөйгән эшләремә.*
*Чик куям антым белән мин*
*Дөрләп торган хисләремә.*

Һәм шигырьне болай тәмамлый:

*Хушыгыз, таллар, юкәләр,*
*Хуш, сөекле алмагач!*
*Нишләсен шагыйрь Сиринең, –*
*Кыш сайрамый сандугач.*

Сирин әле бу шартларда да ихлас күңелдән Коммунистлар партиясе яклы булып кала. Бунтарь йөрәгендә кайнаган хис-тойгыларны тезгенләп, совет идеологиясе таләпләренә җавап бирә торган әсәрләр иҗат итә. Ул иҗади эзләнә, милли чикләнгәнлек рамкаларында гына калырга теләми, классик рус һәм дөнья поэзиясен өйрәнә. Нәтиҗәдә аның иҗатының тематикасы, офыгы киңәя, каләме чарлана, шагыйрьнең үз-үзенә ышанычы арта. Аның Маяковскийга ияреп язган «Идәнгә төкермәгез!» (1928), «Кытай җыры (Кытай шагыйре Ши-Кингтан)» (1928), «Һейне фикере» (1929) кебек әсәрләре Сириннең үз өстендә җитди эшләгәнлеген күрсәтеп тора.

Әмма Коммунистлар партиясе идеяләренә ихлас күңелдән бирелгәнлеге, совет системасының кешеләргә яхшы, матур тормыш бирәчәгенә ышанычы шагыйрьнең гомере буена бармый. Ул җәмгыятьтәге гаделсезлекләр, аларның нигезе турында уйлана. Еллар буе совет җәмгыятенең чын патриоты булып та, үзен һаман гаепләүләре,

эзәрлекләп торуның сәбәбен аңларга тели. Һәм әкренләп моны төшенә: тышкы яктан кызыл лозунглар белән төреп алынган совет системасында мәкерлелек, астыртынлык, алдашу, кыерсыту, байлык бүлешү ятканлыгын һәм үзенең шул система эчендә яшәргә мәҗбүр булуын аңлап ала. Аның ирек сөюче бунтарь җаны мондый икейөзлелеккә, мәкерлелеккә нәфрәт белән тула һәм ул гаделсезлекләргә каршы көрәш ача. Сирин иҗатында борылыш башлана: ул бер-бер артлы совет системасының чын йөзен фашлый торган әсәрләр иҗат итә башлый. Аның 1930–1935 еллардагы иҗаты тулаем диярлек совет җәмгыятендәге гаделсезлекләрне, тискәре күренешләрне тәнкыйтьләүгә багышлана. Ачы сатира барлыкка килә. Нәтиҗәдә, ул кулга алынып, биш ел буе гаҗәеп рәхимсез, кеше ышанмаслык кыргый тәртипләр хөкем сөргән Сиблаг лагерьларында җәфа чигәргә мәҗбүр була.

1932–1935 еллар – Сирин иҗатының иң каршылыклы һәм иң катлаулы чоры. Күңеле бәргәләнгән, кемгә ышанырга да белмәгән шагыйрь нинди генә темаларга язмый бу елларда! Иң элек эзоп теленә мөрәҗәгать итеп, җәмгыятьтәге тискәре күренешләрне мәсәл жанры аша камчылый: «Кәҗә белән сарык» (1931), «Сатучы һәм сатып алучы» (1932), «Карга белән саескан» (1934), «Ишәк белән куян» (1935) һ.б. «Сатучы һәм сатып алучы» мәсәлендә ул власть башында утыручыларның ил байлыгының иң зур өлешен үзләштереп, гади халыкка бик азын гына калдыруларын һәм шуны әйтмәсен өчен, гади халыкның «телен кисеп алуларын» образлы итеп тасвирлап бирә. Сатып алучының үзе сатып ала торган үрдәкнең теле юклыгын күреп, «Аның теле кая киткән?» дигән соравына сатучы:

*Теле булган аның, син кайгырма,*
*Тик соңыннан шулай иткәннәр:*
*Түшен кем ашаганны сиңа*
*Әйтмәсен, дип, телен кискәннәр, –*

дип җавап бирә.

1933 елда Сирин «Сугышка каршы Халыкара конгресста Сириннең сөйләгән беренче рече» дигән фәлсәфи-публицистик поэма иҗат итә. Бу әсәр язылган елларда Европа илләре һәм халыклары арасында тынычлык өчен, илләр һәм дәүләтләр арасында сугышны булдырмау өчен халыкара хәрәкәт бара. Сирин дә үз әсәрендә шул мәсьәләләрне күтәрә. Хыялында ул үзен сугышка каршы Халыкара конгресста чыгыш ясаган итеп күрә һәм шул форумда әйтергә уйлаган фикерләрен әлеге әсәрендә бәян итә. Бу киң планлы поэманы Сирин тугыз бүлеккә бүлгән, һәр бүлекне бер халыкара-фәлсәфи мәсьәләгә багышлаган. Ә гомумән алганда, поэманың төп мотивы – дәүләт белән шул дәүләттә яшәүче кешенең үзара мөнәсәбәте. Бу мөнәсәбәт илләр-дәүләтләр арасында тынычлыкны саклау зарурлыгы турындагы фикерләргә бәйләп күрсәтелә. Шул фикерләрне бәян итү барышында Сирин совет җәмгыятендә хөкем сөргән гаделсезлекләрне һәм аерым бер кешенең хокуксызлыгын да күрсәтә барган. Беренче бүлектә шагыйрь үзенең бу халыкара форумда сүз алып сөйләргә хакы барлыгын исбатлый;

икенчесендә: «коралсызлану» дигән сүз, төптән уйлап караганда, ул «кораллану» дигәнне аңлата; ә ул бит без – эшчеләр эшләп тапканнар исәбенә башкарыла. Нәтиҗәдә күпме сугыш кораллары барлыкка килә, ди. Дәүләт җитәкчеләренә Сирин болай дип мөрәҗәгать итә:

*Кемгә бирерсез ул коралларны?*
*Кемгә кирәк сезнең сугышыгыз?*
*Эшчеләрнең анда ни катнашы бар?*
*Бик кирәксә, үзегез сугышыгыз!*
*Кемнәр бүген сугышка сусаган,*
*Шул кешеләр корал алсыннар!*
*Шул кешеләр канлы фронтларда*
*Бер-берсенә каршы барсыннар!*

Өченче бүлектә залдан берәү торып баса да: *«Нигә шагыйрьгә сүз бирәсез? Хәзер туктатыгыз аның сүзен!»* – ди. Сирин аңа: *«Йөз миллионнар миңа рөхсәт бирә. Мин сездән сүз сорап тормыйм!»* – дип җавап бирә.

Дүртенче бүлектә шагыйрь: *«Хиссез дәүләт һәркөнне / Яшәү шартларыннан файдаланып / Кол итәргә мөмкин һәркемне, ...Бездә чын дөреслекне сөйләү тыелган»*, – ди дә, үзенең бер фаразын сөйли:

*Әгәр бер үлгән кеше,*
*кайтып басса дәүләт каршына,–*
*Һәрбер хаклык өчен аяк терәп,*
*Үз каршыңда егылып талашса,*
*«Безне үтереп көн күрәләр бит», – дип,*
*Халыкларга сөйләп аңлатса, –*
*Их, бичара дәүләт, нишләр идең?*
*Нишләр идең син бу кешегә?*
*Тик ул гына дөреслекне сөйләр,*
*Башын имәс ул һичбер кемгә.*

Сирин үзенең әнә шул кеше кебек чын дөреслекне сөйләүче кеше булуын әйтә: *«Мин дә шулай эшлим, шуңар миңа синең юк җәзаң»,* – ди.

Поэмада сугышның (Беренче бөтендөнья сугышы күздә тотыла) гади, гөнаһсыз кешеләрне имгәтүе, гомерлеккә гарип итеп калдыруы күрсәтелә. Дәүләтләр үз гражданнарының сәламәтлеге һәм тыныч яшәве турында кайгыртырга тиеш булсалар да, бу вазифаны үтәмиләр, киресенчә, кешеләрне сугыш эченә кертеп, гарипләндерәләр, хәтта үтерттерәләр. Сирин еш кына:

*Кеше өчен дәүләтләр яшиме?*
*Дәүләт өчен мәллә кешеләр?*
*Кеше өчен дәүләтләр яшәсә,*
*Нигә болай безнең бу эшләр? –*

дигән фәлсәфи сорау куя һәм шуңа бәйләп, үз тормышыннан мисаллар китерә:

*Алып китеп таза абыемны,*
*Кайтардыгыз өйгә аяксыз.*

*Ничек тормыш итәр инде ул?*
*Йөри алмый бит ул таяксыз.*
*Алты-җиде баласы бар иде,*
*Барысы эчтән авыр сулады.*
*Барысы бергә кочаклашып,*
*Күз-яшь белән үксеп елады.*
*Яшь балалар килеп карыйлар да,*
*Тоталар да аның таягын,*
*Бөтен дәүләтләргә кычкыралар:*
*Бирегез, дип, әти аягын!*
*Кеше өчен дәүләтләр яшиме?*
*Дәүләт өчен мәллә кешеләр?*
*Кеше өчен дәүләтләр яшәсә,*
*Нигә болай безнең бу эшләр?*

Шунда ук шагыйрь үз тормышыннан тагын бер фаҗиганы сурәтли:

*Бервакытны Җәмил абый кайтты,*
*Караганда болай берни юк.*
*Бервакытны күрсәм, исем китте, –*
*Җиң эчендә аның кулы юк.*
*Безгә белдермәскә теләгәндер, –*
*Безнең күздән яшьләр тамдылар.*
*Шул вакытта минем йөрәгемдә*
*Мәңге бетмәс утлар яндылар.*
*Аның кулы һаман төзәлмәде,*
*Күлмәкләре канга буялды.*
*Гомер буе мескен җәфаланды,*
*Шулай үтердегез, югалды...*
*Дәүләт өчен кешеләр яшиме?*
*Кеше өчен мәллә дәүләтләр?*
*Кеше өчен дәүләтләр яшәсә,*
*Нигә бетми кайгы, хәсрәтләр?..*

Җиденче бүлек шундый сүзләр белән башлана:

*Барлык дәүләтләр!*
*Тыңлагыз, тыңла!..*
*Серләр яшерен калмасын!*
*Дәүләтләрнең закон-аферларын*
*Түбән халык яхшы аңласын!..*

Бу бүлектә «гомумхалык бергә эшләп барлыкка китергән байлыкны халыкның үзенә тигез итеп бүлеп бирергә кирәк», дигән фикер үткәрелә. «Нигә ул байлыкны, халыкның үзенә бирмичә, сакчы куеп саклап тотасыз?» – дигән сорау куела:

*Ник саклыйсыз инде ул азыкны?*
*Кем алса да, барыбер бетми бит!*
*Синең ашавыңнан файдаланып,*
*Дәүләт сине шулай этли бит!*

Сигезенче бүлектә автор үзенең кич белән шәһәр урамында бер кибетне ике төрле сакчы саклавын – тимер йозак та эленүен, аның өстенә тагын тере сакчы да куелуын күреп гаҗәпләнүен сурәтли. Монда Сирин үтергеч сатирасын куллана:

*Их, йозак, тимер йозак!*
*Хиссез йозак, юк бит җаны.*
*Ник товарны тараттың, дип,*
*Үтереп тә булмый аны!*
*Хиссез йозак, сакла, сакла,*
*Ләкин ышаныч юк сиңа!*
*Сине ватулары мөмкин, –*
*Сакчы кирәк тимер сакчыга!*
*Шуңар, әнә, синең өстеңнән*
*Тагын җанлы сакчы куелган*
*Син ул сакчыны саклыйсың,*
*Ә ул саклый сине башкадан.*

Поэманың соңгы бүлегендә хакимият өлкәсендә эшләүче «вак кешеләрнең» (беренче чиратта милиционерлар күздә тотыла булса кирәк) «зур булу өчен» үз формаларын киеп, погоннар (бәлки, әле медальләр дә) тагып йөрүләре сатира утына алына. «Хиссез тимер» тагып, кешеләрнең хөрмәтен казанып булмавы әйтелә:

*Бу форма – бу «мин – кан эчүче» дигән сүз.*
*Шул ис килә, шулай аңлыйм мин.*
*Шуңар андый формаларга*
*Зур нәфрәт белән карыйм мин.*

Совет тормышындагы ясалмалылыкка, икейөзлелеккә шагыйрь «табигый хис белән яшәү»не каршы куя, шуны яклый; ә гади крестьяннарны, эшчеләрне табигый хис белән яшәүчеләр дип атый; алар шатлана да, кайгыра да беләләр, ди. Әлеге поэманы ул:

*Бу – аларның иң матур сыйфаты.*
*Шуңар аларны бик дус күрәм мин.*
*Шуңар аларны өзелеп яратам,*
*Шуңар аларны өзелеп сөям мин, –*

дигән юллар белән тәмамлый.

Шулай итеп, бу поэма Сиринең иҗтимагый-әхлакый карашларын ачык чагылдырган әсәре булып тора.

Шушы ук темага Сирин 1932 елда «Бала һәм хөкүмәтләр» дигән сатирик шигырь дә язган. Ул анда хөкүмәтләр арасындагы мөнәсәбәтләр белән балалар уены арасында параллель үткәрә:

*Һәр бала көчсезлеген*
*Сизгәндә шундый юл тота:*
*«Әти-әнигә әйтермен», – дип,*
*Һәр дошманын куркыта.*

*Кәефе китсә, төрле дәүләтләр*
*Шулай ди бер-берсенә:*
*«Мин хәзер корал алып, ут*
*Яудырам, ди, өстеңә!»*

Мондый мөнәсәбәтләргә шагыйрь үзенең карашын болай белдерә:

*Корал алып көчләүне*
*Мин зур көчсезлек санадым.*
*Шуңар дошманымны көчле*
*Җырлар белән кыйнадым.*

* * *

1933 елда «Совет әдәбияты» журналында (№ 11–12) Сириннең «Кышкы чәчәкләр» дигән шигыре басылып чыга. Яшьлек чаялыгын чагылдырган бу лирик әсәр язучылар арасында көтелмәгән резонанс тудыра. Моңарчы да иҗтимагый вазгыятькә туры килмәгән «Сирин стиле» бу әсәрне дә тәнкыйтькә дучар итүгә сәбәп була. Кайбер язучылар журналның 1934 елның 1 нче санында ук бу шигырьне дә, гомумән Сирин иҗатын да тәнкыйтьләп мәкаләләр бастыралар: аны формализмда, буржуа төшенкелегендә, милләтчелектә һ.б. гаеплиләр (һәм шуның белән кайберәүләре үзләренең дә вульгар социологизм тарафдарлары икәнлекләрен дә күрсәтәләр. – *Ә.Ш.).* Язучылар берлегендәге бер җыелышта (1934) Сирин аларга болай дип җавап бирә: «Совет әдәбияты» журналында «Кышкы чәчәкләр» исемле шигырем басылды. Бу күпләргә ошамады, ахры. Ул шигырьне сүктеләр. Таныш-белешләр, язучылар минем белән күрешергә, сөйләшергә дә, хәтта минем яныма килергә дә курка башладылар. Күренергә дә, күрмәмешкә салыштылар.

...Нәрсә булган соң? Минем динче дә, милләтче дә, буржуа да булганым юк. Моны минем әдәби хисләрем кабул итә алмый. Мин шигыремнең ахырында:

*Юл өстендә ап-ак карга,*
*Букетларга абындым.*
*Ап-ак карым:*
*Салкын ярым,*
*Сине өзелеп сагындым.*
*Сикереп уйныйсым, ауныйсым,*
*Ятып елыйсым килде.*
*Шунда сине дә ак карга*
*Төртеп егасым килде, –*

дигәнмен. Дөрес дигәнмен. Үземә бала вакыттан таныш, өстендә чанага утырып шуган, кайнаган, йөргән, балалар белән куышып, төртешеп уйнаган ап-ак кар миңа кышның букеты булып күренгән, мин аларга абынганмын. Минем тормышым бер генә төсле акмый, шатлыклы да, кайгылы да, уртача да була. Елыйсы килгән, бик сагынган

чак та була. Мин әле тиешле урында кайгыра да беләм. Мин шуның өчен шагыйрь. Шагыйрь – көчле сөюче, көчле кайгыртучы, көчле шатланучы кеше ул.

Тәнкыйтьчеләр авторның нәрсә әйтергә теләгәнен дөрес аңларга һәм шуны башкаларга дөрес аңлатып бирергә тиешләр иде... 1934 ел».

Әмма Сириннең гаепсез икәнлеген исбатлаучы бердәнбер кеше ул үзе була; аны башка берәү дә яклап чыгыш ясамый.

«Күңелле-күңелсез» әсәрендә (1934) Сирин тормыштагы уңай һәм тискәре күренешләрне янәшә куеп сурәтли, әмма җәмгыятьтәге тискәре күренешләрне «күңелле» дип, ә уңайларын «күңелсез» дип атый. Мәсәлән:

*Урам буйлап автомобиль чаба,*
*Җаным-бәгърем, нинди сөйкемле!*
*Тузаныннан авыз-борын тулды,*
*Күз ачкысыз, ... нинди күңелле!..*
*Менә тагын һавалар җылынды, –*
*Сандугачлар сайрар, күрерсез.*
*Чәчәк атып, матур гөлләр үсәр,*
*Кояш чыгар, – булыр күңелсез.*
*...Ничә еллар подвалда яшәдем,*
*Ничә еллар яшьләр түгелде.*
*Тере тәнгә салкын кабер бит ул, –*
*Моңсу яшәү нинди күңелле!*
*Бүген минем тапкан квартирым*
*Өч тәрәзәле, якты – күрерсез.*
*Бәлки, мин дә сезнеңчә яшәрмен,*
*Менә бүген шактый күңелсез.*
*Юк, булмады – бүлмәмне алдылар,*
*Теге уйлар үлде, күмелде.*
*Мин тагын да кабердә калдым ич,*
*Калса – калсын, шулай күңелле!*

Шундый алым белән Сирин совет тормышының шактый гына тискәре, астыртын якларын күрсәтеп чыга.

Кемнән дә булса килгән хат яки телеграмма тексты итеп язу алымын да куллана шагыйрь: «Лермонтовтан хат», «Есениннан хат», «Тумаган балалардан хат», «Поезд астына тапталган берәүдән хат», «Тукаевтан Сирингә телеграм», «Бөтен дөньяга телеграм» һ.б. «Тумаган балалардан хат» әсәрендә (1933) ана карынындагы балалар, совет чынбарлыгындагы авыр тормышны сизенеп, хәтта дөньяга туарга да теләмиләр. Алар болай ди:

*Тик сезнең файдагыз өчен*
*Кан түгү өчен генә,*
*Канлы фронтларга барып,*
*Егылып үлү өчен генә,*

*Без ул дөньяга тумыйбыз,*
*Яшәмибез, тормыйбыз, –*
*Әниләрнең карынында*
*Нервалардан тыңлыйбыз.*

Үзенә юаныч эзләп, Сирин рус һәм чит илләр поэзиясенә мөрәҗәгать итә, алардан үзенең рухи халәтенә аваздаш мотивларны эзли. 1933 елда «Гаҗәпләнү (Әбел Галә әл-Мәгарридән)», «Алтын металл (Шекспирдан)», 1934 елда Есениннан этәрелеп китеп «Зәңгәр кичтә», «Алсу кофта, зәңгәр күзләр» шигырьләрен иҗат итә. Француз шагыйре Пьер Беранжега таянып, әхлак темасына багышланган «Син бит Гөлсем түгелсең» (1933), «Аучылар» (1934) шигырьләрен яза. Аның беренчесендә фахишәлек юлында йөрүче Гөлсемнең үзенең матурлыгын югалтуы, ә балаларының аның кайтуын көтеп зарыгып бетүләре сурәтләнә; икенчесендә – ире ауга киткәч, ят ирләрнең аның хатынын аулаулары турында бәян ителә.

«Күтәрик бокалларны!» шигырендә (1934) язучыларның авыр тормышта яшәүләре, гаделсезлекләрне кичерә алмаулары аркасында начар гадәткә бирелүләре сурәтләнә:

*Билетсызлар пивнойларга кереп,*
*Төннәр буе шаулап эчәләр.*
*Билетлылар өйләренә кितереп,*
*Бер-берсеннән яшереп эчәләр.*

Бу әсәрдә үзен һәр адымда эзәрлекләп торулары өчен Сириннең эчтән янып яшәве ачык чагыла:

*Мин язмышка ачу итеп эчәм,*
*Ачу итеп көләм, шатланам!*
*Юкса, бер көн чәчләрең агарыр,*
*Тормыштагы авыр кайгыдан.*
*Күтәрегез, күтәр бокалларны!*
*Күтәрегез, күтәр кайгыдан!*
*Бер минутка булса да онытылсын,*
*Көңелдәге уйлар, кайгылар!*

Ә шулай да Сирин күңелен төшерми, үзенә таяна. 1934 елда язган «Карлы» шигырендә ул үзенең көчле рухлы булуы турында болай ди:

*Их-ма!*
*Әле дә үзебез чыдам, –*
*Йөрәк күнгән кайгы-хәсрәткә.*
*Юкса безнең башны әллә кайчан*
*Шаштырырлар иде хәсрәтләр.*

1934 елда Сирин «Ана» дигән поэма язган. Әсәрнең башында ук «1931 елда кулак итеп авылыннан куылган бер ананың Казан урамында үз малае белән очрашуы» дигән аңлатма бирелә. Бу – Сиринне репрессияләүгә сәбәпче булган әсәрләрнең берсе.

Поэмада «Социализм җиңә барган саен җәмгыятьтә сыйнфый көрәш тә кискенләшә бара» дигән Сталин күрсәтмәсенең кешеләр арасында ничек чагылуы, нинди каршылык-фаҗигалар китереп чыгаруы тасвирлана, шул тәнкыйтьләнә. Сәяси карашларыннан чыгып, хәтта ана белән бала да икесе ике капма-каршы лагерьда торып калалар. Әсәрнең нигезендә ана белән бала арасындагы психологик конфликт ята. Унөч бала тәрбияләп үстергән ялгыз ананы (ире үлгән була), бер сыер һәм бер тана асраган өчен кулак дип гаепләп, өеннән куып чыгаралар. Ул хәзер хәер сорашу хәлендә калган. Шәһәр урамында ул үзенең улын очрата, аңардан ярдәм сорый: «Әтиегез вафат булды, үлеп котылды», – ди. Ананың сүзләрендә шул еллардагы курку атмосферасы бик ачык чагылыш таба. Ул үзен яклаучы табылмавын болай аңлата:

*Мин үзем дә сөйләп бирә алмадым,*
*Башкалар да эчтән тындылар.*
*Кем дә булса берәү яклап әйтсә,*
*Кулак ялчысы дип кудылар.*
*Үз-үзеннән куркып, һәрбер кеше*
*Кырын карый, белмим нишләргә.*
*Шул куркулар бозды бөтен эшне,*
*Юк ярдәмчем киңәш итәргә.*

Һәм ана, гаҗизлектән, хәер сорашырга мәҗбүр булган:

*Үз-үземне көчләп суя алмадым,*
*Килеп бастым урам чатына.*
*Кызган, бала, мин сиңа ана бит,*
*Шул аналык хисләре хакына!*

Әмма партия идеяләренә нык бирелгән улы әнисенә карата коточкыч рәхимсезлек күрсәтә: үз анасын сыйнфый дошман күреп, аңа ярдәм итүдән баш тарта. Әнисенә болай дип җавап бирә:

*Үз-үземне көчлим,*
*Булдыра алмыйм,*
*Газапланам, каты бәрелсәм...*
*Ачуланма, анам, мин шәфкатьсез,*
*Мин гаепле – шәфкать иттисәм...*
*Син – «милекче ана», һәр сүзеңдә*
*«Вак милек»не сөеп яклыйсың.*
*Яшьләр коеп, урам чатларында*
*«Вак буржуа хисе» саклыйсың.*
*Бер кулак пичәте басылгач,*
*Үз анам дип сине якласам,*
*Нәрсә булыр сыйнфый көрәштән*
*«Кода-кодагыйлык» ясасам...*
*Без икебез – ике фронтта,*
*Канлы кинжал тора арада.*
*Их, шәфкатьле анам! Сыйнфый көрәш...*
*Мәрхәмәт юк «дошман ана»га...*

Шундый мәрхәмәтсезлек күргән ананың хәле болай сурәтләнә:

*Сулыш кызды, ана башында*
*Шәфкать үлде, шатлык югалды.*
*Ачу белән уйлар томаланды,*
*Күз аллары ямьсез, караңгы.*
*Өерләнеп уйлар бөтерелде,*
*Өмит яраланды, шул ара –*
*Күңеле тулды, күздән яшьләр китте...*

Ана, каты рәнҗеп, улына болай ди:

*«Мин алайса, дошманнар үстердем,*
*Киләчәкне алдан белмәдем...*
*Ник үстердем сез унөч баланы,*
*Корсакта чак ник үтермәдем?..*
*Ник имезәм тагын бу соңгысын?*
*Дошман булыр, аны үстерсәм...*
*Ул ашыйсын үзем ашармын,*
*Беркем белмәс буып үтерсәм...»*

Ана нишләргә дә белми: аның күңеле бер туңа, бер эри:

*Тагын май күк йомшап китте,*
*Тәндә вак-вак энәләр йөгерде.*
*Тагын тирән уйга талды, –*
*Ниләр күрми бала анасы!..*
*Кинәт күреп, шашып калды, –*
*Кулда үлгән имчәк баласы!..*

Шагыйрь, ачыргаланып, болай ди:

*Их, син тормыш! Ник соң болай?!..*
*Хисләр белән сәүдә итәсең?..*
*Бала – ана, туганлык хисләрен*
*Үтмәс кайчы белән кисәсең?*

Әсәр болай тәмамлана:

*Күкрәк сөте белән үз гомрендә*
*Унөч солдат биргән бер ана*
*Шәфкать эзли көрәш мәйданында,*
*Яшь баласын кочып җиргә ава...*

Лирик герой күңелендә дә хисләр давылы. Ничек эшләсә дә, ул гаепле:

*Катып торам үз әнием янында...*
*Мин гаепле...*
*Мин гаепле диктатура алдында...*
*Мин гаепле, – шәфкать иттисәм...*

Шулай итеп, «Ана» поэмасы укучы күз алдына 1930 елларда махсус күпертелгән сыйнфый көрәшне, ул көрәшнең никадәр рәхимсез, кешелексез һәм мәгънәсез булуын ачып сала. Татар поэзиясе

тарихында әлеге рәхимсезлекне бу кадәр тирәнлек белән тасвирлаган башка әсәр юк шикелле.

Р. Мостафин: «“Идеологик тотнаксызлыкта” гаепләп, Сиринне Язучылар берлегенә алмыйлар, “формализм”да һәм башка “изм”нарда гаеплиләр, – дип ассызыклый. – Ә сәләтсез шагыйрьләрне, “идеология” ягына карап бастыралар, бүләклиләр, югары күтәрәләр» [Мостафин, б. 163]. Поэзиядә үз дәрәҗәсен белгән, ачы телле Сирин горур кала, үзен мондый кимсетүгә көчле сатира белән җавап бирә. Казанда оешкан язучылар төркемен ул «Ат кәмите» дип атый (1935 ел):

*Ярминкәдә ат кәмите әйләнә дә әйләнә,*
*Их, мин дә әйләнер идем, эш акчага бәйләнә.*
*Әйләнә тайлар, агач атлар, малайлар әйләнә,*
*Әйләнә кызлар, кызыл утларга күзләр бәйләнә.*
*Әйләнә Нәҗми, Толымбай, Нигъмәти әйләндерә,*
*Әйләнә Сәйфи, Әмирләр ... Әйләнү бәйләндерә.*
*Татиздатның ат кәмите әйләнә дә әйләнә,*
*Их, мин дә әйләнер идем, эш билетка бәйләнә*[1].

Сирин хәтта Сталинга да эпиграмма язган. Аның тексты безгә килеп җитмәгән, әмма Булат Солтанбәков үзенең мәкаләсендә аның эчтәлеген китерә. Анда «Сандугач, син ташла бу җырларыңны, ә һәр җырыңда Сталинны мактап җырла. Шул чакта сине күреп алырлар һәм син СССРның атказанган сандугачы булырсың», дигән сүзләр булган. Моңа кадәр гел кызыл төсләр белән генә сурәтләнеп килгән совет системасын тискәре яктан яктырту, андагы астыртын күренешләрне тәнкыйтьләү, әлбәттә, ул елларда искиткеч зур кыюлык таләп иткән һәм һич тә җәзасыз кала алмаган. Совет системасын рәхимсез тәнкыйтьләгән Сирин дә репрессия корбанына әверелә. Аны биш елга хөкем итәләр һәм Сиблагка озаталар.

Сирин, сөрген срогын тутырып, 1940 елда туган иленә кайта. Иҗатын дәвам итә: сөргеннән соң ул туксаннан артык шигырь, бер сатирик поэма һәм берничә әкият иҗат иткән.

**Әдәбият**

*Исхак Ә.* Бәләкәй генә бер истәлек // Чаян. 1987. № 3.

*Бадыйкшан Л.* Шагыйрь белән очрашулар // Ватаным Татарстан. 1997. 14 гыйнвар.

*Батыршин С.* Тормыш хатирәләре// Казан утлары. 2016 . № 12. Б. 153.

*Мостафин Р.* «Кыш сайрамый сандугач...» // Казан утлары. 1996. № 12. Б. 163.

***Шәрипов Әнвәр Мәгъдәнур улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор*

[1] Сүз Язучылар берлеге билеты турында бара.

УДК 82-13

***Р.Ф. Сафиуллина***

# «ИБРАҺИМ ӘДҺӘМ» ДАСТАНЫНЫҢ ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ВЕРСИЯЛӘРЕНДӘ ДИНИ-СУФИЧЫЛ ӘДӘБИЯТ ИДЕЯЛӘРЕ

В статье рассматривается поэма татарского поэта Габдельджаббара Кандалый «Кыйссаи Ибрахим Адхам», занимающая особое место среди произведений о суфийском шейхе Ибрахиме. Автор анализирует данное произведение в сравнении с турецким дастаном «Ибрахим Адхам». Предпринята попытка сравнительного анализа сюжетно-стилистических особенностей турецкого дастана и произведения татарского поэта Г. Кандалый.

Татарская версия дастана об Ибрахиме Адхаме содержит многочисленные заимствования из арабского, персидского и турецкого языков. Поэму Г. Кандалый можно отнести к жанру назира, широко распространившемуся в тюркской литературе (произведение, написанное на основе или по аналогии с известным сюжетом). Тем не менее, поэма не повторяет широко распространенный в Восточной литературе сюжет: в ней присутствуют события, не описанные в других версиях дастана. В ходе анализа автор приходит к выводу о том, что поэма Г. Кандалый является самостоятельным, оригинальным произведением, основанным на традиционный в восточной литературе и народном творчестве мотив.

**Ключевые слова:** Ибрахим Адхам, дервиш, дастан, суфийская литература, Габдельджаббар Кандалый.

The article deals with the poem of the Tatar poet Gabdeljabbar Kandaly Kyyssai Ibrahim Adham» which has a special place among the works about the Sufi sheikh Ibrahim. The author analyzes this work in comparison with the Turkish dastan «Ibrahim Adham». An attempt has been made to compare the plot and stylistic features of the Turkish dastan and the work of the Tatar poet G. Kandaly. The Tatar version of the dastan about Ibrahim Adham contains numerous borrowings from Arabic, Persian and Turkish. G. Kandaly's poem can be referred to the Nazir genre, which is widely spread in Turkic literature (a work written on the basis of or by analogy with a well-known plot). However, the poem does not repeat the plot which is widespread in Eastern literature: it contains events that are not described in other versions of the dastan. In the course of the analysis the author comes to the conclusion that G. Kandaliy's poem is an independent, original work based on a traditional motif in Eastern literature and folk art.

**Keywords:** Ibrahim Adham, dervish, dastan, Sufi literature, Gabdeljabbar Kandaly.

Төрки-мөселман дөньясы әдәбиятына һәм фольклорына кайбер уртак дастани сюжетлар хас. Мәсәлән, байтак мөселман халыклары әдәбиятында Ибраһим Әдһәм турында тезмә һәм чәчмә дастаннар, шагыйрьләрнең әсәрләре билгеле. Ибраһим Әдһәм – реаль тарихи шәхес: ул Бәлхтә туган, Суриядә гомер кичергән, 875 еллар тирәсендә [Госманов, б. 23] вафат булган. Аның Бәлх әмире булуы, байлыгын һәм тәхетен ташлап, дәрвишлеккә китүе мәгълүм.

Ибраһим Әдһәм турындагы шигъри әсәрне тәүге мәртәбә фарсы шагыйре Фәрид әд-Дин Гаттар язган (1229 елда үлгән) [Садыйкова, Хәйретдинова, 36]. Шулай ук Үзбәкстан җирлегендә дастан формасында язылган «Кыйссаи Ибраһим ибн Әдһәм» дигән чәчмә әсәр билгеле. Кайбер башка төрки халыкларда да аңа багышланган дастан бар. Атаклы мөселман әүлиясе турындагы дини эпос Әхмәд Ясәви тарафыннан да язылган [Садыйкова, Хәйретдинова, б. 248–255]. Шулай ук Сөләйман Бакырганиның дини-дидактик әсәрләре җыентыгында Ибраһим Әдһәмнең дәрвишләр юлына басуы әйтелә [Яхин, 229] .

Татар әдәбиятында Ибраһим Әдһәм образына шагыйрь Габделҗәббар Кандалый (1797–1860) аерым игътибар бирә. Аның «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмасы дөньякүләм мәгълүм Ибраһим суфига багышланган. Г. Кандалыйның әлеге тарихи персонажга мөрәҗәгать итүе очраклы түгел. Әлеге шәхес... бербөтен, тулы һәм эмоциональ образ мөселман Көнчыгышы әдәбияты белән яхшы таныш шагыйрьгә нык тәэсир иткән кебек, татар укучысын да тетрәндерә, уйландыра, илаһи кичерешләргә сәбәп була. Мәшһүр суфиның Аллаһ юлында дөньядан ваз кичүе әлеге тәэсирләрне бигрәк тә арттыра:

*Гашыйк булсаң, гыйшык юлыга куйгыл кадәм,*
*Дөнья – гокъбен талак куйгыл, мисле Әдһәм.*

Г. Кандалыйның «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмасының 14 бүлеге сакланган. Әлеге әсәр татар телендә язылган, шулай да поэмада гарәп-фарсы, төрек телләреннән алынмалар бихисап. Аны төрки әдәбиятта киң таралган нәзыйрә (мәгълүм сюжетка нигезләнеп яки охшатып язылган әсәр) жанрына кертергә мөмкин.

Поэманың беренче бүлеге сюжет динамизмы, хәрәкәткә корылуы, шулай ук әкиятләргә хас образ – падишаһ персонажы кертелү белән халык әкиятләрендәге башламны хәтерләтә:

*Шаһи Бәлх ирде солтан Ибраһим.*
[Госманов, б. 318]

Көннәрдән бер көнне Ибраһим тәхеттән баш тартып, иске киемнәр киеп, дәрвишлеккә китә. Каһарманның әлеге гамәленең сәбәбен, аның элекке тормыш юлын да белмибез. Г. Кандалый укучыга бу хәлләрне сөйләми.

Г. Кандалый беренче строфада ук персонажның бәлагә таруын бәян итә: дәрвишлектә йөргән Ибраһим бикле шәһәр капкасыннан уза алмый һәм шәһәр читендә кунарга кала. Көтмәгәндә ул тирә-юньне карап-тикшереп йөрүче каравыл кулына эләгә. Каравыл юлчыдан карак дип шикләнә һәм үзләренең патшасы янына алып керә. Кемлеген сорашкан Һарун патшага юлчы үзенең Аллаһ ризалыгы өчен гомерен дәрвишлектә үткәрүче мосафир булуын әйтә. Каравыл башлыгы, ышанмыйча, ачу белән Ибраһимга китереп суга. Һарун патша хезмәтченең мосафирга карата мондый илтифатсызлык күрсәтүен хупламый. Ул Ибраһим Әдһәмнең хикмәт иясе дә икәнлеген сизеп

ала. Патша каравыл башлыгының үзен суктыра. Монда янә традицион фольклор, әкият мотивына дикъкать итми мөмкин түгел: ул – халыкның мескеннәрне һәм фәкыйрьләрне яклый торган игелекле, гадел патша турында күпгасырлык хыяллары. Г. Кандалый поэмасында Һарун патша, кунакчыллык кагыйдәсен тупас бозган хезмәтчене җавапка тартып, гадел хаким буларак гәүдәләнә. Әсәрнең төбендә, бик тирәндә яшеренгән ислам фәлсәфәсенә дә игътибар бирү кирәк: хуҗага ярарга тырышуда чама хисен онытып җибәрергә ярамый, хуҗа-падишаһ та –Аллаһның бер колы гына.

Татар шагыйре Г. Кандалыйның әсәрендә Һарун патша, кунакчыллык күрсәтеп, Ибраһимны кесәл белән сыйламакчы була. Ибраһим кесәлне алмый, тик елмаеп кына куя. Падишаһ мосафир елмаюының сәбәбен белмәкче булгач, кунак аңлатып бирә. Патша ризалыгын алырга омтылган хезмәтчене суктыралар, шул ук вакытта Аллаһ ризалыгын эстәгән Ибраһимга сый-нигъмәт тәкъдим итәләр, дип аңлата Ибраһим. Суфилар әхлагы хакимнәр кулыннан бүләк һәм сый кабул итүне һич акламый. Әмма падишаһ тәкъва, хикмәтле кунагы Ибраһимга ничек тә кадер-хөрмәт күрсәтмәкче: аны патша сараенда калырга чакыра. Ибраһим Әдһәм янә патша тәкъдименнән баш тарта. Патша сараенда рәхәт чигүдән Аллаһ катында тәүбә кылып гомер үткәрү, әлбәттә, тәкъва суфи өчен күпкә артык:

*Дия кем: «Гафу сорап килдең миңа,*
*Бөтен гөнаһларың багышладым сиңа».*
*Бәс, аның белән миңа булмак кирәк,*
*Синең белән ничек тормак кирәк?*
[Госманов, б. 318]

Шул сәбәпле хикмәтле кунак Һарун әр-Рәшид патша янында кала алмый.

Әлеге ике персонаж да тарихи шәхесләр булса да, чынлыкта алар очраша алмаган: Һарун әр-Рәшид Ибраһимнан бер гасыр элек, 763/809 елларда яшәгән. Бу мисал тарихи шәхесләр биографиясенең фольклорлашуын, үзгәртелүен, бизәлеп, әдәби әсәрләргә дә күчүен күрсәтә.

Татар шагыйре Г. Кандалыйның «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмасы чыганаклары мәсьәләсе дә гаять актуаль. Фәрид әд-Дин Гаттарның суфи шәехләренә багышланган «Тәзкират әл-әүлийа» («Изгеләрнең юлы») әсәрендә Ибраһим ибн Әдһәмгә байтак урын бирелә. Поэмада шулай ук персонажның Бәлх патшасы булуы, тәхетен, хатыны һәм кечкенә улын ташлап китүе, Мәдинә шәһәренә барып, анда фәкыйрьлектә яшәве, авыр физик хезмәт белән шөгыльләнүе турында язылган. Г. Кандалый поэмасында исә Ибраһимнең гаиләгә, никахка мөнәсәбәте, элекке тормышы, ни сәбәпле дәрвишлеккә чыгып китүе укучыга хәбәр ителми. Моны суфи тарикатьләренең кайбер үзенчәлекләре татар халкына бөтенләй чит булу белән аңлатырга мөмкиндер. Ягъни татар ире дәрвишлеккә китмәгән, чөнки ул кырыс

табигать шартларында гаиләне туендыручысыз калдырып читтә йөрү мөмкин хәл дип санамаган.

Ибраһим Әдһәм турындагы мәгълүм чыганакларның берсе – XIV гасырда иҗат ителгән «Ибраһим Әдһәм» дастаны. Дастан фольклорлашкан, төрле халыкларда таралган. Аның иске төрек телендә генә дә дистәгә якын варианты яши. Г. Кандалый өчен дә Ибраһим дәрвиш турында поэма иҗат итүгә шушы дастанның чыганак булу ихтималы зур. Төрки дастанны үзенең мәшһүр «Төрек әдәбияты тарихы» китабында танылган төрек язучысы һәм әдәбият белгече Вәсфи Маһир Кожатүрк (1907–1961) тикшерә.[Kocatürk, s. 162]. *(Дастаннан татарчага тәрҗемәләр шушы чыганакка таянып гамәлгә ашырылды.)*

Төрек дастанында да сюжет Ибраһим турында бәян итүдән башлана. Әмма монда Ибраһим ибн Әдһәмнең суфи булганчыга кадәрге тормышы, Аллаһка якынаю турында уйланулары, дәрвишлеккә китүенең сәбәпләре әйтелә.

*Horasan'da var idi bir padişah,*
*Hükmüşarkdangarbageçerdiey şah.*
[Kocatürk, s. 162]

*(Хорасанда бар иде бер падишаһ,*
*Хөкеме Көнчыгыштан Көнбатышка кадәр, әй, шаһ.)*
[Сафиуллина, б. 162]

Хорасан падишаһы Ибраһим башта абсолют хакыйкать, тәсаувыф, Аллаһ юлы турында уйланмый торган гадәти бер хаким була. Әсәрдә аның тормышын һәм карашларын үзгәрткән бер вакыйга тасвир ителә. Патша төнлә үзенең сараенда йоклаганда бер төш күрә:

*Damın üzerinde bir kişi gezer,*
*Çün tıkır tıkır edip nesne ezer.*
*İbrahim çağırdı «kimsin ey kişi?»*
*Geceleyineyliyesün buişi.*
*Kişi etti: Ben senin devecinem,*
*Deveya vukildim anı isterim.*
[Kocatürk, s. 162]

*(Түбә өстендә бер кеше йөрер,*
*Дөбер-шатыр әйбер изәр.*
*Ибраһим дәште: «Кем син, әй, кеше?»*
*Кеше әйтте: «Мин синең дөя караучың,*
*Дөя тотарга чыктым, шуны телимен».)*

Ибраһим Әдһәм бу сүзне тыңлап, пошаманга төшә, чакырылмаган «кунак»ка түбә өстендә дөя булмаслыгын аңлатырга тырыша. Аңа үзенең терлекләре арасыннан бер дөяне алырга һәм сарайдан чыгып китәргә тәкъдим итә. Бу кеше падишаһның, «җылы атлас эчендә ятып», Аллаһтан читләшүен тәнкыйтьли, «минем монда дөя табарга теләвем – синең: "мин – Тәңре колы", диюең белән бер», ди.

Ибраһим падишаһ йокысыннан уяна һәм аптыраошта кала. Моннан соң да әле тагын шундый гаҗәп төшләр күрә, аларда да аңа дөньяның фанилыгы, Аллаһка якынаю зарурлыгы әйтелә. Ибраһим нишләргә дә белми, гаҗизләнә, гел уйда була. Юаныч табу өчен ул гаскәре белән ауга чыга. Бер боланны куган вакытта адаша. Колагына: «Уян, уяндырганчы уян!» – дигән тавышлар ишетелә. Ниһаять, бер көтүчене очратып, аңа үзенең затлы киемнәрен бирә, көтүче киеменә төренеп, ялгыз башы китеп бара.

Ибраһимнан ике айлык чагында калган һәм аның урынына тәхеткә утырган улы атасының югалуына бик кайгыра. Ул 18 яшькә җитә. Көннәрдән бер көнне хәбәр килә: Ибраһим Әдһәм Мәккәдә дәрвишләр башлыгы булган икән, ул тауларда утын кисеп, аны базарда сатып, әлеге акчага икмәк алып, дәрвишләргә тарата, дип сөйлиләр.

Угыл атасын өенә алып кайту өчен, сәүдәгәр кыяфәтенә кереп, Мәккәгә китә, эзли торгач, әтисен таба:

*Аркасына төягән утынын,*
*Килә иде бер ак сакаллы карт.*
*Кулына аскан утынның бавын,*
*Биленә таккан балтаның сабын.*
[Сафиуллина, б. 164]

Әлеге тетрәндергеч һәм дастани вакыйга Г. Кандалый поэмасында тасвирланмаган. Төрек вариантында исә угыл атасының кулын үбә, аны туган иленә алып кайтып, анасы белән кавыштырырга, яңадан тәхеткә утыртырга омтыла.

Төрекчә дастанда дәрвишләргә хас аскетизмның һәм фани дөньядан ваз кичүнең иң югары дәрәҗәсен күрәбез. Ибраһим Әдһәмнең Аллаһка гыйшкы һәм тәкъвалыгы шулкадәр көчле була, ул хәтта ерак аралар үтеп килгән, унсигез ел буе күрмәгән улының тырышлыгын күңеле белән кабул итми. Ул ике ут арасында кала: аңа улы якын, әмма Аллаһны ул артыграк ярата. Дәрвиш, илаһи мәхәббәтенә кимчелек килер дип уйлап, «йә минем җанымны ал, йә улымныкын ал» дип, Аллаһка дога кыла:

*«Телимен синнән, әй, Ходаем,*
*Кылма каршылык аны миңа бүген.*
*Йә минем җанымны ал бу сәгатьтә үк,*
*Йә – аның», – дигәч, ауды пәһлеван.*
[Сафиуллина, б. 165]

Төрек дастанында тасвирланган бу фаҗига тетрәндергеч: Ибраһимның пәһлеван гәүдәле улы шунда ук егылып, җан тәслим кыла.

Дастанның калган өлешендә аерылу газабы чагылыш таба. Ибраһим, әүлия һәм суфи шәехе булса да, гадәти кешегә хас сыйфатлардан мәхрүм түгел, чөнки суфилар – Аллаһның гап-гади коллары. Ибраһимда аталык хисләре уяна:

*Атасына омтылып килгән*
*Әлеге хәлгә төшкән,*

*Атасы угына очраган,*
*Ятим угыл, гариб угыл.*
*Ата угы сине яндырды,*
*Бөтен илләр безгә карады,*
*Ялгызлыгың йөрәгемне яндырды,*
*Ятим угыл, гариб угыл.*
*Сәүдәгәр кыяфәтенә кердең,*
*Бу өлкәгә килеп юлыктың,*
*Егетлекне илгә бирдең,*
*Ятим угыл, гариб угыл.*
*Мине дәрвишләрдән сорадың,*
*Утынга киткәнемне белдең,*
*Җанымны телгәләдең,*
*Ятим угыл, гариб угыл.*
[Сафиуллина, б. 165]

Биредә рефрен булып яңгыраган «Ятим угыл, гариб угыл» гыйбарәсе тулаем суфилар риторикасына хас. Суфилар фәлсәфәсендә дә, гомумән, дин өйрәтүе буенча, Галәмнәр хуҗасы Аллаһ каршында гына түгел, Ул бар иткән табигать каршында да бәндәләр көчсез һәм зәгыйфь – гариб. Шулай ук төрек дастанында Ибраһим образының тасвирламасы да мөселман халыкларының традицион суфичыл әдәбиятындагы тасвирламалар белән туры килә. Көтүчеләр, чыбык, утын җыючылар – дәрвишләрнең социаль хәле традицион рәвештә нәкъ шулай сурәтләнә. Фәкыйрьләрчә киенгән суфи тамагын да Аллаһ ни бирсә, шуның белән туендырган.

Әгәр яңадан татарча шигъри әсәргә, ягъни Г. Кандалыйның «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмасына әйләнеп кайтсак, аның төрек, фарсы һәм үзбәк версияләреннән беркадәр аерылып торуын күрербез. Г. Кандалый поэмасының бүгенгәчә сакланган 11 бүлегендә алдарак телгә алынган вакыйгалар сурәтләнми. Ибраһим Әдһәмнең гаилә хәле дә телгә алынмый. Композицион яктан Кандалый поэмасы берничә сюжет сызыгына корылган, аларны уртак персонаж – Ибраһим берләштерә.

Поэмада зикер (Аллаһны телгә алу, искә төшерү) һәм догалар шактый урын алган. Зикердә, ягъни, автор версиясе буенча, мөнәҗәттә, әсәрнең төп идеясе дә бирелә:

*Кем сәнең зикрең, Хода, Раббе-л-кәрим,*
*Инҗир-у-хөрмәм ирер улдыр бәнем.*
*Мәүляи зикрең гөлстаным дорыр,*
*Зикрең, и Хакъ, багый-бөстаным дорыр.*
*Зикрең, и Хакъ, әһле әүлядым дорыр,*
*Дөнйа-ахирәт вә гъәдел-дадем дорыр.*
[Госманов, 325]

Шушы сүзләрне әйтеп, Ибраһим вафат була.

Аннан соңгы бүлекләр, беренче карашка, поэманың исеме һәм баш каһарман белән бәйле түгел: Ибраһим Әдһәм персонажы сюжет-

тан бөтенләйгә төшеп кала, соңында бер-берсе белән эчтәлек ягыннан бәйләнгән аерым бүлекләр дәвам итә. Бишенче бүлектә бер мәҗлескә җыелган могтәбәр кешеләр, фәкыйрь киенгәнлеген сәбәп итеп, олы яшьтәге берәүне үз җыелышларыннан куып җибәрә. Кайбер галимнәр фикеренчә, биредә сүз янә Ибраһим Әдһәм турында бара. Ул башка бер дәрвиш персонажмы, әллә автор Ибраһим образына яңадан мөрәҗәгать итәме – мәгълүм түгел. Һәрхәлдә, әлеге персонажны күрсәтү – Ибраһим суфидай бәндәләргә ачу сакламый торган, бөтен авырлыкларга сабыр итүче тәкъва мөселман темасын дәвам итү дип аңлашыла.

Г. Кандалый поэмасында татарлар өчен традицион булган дини-суфичыл әдәбият идеяләре [Хасавнех, Мөхәммәтҗанова, б. 36–45] һәм халык иҗаты бергә үрелеп, шигъри образлар белән баетып бирелә. Шулай ук автор персонажлар әхлагына халыкчан рәвештә төгәл бәя бирә. Мәсәлән, җиденче бүлектә лирик герой исеменнән хикәяләү игътибарга лаек. Анда тасвирланган хәлләр яшь шагыйрьнең үз башыннан кичкән вакыйгага охшап тора. Нәкъ кичке эңгер-меңгердә генә бер авылга белем һәм тәҗрибә эстәп дөнья гизүче яшь егет килә. Япан кырда ялгыз калу чарасызлыгы аны шушы авылда кунарга мәҗбүр итә. Җирле халыкның элек яшәгән җиреннән төрле яманлыклар өчен сөрелгәнлеге турында ул хәбәрдар була.

Авылда мосафирның кунуы турында ишеткән кешеләр иртән иртүк егет янына килеп җитәләр: аның кая, нинди максат белән юнәлүен, кайсы нәселдән, кем булуын тәфсилләп сорашалар. Егет берни яшермичә сөйләп бирә. Авыл кешеләре аның белән артык итагать саклап тормый: кунакка ышанмыйлар, чыннан да Кандал авылының фәлән-фәлән кешесе булуын раслаган язу сорыйлар. Табигый, сәфәргә чыккан егетнең мондый кәгазе булмый. Шулвакыт авыл агайлары татар-мөселманга хас кунакчыллык кагыйдәләрен боза: мосафирны зинданга ташлап, җәза бирергә карар кыла. Бары тик шушы вакытта авыл аша бер сәүдәгәрнең узып баруы, бәлагә тарыган мосафирның аяныч хәлен ишетеп, аның өчен ясак түләве генә егетне зинданнан коткара.

Беренче карашка, яшь мосафирның явыз кешеләр яшәгән авылда күргәннәре атаклы Ибраһим шәех турындагы әсәр мантыйгына туры килми сыман. Шулай да, игътибар итсәк, авторның әлеге ике төрле сюжет сызыгын бер әсәрдә берләштерүе эзлекле һәм табигый күренеш булуын аңларбыз. Поэма башында шәһәр читендә кунып калган Ибраһим Әдһәмгә дә җирле халык тарафыннан илтифатсызлык, ышанмаучылык билгеләре күрсәтелгән иде. Мосафирларга кадер-хөрмәт күрсәтү кагыйдәләрен тупас бозып, суфи дәрвишне дә кыерсыталар. Ләкин Аллаһ хакына сабыр итүче мөселманнарга карата һәр ике очракта да гаделлек торгызыла. Әлеге ике сюжет сызыгын шушы уртак фикер берләштерә.

Поэманың соңгы бүлеге «Мөәллифе пәнд ба-худ гөфтәнүш» («Автор үзе белән киңәш-табыш итә») дип атала. Бүлек исеме –

каламбур түгел. Текстта моңарчы очраган мөнәҗәтләрдәге кебек үк, Г. Кандалыйның игътибары бу очракта да лирик геройның эчке дөньясына юнәлгән. Әлеге бүлекләр укучыга үгет-нәсыйхәт бирүгә багышлана. Лирик герой, суфилар шикелле үк, үзенең гөнаһлы бәндә булуын, гөнаһларын исенә төшереп кайгыруын, Аллаһның ярлыкавына өметләнеп, дога кылуын, зикер әйтүен яза. Элекке бүлекләрдәге «Мөнәҗәтләр»дәге сыман ук, монда да Г. Кандалый игътибарны лирик геройның күңел дөньясына, эчке кичерешләренә юнәлтә. Беренче очракта автор гөнаһларын кичерүне үтенеп, Аллаһка ялварса, «Автор үзе белән киңәш-табыш итә» бүлегендә ул үз-үзен «камчылый». Суфиларга хас булганча, ул башка кешеләр, персонажлар гаебен тикшерә алмый, суфи шигъриятендәге сыман, мәләмәтиягә – үз-үзен тәнкыйтьләүгә бирелә [Мухаммад, с. 57]. Суфи шагыйрьләр кебек үк, Г. Кандалыйның лирик герое да үз-үзенә карата «мескен», «гарип», «фәкыйрь», «гөнаһлы»ише сүзләр куллана, ләкин аның Аллаһ кичерүенә өмете бар. Шуның белән укучыга эмоциональ йогынты көчәя һәм тирәнәя.

Г. Кандалый әсәрендәге төп юнәлеш, – тәсаувыфтан да бигрәк, ислам шәригате кушканны үтәү, Коръән белән гамәл кылу, яшәү, гөнаһлар өчен үкенеп, Аллаһка ялвару. Сурәтләр, символлар суфичылык идеяләрен үткәрергә ярдәм итсә дә, асылда барысы да гомумислам рухында. Алар исламга да, тәсаувыфка да хас. «Шуңа алар халык әсәрләренә бик органик булып кереп урнашканнар, һәм аларның образлар дөньясын баетканнар» [Садыйкова-Башкурова, б. 113].

Җыеп әйткәндә, Г. Кандалыйның «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмасында дәрвишлек, тәкъвалык, дини дидактика, нәсыйхәтләү урын ала; Ибраһим образының Аллаһ юлында җанын фида кылырга әзерлеге турындагы идеяләр, мотивлар саклана. Шул ук вакытта, шагыйрь Г. Кандалый әсәренә оригиналь иҗат ысулы хас, авторның шәхси фикер-карашлары, сюжет сызыгында яңа, кабатланмаган урыннар бар. Әлеге аерымлыклар, нигездә, татар җирлегенә карый яисә лирик герой белән бәйле хис-кичерешләрне, кайбер вакыйгаларны сурәтли. Шулай ук татар шагыйре иҗат иткән поэмада Аллаһка зикердога (автор аларны мөнәҗәт дип атый), традицион суфи шигърияте символлары белән сурәтләү игътибарга лаек. Шунысы да мөһим: Г. Кандалый әсәрендә мәгълүм борынгы сюжетлар татар халык иҗатыннан алынган мотивлар, традицион фольклор жанрлары белән бергә үрелеп бара. Димәк, Г. Кандалый поэмасы, традицион мотивлар, суфичылык-мөселман, дини-дидактик әсәрләр белән уртаклыкларны саклаган хәлдә, алардан шактый аерылып та тора, ул – кабатланмаган сюжет сызыкларына, яңа образ һәм идеяләргә ия мөстәкыйль, оригиналь әсәр.

**Әдәбият**

*Госманов М.Г.* Бер гомердә ике чор // *Кандалый Габделҗәббар.* Шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 552 б.

*Kocatürk Vasfi Mahir.* Türk Edebiyatı tarihı. Ankara, 1970. 854 s.

*Мараш И.* Религиозное обновление в тюркском мире (1850–1917). Казань: Иман, 2005. 96 с.

*Мухаммад Ю.Х.* Суфийская энциклопедия (Часть I–II). Казань: Иман, 2004. 230 с.

*Садыйкова А.Х., Хәйретдинова Р.Р.* XII–XX гасыр башы татар әдәбиятында дини фольклор: дәреслек. Казан: КФУ, 2016. 384 б.

*Садыйкова-Башкурова А.Х.* Ислам һәм татар халык иҗаты. Казан, 2005. 231 б.

*Сафиуллина Р.Ф.* Традиции фольклора в творчестве Габдельджаббара Кандалый. Казань: ИЯЛИ, 2020. 168 с.

*Хасавнех А.Ә., Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Әбү Бәкер Каландар Руминың «Каландарнамә» исемле суфичыл әсәрендә мәхәббәт классификациясе // Фәнни Татарстан. 2022. № 3 (35). С. 36–45.

*Яхин Ф.З.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан: ТДГИ нәшр., 2000. 268 б.

***Сафиуллина Рузия Фәһим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 82-1(=512.145)

*Л.Р. Надыршина*

# XX ЙӨЗНЕҢ 90 НЧЫ ЕЛЛАРЫНДА ТАТАР ПОЭМАСЫНЫҢ ҮСЕШ ЮЛЛАРЫ

В статье анализируются жанровые изменения татарской поэмы 1990-х гг. Автор статьи приходит к выводу, что изучаемый период в развитии татарской поэмы воспринимается временем продолжения достигнутого в предыдущие годы, но при этом поэмы начинают тяготеть к усложнению структуры, усилению публицистического пафоса, укреплению этнической проблематики. Большинство поэм этого периода характеризуются лозунговостью, риторикой, концептуальностью, стиранием границ между лирическим героем и автором, что позволяет рассматривать полупублицистические лиро-эпические тексты как манифестацию гражданской позиции самих поэтов.

**Ключевые слова:** татарская поэзия, поэма, жанр, идея-проблематика, образ, лирический герой.

The article analyzes the genre changes of the Tatar poem of the 1990s. The author of the article comes to the conclusion that the studied period in the development of the Tatar poem is perceived as a continuation of what was achieved in previous years, but at the same time the poems begin to gravitate towards complicating the structure, strengthening journalistic pathos, strengthening ethnic issues. Most of the poems of this period are characterized by sloganeering, rhetoric, conceptuality, blurring the boundaries between the lyrical hero and the author, which allows us to consider semi-publicistic lyric-epic texts as a manifestation of the civic position of the poets themselves.

**Keywords:** tatar poetry, poem, genre, idea-problematics, image, lyrical hero.

Үзган гасырның соңгы ун-унбиш елындагы иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни үзгәрешләр дулкынында татар сүз сәнгате дә яңа эзләнүләр юлына чыга. Милли һәм рухи күтәрелеш чоры булган бу дәвердә әдәбиятның үзәген халыкның бәйсезлеге, тарихы һәм киләчәге мәсьәләләре тәшкил итә. Милли мотивларның активлашуы, республика язмышындагы мөһим вакыйгаларны, көн кадагындагы проблемаларны матбугатта җәһәт яктыртып бару ихтыяҗы жанрлар иерархиясендә дә чагылыш таба: аерым алганда, шигърияттә гражданлык һәм сәяси лирика жанрлары активлаша, әдипләр «фикерне публицистик характерда турыдан-туры җиткерү юлын кулай күрә, субъектив эчтәлек актуальлеген үзгәртә» [Йосыпова, б. 245].

Шушы шартлар татар поэмасының жанр эволюциясенә дә, һичшиксез, тәэсир итми калмый. 1960–1980 елларда традицион һәм авангард эзләнүләрне бер мәйданда берләштергән, форма һәм эчтәлек, сәнгати эшләнеш ягыннан үзгә баскычка күтәрелгән татар поэмасы, бер яктан, алдагы дәвердәге үсеш тенденцияләрен табигый рәвештә дәвам итсә, икенче яктан, заман вазгыяте белән билгеләнгән әдәби-эстетик үзгәрешләргә килә. Әйтик, элгәре елларда С. Хәким, Ә. Маликов, М. Шабаев һ.б. иҗатында үстерелгән эпик юнәлеш 1990 елларда тари-

хи шәхесләргә багышланган лиро-эпик әсәрләр бәйләмендә дәвам итерелә. Күренекле галим Т. Галиуллин сүзләре белән әйтсәк, «шагыйрьләр татар халкының тарихи шәхесләрен күтәрү, аларның тормышын, көрәшен үрнәк-өлге итеп күрсәтү юнәлешендә дә киеренке эзләнүләр алып баралар. Татар әдәбиятын кырмавык кебек басып киткән большевик образларын Кол Гали, Колшәриф, Сөембикә, Батырша, Тукай, Сәйдәш, Туфан кебек олы һәм фаҗигалы шәхесләрнең сыннары кысрыклый» [Галиуллин, б. 140]. Мәсәлән, 1980 елларда ук инде «Сөембикә» поэмасы белән «тыю мөһере сугылган тарихи чынбарлык сәхифәләре» [Мансуров, б. 156] ачып җибәргән Ә. Рәшитнең гасыр азагында иҗат ителгән «Колшәриф» (1990) һәм «Мөхәммәдьяр» (1995) поэмалары милли тарих сәхифәләрен заман, чор вазгыятенә аваздаш рәвештә торгызуы белән игътибарны җәлеп итә. Татарның җан ярасы – Казан ханлыгы һәлакәте укучының күңелен тетрәндерерә, уйландыра. Үткән һәм бүгенгене тыгыз-табигый үреп бирә алган шагыйрь татар тарихының төрле чорларын кисештерүгә ирешә, халыкның мәңгелек кыйммәтләр системасын барлый, милләтне милләт итеп яшәткән мәдәни кодларның иман, туган тел һәм рухи традицияләр булуын ассызыклый. Әлеге идея «Колшәриф» поэмасының дога шәкелендә язылган бетемендә махсус калкытыла: *И Раббым! Изге динебезне, телебезне-моңыбызны, ата-баба гадәт-йолаларын дәвам итү өчен һәммәбезгә иман вә куәт бир!* [Рәшит, б. 278]. «Мөхәммәдьяр» поэмасының диалог – Казан ханлыгы чоры һәм XX йөз шагыйрьләре әңгәмәсе формасында иҗат ителүе әсәрнең хронотобын гына киңәйтеп калмыйча, һәр татар сүз иясен борчыган гамьнәрне ачыкларга, вакыт кысалары белән чикләнмәс фәлсәфи гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек бирә. Әйтик, данлы тарих сәхифәләрен тергезгән Мөхәммәдьяр монологларында һәрнәрсәнең бетүгә юнәлгәнлеген, дан-шөһрәтнең вакытлыча булуын, яшәү – үлем арасы бер мизгелгә тиңләгән аңлаудан туган сызланулы хиссият әйдәп бара: *Вакытлыча бу җиһанда бөтенесе – / Әлмисактан мәгълүмме соң берәресе? / Кечкенәме, зурмы аның кылган эше, / Мәңгелеккә дәгъва итми һичбер кеше. / Матурлыклар бетә, асыл кием тузгач, / Батырлыклар онытыла, гомер узгач, / Баш та, таш та әверелә гади чүпкә – / Бу дөньяда ни кала соң ахыр чиктә?!»* [Рәшит, 2003: 70]). XX йөз шагыйренең шушы юлларга капма-каршы эчтәлектә яңгыраган фикерләре чор рухи-милли күтәрелешен, татар халкының киләчәгенә өмет-ышанычның какшамас булуын ачык чагылдыра: *Өмет соңгы чиктә сүнә барыбер дә... / Без һаман да исән әле... шул ук җирдә... / Мөмкин түгел безне алай тиз күмәргә, / Куркак кына тере көе гүргә керә* [шунда ук, б. 72]. Араларында биш гасырдан артык вакыт ятса да, ике шагыйрьнең дә максаты, мәсләге уртак – аларны татарның киләчәге өчен борчылу, халыкка хезмәт итү идеясе берләштерә. Мөхәммәдьяр авызыннан яшь каләмдәшенә җиткерелгән үгет-киңәш иҗат кешесенең җәмгыятьтәге урынын билгели, XX йөзнең соңгы чирегендә аеруча активлашып киткән шагыйрь-гражданин концепциясен алга чыгара: *Киңәшем бер: түз, сабыр бул, өмет өзмә, / Илдә кирәк хакыйкатьне үзең эзлә* [Рәшит, б. 79].

Гомумән, милләтнең киләчәген билгеләр ориентирлар, рухи идеал эзләп үткәнгә мөрәҗәгать итү, татар тарихының киң катламнарына төшү узган гасыр азагы эпик поэмасында төп тенденцияләрнең берсе булып китә. Тарихи теманың киң колач алуын Ә. Рәшит үзе туксанынчы еллар әдәбиятының иң зур казанышы дип атый [Туксанынчы еллар әдәбияты, б. 138], туган халкының төрле җиргә сибелгән тарихын тамчылап җыюның милләт киләчәге өчен кирәк булуын ассызыклый [Рәшит, б. 13]. Ә. Рәшит поэмаларыннан тыш, укучы хөкеменә бер-бер артлы тагын Җ. Дәрзаманның «Моңнар фәрештәсе» (1999), З. Мансуровның «Балкыш, яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар», Р. Зәйдулланың «Койрыклы йолдыз» (1985–1991), Р. Низаминың «Ике мөһаҗир» (2001) һ.б. поэмалар тәкъдим ителә. Бу әсәрләрне уртак тема, проблемалар, халкының рухи кыйммәтләрен раслау идеясе берләштереп, әдипләрнең эстетик идеалы үзендә татар холкына хас иң асыл әхлакый сыйфатларны туплаган тарихи образларда ачылса да, поэмаларның һәрберсе шагыйрьләрнең иҗади осталыгын ачып бирердәй югары кимәлле, сәнгати камиллеккә дәгъвалаган үзенчәлекле әдәби үрнәкләр буларак игътибарны җәлеп итә. Мәсәлән, Җ. Дәрзаманның татар җырчысы Гөлсем Сөләймановага багышланган поэмасында салмак-медитатив укылыш, лирик-фәлсәфи чигенешләр, әдәби текстка гаҗәеп гармонияле үрелеп килгән җыр текстлары үзенчәлекле аһәң тудыра. З. Мансуров һәм Р. Зәйдулла поэмаларының эчтәлеге исә катлаулы метафоралар, интертекстуаль бәйләнешләр, төрле стильләр синтезы, күптавышлылык һ.б. хисабына тыгызлана. Мәсәлән, З. Мансуров әсәрендә Бөек Ватан сугышы корбаны, татар шагыйре Хәйретдин Мөҗәйнең рухи халәтен бөтен төсмерләре белән ачкан лирик монолог аның көндәлекләреннән өземтәләр белән керешеп бара. Автор үзе әсәрнең жанрын «поэма-рулада» дип билгели һәм поэманың керешендә үк кеше гомеренең бер очкын сыман тиз үтеп китүен ассызыклый. Мәгънәле яшәүнең үлемсезлеккә алып килүе турындагы фикер белән тулыландырылган шушы фәлсәфи идея әсәрнең структур өлешләрен бер җепкә тезә. Соңгы бүлектә болгар тарихына мөрәҗәгать итү поэманың вакыт катламнарын тагын да киңәйтә, укучыны аерым шәхес язмышыннан татар халкының тарихы, тоткан юлы, яңарышы турындагы уйлануларга алып килә: *Без... яңадан яралганнар / мәгъмүр Болгар көленнән! <...> / Хәтта нәсел агачының / көле күккә очса да, / халык рухы, феникстай, / яңарырга көч таба!* [Мансуров, б. 130–131].

Нәтиҗә ясап әйтсәк, туксанынчы елларда эпик поэмада татар халкының тарихын, милли үзаңын торгызуга юнәлдерелгән тема-мотивлар, проблемалар алга чыга. Шул ук вакытта анда публицистиклык, гражданлык пафосы, чынбарлыкка тәнкыйди караш актуальләшә, көн кадагындагы мәсьәләләргә авторларның турыдан-туры бәя-мөнәсәбәте урын ала. Тоталитар үткәннәр белән бәйле демифологизация алымы әйдәп баручы сәнгати принципка әйләнә: поэмаларда еллар дәвамында сәяси кануннарның рухи кыйммәтләрне юк итүгә юнәлдерелгән булуын фаш итү тенденциясе киң чагылыш

таба. Мәсәлән, Ф. Яруллинның «Коткарыгыз» (1990) әсәре герое коммунистик режимга түбәндәге бәяне бирә: *Коммунизм дигәннәре / Әллә шушымы, димен. // Беркемнең бер нәрсәсе юк – / Бар да шәрә, бар да ач. / Эшләр өчен куллар бар да... / Иелер өчен – мескен баш* [Яруллин, б. 5], системаның үзгәрергә тиешлегенә ишарә итә. Э. Шәрифуллинаның «Тәмуг кисәве» поэмасында «сырхау дәүләт» гыйбарәсе белән тәгаенләнгән совет системасының интернациональ тәрбия сөреме аша милли үзаңны юкка чыгаруы татар халкының фаҗигасы буларак бәяләнә: *Бу безнең фаҗига, кадерлем, / Кайтарып ал идең – эш узган. / Өзелде буыннар – беркем юк, / Беркем юк, өч онык – өч кыздан. <...> / Нәрсә бирә, кая алып бара, / Имеш, надан әби мәктәбе. / Ялгышканбыз: фәкать шунда булган / Оят, / намус, / әдәп, / әхлагы* [Шәрифуллина, б. 65, 68]. Совет мифын деконструкцияләүгә юнәлдерелгән тенденция Ф. Гыйззәтуллинаның «Ирек юлы» (1992) поэмасында да дәвам иттерелә, шәхес культы еллары ачысын үз җилкәсендә татыган татар хатыны образы аша шагыйрә аерым шәхеснең ireккә бару юлын татар халкының рухи хөрлеккә ирешү юлы белән янәшә куя.

1980 елларда Х. Әюп тарафыннан гаҗәеп камил үрнәкләре тәкъдим ителгән лирик поэмага килгәндә, яңа унъеллыкта аның да үзгәрешләргә дучар булуы аермачык күзаллана. Күзәтүләрдән күренгәнчә, сентименталь-психологик эчтәлекле, публицистлыктан азат лирик поэмалар сирәк языла. Аерым алганда, Л. Шагыйрьҗанның, шагыйрә үзе билгеләп үткәнчә, «ниндидер бер катгый сюжетка корылмыйча, мәгълүм бер идея-төшенчә яисә предмет тирәсендә фәлсәфи-лирик уйланулар формасында язылган» [Поэма турында сөйләшәбез, б. 152] «Гүзәллек» (1993–1995) лиро-эпик әсәрендә төп структур үзәк булып матурлык категориясе калка. Лирик герой матурлыкны көндәлек гадәти күренешләрдә тоемлый: бер-бер артлы тезеп-саналып киткән яшел чирәм, үрдәк бибиләре, чишмәгә суга барган кыз көянтәләрендә чылтыр-чылтыр килгән чиләкләр, боз өстендә янган учаклар, тамчы гөлләр, җиләк тәме килгән исле сабын һ.б., һ.б. бик күп детальләр, бер яктан, яшәешнең илаһи гүзәллеген раслауга хезмәт итсә, икенче яктан, лирик геройның бай һәм матур күңел дөньясын ачып бирә. Шагыйрә үзенең иҗат максатын да нәкъ менә шушы матурлыкны укучысының рухына сеңдерерлек сүзләр табуда күрә: *Дөньядагы барлык гүзәл нәрсәләрне / шигыремә килә кертәсем. / Тирәмдәге бөтен матур кешеләрне, / табын җәеп, килә кунак итәсем* [Шагыйрьҗан, б. 304]. Шул ук вакытта гүзәллекне автор киң төшенчә буларак карый, аның мәгънәви кырын яшьлек, әхлакый кыйммәтләр, ирек һ.б. семантик төсмерләр белән тулыландыра. Шагыйрәнең үзе белән тәңгәл укылган лирик геройның экспрессив аң агышы рәвешендә калыплашкан хисле монологы әле гүзәллеккә табынган, әле шул матурлыкның юкка чыгуына сызланган, әле үткәннәрне сагынып сагышланган, әле яшь буынның әхлакый кануннардан читләшүен уйлап шөбһәләнгән ваемлы шәхес уйланулары буларак кабул ителә. Хис катламындагы мондый эмоциональ күчешләр җәмгыятьтә гүзәллекне юк итүгә китергән сәбәпләрне

тәнкыйтьләү белән кушыла. *Коткарырмы безне бу Гүзәллек, / биктә торгач үзе әсир булып?..* [Шагыйрьҗан, б. 299] дип сызланган лирик герой шагыйрь Зөлфәтнең 1976 елда ук язылган «Тыным бетте...» (1976) шигырендәге лирик геройның дәвамчысы буларак кабул ителә.

1990 еллар поэмасына тулаем үтеп кергән публицистлык лирик поэмага да эчтәлек һәм форма үзгәрешләре алып килә. Л. Шагыйрьҗанның «Менә шундый Казан ул!..» (1993), «Тукай тавышы» (1996) кебек поэмаларында инде бу үзгәрешләр ачык тоемлана. Аларда «тирән лиризм белән публицистик яңгыраш үзенчәлекле рәвештә үрелеп бирелә» [Габидуллина, б. 147]. Беренче поэмада, мәсәлән, әле XIX йөздә үк Г. Чокрый тарафыннан башланып, XX йөз башы татар әдипләре тарафыннан үстерелгән Казан образын сакральләштерү идеясе алга чыга. Бу идея поэманың беренче өлешендә туплана: лирик герой «җиһандагы һәр татарның кыйбласы, кәгъбәсе» булган Казанны һәрьяклап зурлый, аңа мәдхия укый. Әсәрнең киләсе өлешләрендә ул җәмгыять моделе буларак ачыла башлый: монда «хәерче дә, бае да», «белем эстәүчеләр дә, хәер эстәүчеләр дә», «шымчысы да, илче дә, тарихчы да, телче дә», «каләм тоткан шагыйрь дә, кылыч тоткан яугир дә» – кыскасы, яшәү максатлары төрледән-төрле булган кешеләр бергә кайный: *Менә шундый Казан ул! / Бик четрекле шәһәр ул... / Көенә килә белмәсәң, / Шәһәр түгел, каһәр ул...»* [шунда ук, б. 313]. Мактау-данлауга корылган пафослы башламның тәнкыйди-ироник хиссият белән алмашынуы, публицистик яңгырашлы тезмәләр, вәзен үзенчәлекләре әсәрнең экспрессив-динамик корылышын тәэмин итә, поэманы бу чорда актив үсеш алган трибун шигърияте үрнәкләренә якынайта.

Күренгәнчә, 1990 еллар татар поэмасы элгәре традицияләрне заман таләп иткән идея-эстетик эзләнүләр белән тыгыз үрә. Шагыйрьләрнең игътибар үзәгендә торган иҗтимагый-сәяси һәм милли проблемалар жанр үсешендә төп этәргечләрдән була, Г. Морат язганча, «сүз ирегенә бәйле рәвештә шигърияттә публицистик накал бермә-бер көчәеп китә» [Морат, 1994, б. 162]. Шагыйрьнең «Ачлык» (1991), «Вакыт машинасы», «Түбә» һ.б. поэмалары да шушы дулкында иҗат ителгән. Шигъри һәм чәчмә текстлар үрелеше рәвешендә калыплашкан «Ачлык» поэмасында, мәсәлән, публицистик һәм фәлсәфи катламнар татар халкының ил һәм кешелек тормышындагы урынын тәгаенләү белән бәйле. Поэманы иңләп үткән хәтер һәм ирек мотивлары (алар Рәш. Әхмәтҗановның 1993 елда язылган «Ачлык мәйданы» поэмасында да урын алачак) милли асылыңны, үзаңны югалтуны иң зур фаҗига итеп раслауга буйсындырыла. Лирик геройның ялвару-дога шәкелендә бирелгән монологы татар халкының иң зур омтылышын чагылдыра: *Улымны телсез калудан, / И Тәңрем, үзең сакла... // Сакла хәтерсез калудан, / Сакла Иделен, йортын. / Сакла берүк – / Хәтеребез / Болай да ярым-йорты* [Морат, б. 37].

Узган гасырның соңгы еллары әдәбиятын бәяләп, галимнәр һәм тәнкыйтьчеләр «эзоп теле икенче планга күчә» [Йосыпова, б. 244], аерым очракларда «публицистика алымнары поэзияне кысрыклап чыга-

ра, шигырь рифмалаштырылган мәкаләгә әйләнә яза» [Мостафин, б. 145], «лозунглылык, диалогларга нигезләнү, халыкка риторик мөрәҗәгать итү һәм милләт исеменнән сөйләү шигъриятне массачыл әдәбиятка тартым итә башлый» [Загидуллина, с. 9] дигән фикерләр әйтәләр. Бу сыйфатлар татар поэмасының да жанр үзгәрешләре нигезендә ята. Алдагы чорда Р. Фәйзуллин, И. Юзеев, Роб. Әхмәтҗанов, Зөлфәт һ.б. шагыйрьләрнең лиро-эпик мирасында активлашкан һәм поэма жанрын катлаулы ассоциатив дөнья, синтетизм, эчтәлекнең күпкатламлылыгы, стильләр үрелеше кебек сәнгати мөмкинлекләр белән баеткан, катлауландырган авангард эзләнүләр яңа иҗтимагый-мәдәни шартларда беркадәр «тынып» кала, яңа буын авторлар иҗатта концептуальлеккә өстенлек бирә башлыйлар. Шулай да жанр өлкәсендәге эзләнү-тәҗрибәләр туктала дип әйтү дөреслеккә хилафлык булыр – Р. Харис, Роб. Әхмәтҗанов, З. Мансуров, Р. Зәйдулла кебек шагыйрьләрнең лиро-эпик иҗаты шуны дәлилли. Әйтик, шушы чорда Р. Харисның интеллектуаль укучыга йөз тоткан «Чехов базары» (1997), «Бүре күзе» (1999) «Харут белән Марут» (2000) кебек поэмалары дөнья күрә. Беренче поэмада лирик геройның Казандагы мәгълүм базарга «сәяхәте» җәмгыять яшәешенең һәр очракта да мантыйк кануннары белән аңлатып булмас (*Тормыш начарайган саен, гаҗәп, / матурая бара базарлар* [Харис, б. 163]) шартлы сурәтен тудырырга мөмкинлек бирә. Сатучылар һәм базарга килүчеләр белән әңгәмәләрдә заманның күптөрле проблемалары калкытыла. Бу күптавышлылык, мозаиклык, поэманың билгеле бер катгый эзлеклелектән азат булуы заманның катлаулы чуар манзарасын күз алдына китереп бастыра. Базар таркау, буталчык постсовет җәмгыятенең шартлы моделе кебек кабул ителә, ироник, аерым очракларда сарказм битлеге астына яшеренгән лирик геройның, асылда, ил һәм халык киләчәге өчен шөбһәләнгән, битараф булмаган шәхес икәнлеге тоемлана. «Харут белән Марут» поэмасында да җәмгыять яшәешенә сатирик бәя беренче урынга чыга. Дини тәгълиматлар белән бәйле сюжетны сәнгатьчә эшкәртеп, шагыйрь бу ике фәрештә образын чорына хас барлык тискәре сыйфатларны гәүдәләндерүче образ буларак тасвирлый. Шул ук вакытта аерым шәхеснең җәмгыятьне үзгәртә алмавын аңлау (*Ә кешегә иң зур җәза – / фәрештә булып яшәүдер»* [шунда ук, б. 237]) лирик геройның сызланулы халәтенә сәбәпче була.

З. Мансуровның «Хозыр галәйһиссәламне эзләү» (1991) поэмасы да мифологизмга корылган. Урта гасырлар төрки-татар әдәбиятына хас кыйсса жанрына стилизация буларак иҗат ителгән әлеге поэма текстка төрле жанрлар – бишек җыры, риваять, каргау һ.б. кертелү хисабына катлаулана, «милли, фәлсәфи катламнарны төенли, анда иҗтимагый хәл-халәткә милли-сәяси бәя дә урын ала» [Йосыпова, б. 257]. XX йөз башы татар әдәбиятыннан ук килгән йокы мотивы аша шагыйрь җәмгыятьтәге битарафлык проблемасын күтәрә һәм халыкның киләчәге турында борчулары белән уртаклаша: *Халык үлеп йоклады, / кулы кулга йокмады; / «Татлы-тәмле» өнендә / аздан... телен йотмады* [Мансуров, б. 56]. Татар халкының киләчәген куркыныч астына куйган

күренешләр арасында ул авылларның юкка чыгуын, әхлак бозылу, диннән ерагаю кебекләрне атый. Үткән һәм бүгенгегә бәя бирү белән янәшә, автор яшәеш кануннары, яшәү мәгънәсе, дин, милли үзаң, туган тел төшенчәләренең кагылгысызлыгы һ.б. турында фәлсәфи уйлануларга бирелә. Кешелекнең яшәү максаты эпиграф итеп сайланган хәдистә ассызыклана: *Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйтте: бу тормыш – бер сәгатьлек, шунлыктан аны изге эшләргә файдалан* [Мансуров, б. 33]. Поэмадагы төрле катламнарны бергә төйнәгән Хозыр галәйһиссәлам образы «Аклык, Сафлык, Мәрхәмәтлелек үрнәге, ягъни архетип буларак кабул ителә» [Йосыпова, б. 257]. Лирик геройның *пакьләндергеч* эпитеты белән зурланган Хозырны табарга теләве татар халкының милли асылын тәшкил иткән сыйфатларны: иман, кешелеклелек, олыларга хөрмәт, намуслылык һ.б. торгызу, халыкның рухи яңарыш, катарсиска мохтаҗ булуын аңлату омтылышы буларак укыла.

Шагыйрь Р. Зәйдулланың «Матәм» (1987–1990) әсәре дә 1990 еллар татар лиро-эпикасының казанышы булып санала ала. Күптавышлылыкка корылган, чәчмә һәм шигъри формалар, салмак-медитатив һәм «аң агышы» рәвешендә язылган текстлар синтезыннан гыйбарәт бу поэмада шагыйрьнең иҗтимагый-сәяси, гражданлык, фәлсәфи карашлары туплана. Поэманы бер җепкә тезгән вакыйга буларак Мөхәммәт исемле яшь егетнең әфган якларында һәлак булуын тасвирлап, шагыйрь шушы хәлгә төрле ноктадан караш ташлый: бабасы Әюп өчен оныгы вафаты – олы фаҗига, әмма патриотик рухта тәрбияләнгән карт моны язмыш сынавы итеп кабул итә; җирле үзидарә рәисе өчен авылдашының үлеме бюрократлык системасында коры бер белешмә кәгазе булып югалачак бер әһәмиятсез вакыйга гына; сөйгәне өчен – кыска вакытлы тетрәнү. Шагыйрь кешенең кадерен белер иманлы заман килергә тиешлегенә ышана: *Тик иманны саклап, / Барыбер / Илтәчәкбез киләчәккә тикле* [Зәйдулла, б. 14]. Поэманың соңгы юлларында егетнең исеменә бәйле дини интертекстуальлек махсус калкытыла: *Эзлим мин юл. / Йөрәкләрдән эзлим – / Табарбызмы кыяматкә хәтле / Мөхәммәтне – димәк, мәхәббәтне, / Мөхәммәтне – димәк, мәрхәмәтне?!* [шунда ук, б. 15]. Шул рәвешле, татар дөньясының барыр кыйбласы (автор аны юл мотивы аша бирә) иманлы, кешелеккә мәхәббәт һәм мәрхәмәт белән тулы булырга тиешлеге турындагы идея яңгыратыла.

Гомумән, XX йөз ахыры татар поэмасы, халык, милләт, тел, тарих, дин һ.б. проблемаларны үзәккә куеп, шушы идеяләрне турыдан-туры әйтеп бару, концептуальлек юлыннан китә. Эчтәлек, фикерне алгы планга чыгару публицистлыкны көчәйтә, күпмедер бертөрлелеккә, кабатлауларга китерә. Бу, үз чиратында, төрле бәхәсләр дә китереп чыгара. Мәсәлән, «Казан утлары» журналының 2000 елгы 9 нчы санында, «Поэма турында сөйләшәбез» дигән исем астында, Татарстан Язучылар берлегендә үткәрелгән түгәрәк өстәлдән бер төркем әдәбият әһелләренең жанрның киләчәге турында дискуссия, фикер алышу нәтиҗәләре дөнья күрә. Монда яңгыраган карашлар төрле һәм каршы-

лыклы: әдипләр һәм тәнкыйтьчеләр поэманың сюжетлылык белән генә чикләнергә тиеш түгеллеген, күләмле лирик монолог рәвешендәге эмоциональ-хисси тезмәләрнең дә жанрны баету мөмкинлеген (Л. Шагыйрьҗан), яки, киресенчә, «сюжетлы чын поэзия жанрларын terelтү, аларны янә әдәбият мәйданына чыгару юлларын эзләргә» кирәклеген (С. Хафизов) ассызыклыйлар, фәлсәфи тыгызлыктан, артык детальләрдән качарга тәкъдим итәләр (Ш. Маннапов)... [Кара: Поэма турында сөйләшәбез]. Мондый дискуссияләр поэманың үсеш-үзгәреше әдәби җәмәгатьчелекне битараф калдырмавы турында сөйли.

Шул рәвешле, 1990 еллар татар поэмалары алдагы елларның бай әдәби традицияләрен яңа гасырга китереп җиткерәләр һәм, заман кануннарына, халыкның рухи ихтыяҗына нигезләнеп, яңа үсеш сукмакларын барлыйлар.

**Әдәбият**

*Габидуллина Ф.И.* XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятында поэма жанры үсеше. Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2021. 160 б.

*Галиуллин Т.Н.* Шигырь кемгә кирәк? // Казан утлары. 1995. № 7. Б. 139–142.

*Загидуллина Д.Ф.* Татарская поэзия рубежа XX–XXI веков (1986–2015 гг.): эстетические ориентиры и художественные поиски. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. 268 с.

*Зәйдулла Р.* Мәтам // Казан утлары. 1991. № 1. Б. 3–15.

*Йосыпова Н.М.* XX гасырның икенче яртысы татар шигърияте: традицияләр һәм яңачалык. Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2021. 296 б.

*Мансуров З.* Яшәү үзәне: шигырьләр, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 319 б.

*Мансуров З.* «Мөмкин» белән «түгел» арасы // Казан утлары. 2006. № 2. Б. 151–159.

*Морат Г.* Шигърият – сәясәт түгел // Казан утлары. 1994. № 8. Б. 162–164.

*Морат Г.* Төнге әверелеш: шигырьләр, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 399 б.

*Мостафин Р. Ә.* Шигъри публицистика // Казан утлары. 1995. № 7. Б. 142–146.

Поэма турында сөйләшәбез // Казан утлары. 2000. № 9. Б. 148–159.

*Рәшит Ә.* Таң илчесе: шигырьләр, җырлар, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 80 б.

Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 5. Б. 137–139.

*Харис Р.* Сайланма әсәрләр: 7 томда. 4 т.: Поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 367 б.

*Шагыйрьҗан Л.* Божра вә Хөҗрә: шигырьләр, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 368 б.

*Шәрифуллина Э.* Тәмуг кисәве // Казан утлары. 1991. № 8. Б. 64–68.

*Яруллин Ф.* Коткарыгыз // Казан утлары. 1991. № 9. Б. 3–6.

***Надыршина Ләйсән Рәдиф кызы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 7.01(093.3)

***Ф.Г. Фәйзуллина,***
***Г.М. Ханнанова***

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ КӨНДӘЛЕКЛӘРЕ БУЙЛАП МӘДӘНИ СӘЯХӘТ

В 2023 г. исполняется 145 лет со дня рождения выдающегося татарского писателя, политического и общественного деятеля Гаяза Исхаки. По этому случаю в ряду мероприятий Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ предусмотрено издание первой части его дневников, охватывающих период его поездки из Японии в Париж (апрель 1919 – март 1920 г.). В дневниковых записях Гаяз Исхаки предстает не только как политический и общественный деятель, но и обладающий тонким вкусом поклонник искусства. Где бы Исхаки ни оказывался, он старался посетить местные музеи, театры, выставки, музыкальные и художественные школы. Полагаем, что наблюдения за культурной жизнью других стран, нашедшие отражение в дневнике Г. Исхаки позволят лучше понять и осветить жизнь писателя в эмиграции.

**Ключевые слова:** татарская литература, Гаяз Исхаки, тюрко-татарская эмиграция, мировое искусство, дневники, текстология татарской литературы.

2023 marks the 145th anniversary of the birth of the outstanding Tatar writer, political and public figure Gayaz Iskhaki. On this occasion, in a series of events of the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan it is planned to publish the first part of his diaries covering the period of his trip from Japan to Paris (April 1919 – March 1920). In the diary entries Gayaz Iskhaki appears not only as a political and public figure but also as an art lover. Wherever Ishaki found himself he tried to visit local museums, theaters, exhibitions, music and art schools. When describing what he saw the writer appears not just as a spectator but as a subtle critic. We believe that observations on the cultural life of other countries reflected in the diary of G. Iskhaki will allow you to better understand and illuminate the writer's life in exile.

**Keywords:** Tatar literature, Gayaz Iskhaki, Turkic-Tatar emigration, world art, diaries, textual criticism of Tatar literature.

XX йөз башы татар иҗтимагый-сәяси үсешендә, әдәби-мәдәни алгарышында тирән эз калдырган шәхесләрнең берсе Гаяз Гыйлаҗетдин улы Исхакыйның (1878–1954) тууына 2023 елның 23 февралендә 145 ел тулды. Татар әдәбиятының милли хәзинәсен тәшкил иткән хикәя, повесть, роман, пьесалары аша классик язучыга әверелгән әдип, үз халкы мәнфәгатьләрен яклауга багышланган бай публицистикасы белән, күренекле җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче буларак та алгы сафка чыкты.

Гаяз Исхакый – халкына еллар үтеп тә югалмас, үз төсен җуймас рухи байлык калдырган әдип. Аның чит җирләрдә чәчелеп яткан бай мирасының, төрле киртәләрне җимереп, унбиштомлык «Әсәрләр»

тупланмасы рәвешендә әйләнеп кайтуы моның ачык дәлиле булып тора. Язучының һәр әсәрендә тормыш фәлсәфәсе ярылып ята, кешелек сыйфатлары мактала. Аларда күтәрелгән мәсьәләләр, һәр чорның үз төсмерен алып, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткәннәр һәм әле дә актуаль булып кала бирәләр.

Г. Исхакыйның исеме татар халкы тарихыннан аерым була алмый. Ул үзенең әдәбият-сәнгать, иҗтимагый-сәяси, матбугат, мәгариф өлкәләрендәге эшчәнлеге белән милләт лидерына әверелде. Аның бөтен гомерен сугарган бердәмлек һәм мөстәкыйльлек идеясе, башкаларны да дәртләндереп, үз артында милли көчләрне туплады.

Гаяз Исхакыйның юбилеен без нинди уңышлар белән каршы алабыз соң? Аның исемен мәңгеләштерү юнәлешендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты нинди яңалыклар тәкъдим итәчәк?

Г. Исхакый – Татарстаннан читтәге татарлар арасында да мәгълүм шәхес. Ул Харбинда, Франциядә, Германиядә, Польшада, Төркиядә, татар мөһаҗирләрен берләштерергә омтылып, халкының киләчәге өчен бөтен барлыгын да кызганмаган. Аның исеме бүген дә халыкара мәйданда яңгыратуга лаек. 2023 елның 24–25 апрель көннәрендә Казанда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан үткәреләчәк «Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме: теория, методология, практика» дип исемләнгән III Халыкара фәнни-гамәли семинар татар әдәбияты классигы, публицист, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Исхакыйга багышланачак. Аның тормыш юлын, әдәби эшчәнлеген өйрәнү буенча эзлекле төстә алып барыла торган эшләрнең бер дәвамы буларак, фәнни-тикшеренүләргә багышланган әлеге семинар материаллары аерым җыентык рәвешендә дөнья күрәчәк.

Г. Исхакый – көчле каләм иясе. Бәйсезлек өчен көрәш юлында үзенең публицистик язмаларын ул тәэсирле бер көчкә әверелдерә. Аның, төрки-татар дөньясының мәгънәви җитәкчесе буларак, «Милләт саг *(сау)* булсын!» дигән девиз астында язылган мәкаләләре бүген дә игътибарга лаек. Г. Исхакыйның тормышы һәм иҗаты, XX йөзнең беренче яртысында татарларның иҗтимагый һәм мәдәни тормышы белән кызыксынучыларга язучының 1905–1936 еллар аралыгында милли үзаң, татар теле, әдәбияты, мәдәнияте мәсьәләләренә багышланган публицистик хезмәтләрен туплаган аерым китап тәкъдим итела. Филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА академигы Д.Ф. Заһидуллина редакциясендә М.И. Ибраһимов тарафыннан төзелгән «Милли куәтләр бардыр = Есть сила в нации» дигән китапның ике телдә басылуы Г. Исхакыйның аерым игътибарга лаек фикерләрен рус телле укучыларга да җиткерә алачагы белән зур әһәмияткә ия. Китапта урын алган хезмәтләр Г. Исхакыйның татар халкының милли-мәдәни үсеш юлындагы эш-гамәлләрен тирәнрәк аңларга ярдәм итәрләр дип көтелә.

Г. Исхакый юбилее уңаеннан башкарылган эшләрнең иң мөһиме – әдип көндәлекләренең беренче китабы дөнья күрүе.

2018 елда, укучыларны әдипнең Төркиядән кайткан материалларының кайберләре белән таныштыру йөзеннән, көндәлекләрнең 2–6 нчы дәфтәрләре Институтның Язма мирас үзәге фәнни хезмәткәрләре тарафыннан эшләнеп, берникадәр кыскартулар белән, «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» җыентыгының Г. Исхакыйга багышланган 5 нче чыгарылышда басылганнар иде. Китапта кыскартылып, төшереп калдырылган өзекләр тулыландырылып, текстлар яңартылып урнаштырылды.

Бүгенге көндә безнең кулыбызда Г. Исхакыйның 41 көндәлек дәфтәре бар. Әдип кичергән шартларда аларның шулкадәр күләмдә сакланып калуы үзе бер могҗиза дияргә кирәк. Чөнки, Г. Исхакый бер урыннан икенчесенә күченеп йөргәнлектән, аңа кайвакыт кыйммәтле документларын калдырып та китәргә туры килә. 1939 елда Варшавадан аның бер чемодан белән генә чыгып китүе дә мәгълүм. Димәк, әлеге көндәлекләр, аның иң кыйммәтле әйберләре исәбеннән, һәрвакыт үзе белән йөргәннәр булса кирәк. Г. Исхакый үлгәннән соң, бу язмаларның саклануында 1988 елның 13 октябрендә Әнкара шәһәрендә оешкан «Аяз – Таһир (Төркестан – Идел-Урал)» фонды зур ярдәм күрсәтә. Кызы профессор Сәгадәт Чагатай тырышлыгы белән төзелгән әлеге фондта сакланган Г. Исхакый мирасы 2018 елда әдипнең үз ватанына кайтты. Материалларның төп нөсхәләре, 2008 елда тапшырылган электрон күчермәләр белән бергә, Институтның Язма мирас үзәгендә Г. Исхакыйның шәхси фондында саклана (135 нче фонд). Бу документларны, Г. Исхакыйның васыятен үтәп [Исхаков, 14 т., б. 410], Институт мирасханәсенә тапшырганы өчен, без «Аяз – Таһир (Төркестан – Идел-Урал)» фондының җитәкчесе Түләй Дуран ханымга рәхмәтле.

Китапта Г. Исхакыйның 1919 елның 26 апреленнән 1920 елның 10 мартына кадәр Токиодан Парижга барганда күргәннәрен тасвирлаган 16 дәфтәре урын алды. Кызганыч, 1 нче дәфтәр сакланмаган. Бу басма филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА академигы Д.Ф. Заһидуллина кереш сүзе белән, Институтның текстология бүлеге фәнни хезмәткәрләре Ә.Х. Алиева (7, 8, 9, 10, 11 нче дәфтәрләр), Ф.Г. Фәйзуллина (2, 3, 5, 6, 16, 17 нче дәфтәрләр) һәм Г.М. Ханнановалар (4, 12, 13, 14, 15 нче дәфтәрләр) тарафыннан әзерләнде.

Көндәлекләрне укый башлау белән, алар укучыны тулысынча Г. Исхакый үткәргән көннәргә алып кереп китә. Сәяси мәнфәгатьләрне кайгыртып, солых сәфәренә дип чыгып киткән Г. Исхакый биредә сәнгать сөюче буларак та ачыла. Кайда гына тукталсалар да, ул, матди хәленең авыр булуына да карамастан, чит илнең мәдәният учакларына тартыла. Биредә әдипнең Токио – Париж юлындагы мәдәни сәяхәте белән танышып китәрбез.

Г. Исхакыйның көндәлек дәфтәрләре «Бүген иртәдән үк музейлар карарга, сәнаигълык[1] выставкасы карарга китәмез» дигән сүзләр белән ачыла. Токио шәһәренә килгәннең беренче көннәреннән үк

[1] Сәнаигълык – сәнгать.

Япония сәнгате белән танышуны ул музыка мәктәпләреннән башлый. Укучылар арасындагы «бик матур кыз тавышлары, бик көчле ир тавышлары»н күзәтү белән бергә, биналарның ничек урнашулары, бүлмәләрдәге уңайлыклар, алардагы һаваның чисталыгы да Г. Исхакыйның игътибарыннан читтә калмый. Гомумән алганда, барысы да «бик матур тәэсир калдыралар».

Сәнаигы нәфисә күргәзмәсендәге рәсемнәр Г. Исхакыйга «бер караганда бик оригинальный күренсәләр дә, икенче караганда бер йире тулмаган кебек хис ителәә, эшләп йитмәгән хиссиятене калдыра»лар.

«Иң күбесе – табигать манзаралары, икенче дәрәҗәдә – кошлар-хайваннар. Өченче дәрәҗәдә – адәм рәсемнәре, гомумән караганда, бөтен рәсемнәрдә әллә нинди буяу җитми. Әллә нәрсәсе тонык, әллә нәрсәсе җитмәгән, әллә нәрсәсе ким. Үзе тәмамән рәсем, үзе тулы түгел. Япониянең чәчәге, чәчәкнең иң зур бер хасияте булган истән мәхрүм булган кебек, мондагы рәсемнәр дә рухтан, җаннан мәхрүмнәр. Хосусан, адәм сурәтләренең һичбер җаны юк. Бите тонык, күзе япон, ирене үлгән».

Г. Исхакыйның күңеленә иң хуш килгән «рәсемнәр, шөбһәсез, кошлар рәсеме вә, гомумән, хайваннар рәсеме. Боларны япон рәссамнәре фәукыльгадә[1] бер мәхәббәт берлән эшләгәннәр, бик нечкә иттереп аңлап, аларны җанландырып утыртканнар».

Күргәзмәдәге күзәтүләреннән чыгып, Г. Исхакый «гомумән караганда, япон рәссамнары буяуны истигъмальдә[2] үзләренә бер юл кулланалар икән. Рәссамлыкта иң авыр булган осталык, адәм баласының бөтен әхвале рухиясене ингыйкяс иттерә торган[3] йөз, күзне тасвир итү әле аларга мөяссәр булмаган[4] икән. Әле япон рәссамы бөтен кайгыны, бөтен шатлыкны, бөтен тәэсиратны бергә җыеп, йөзгә бирер дәрәҗәгә кадәр үсмәгән икән. Мадам ки[5] юлына кергәннәр, мадам ки шулкадәр уртача осталар йитешкән, әлбәттә, зур осталар да, талантлар, даһилар да җитешкәндер» дигән нәтиҗәгә килә.

Сәясәтче буларак, Г. Исхакыйны Токиодагы тарих музее бик кызыксындыра. «Әлбәттә, монда Шәрык булганга, бөтен нәрсәләр – Шәрык мәгъмулаты[6]. Әлбәттә, боларның да барысы да Шәрыкта, Кытайда, Японда бик күптән бирле мәдәнияттә барлыгына аяклы дәлилләр». Ләкин бик күп тарих музейларын күргән Исхакый монда искитәрлек нәрсәләр тапмый. Биредә аның игътибарын җәлеп иткән нәрсә – «иске япон савыт-сабалары арасындагы бик матур комганнар». Аның «болар нәрсә?» дигән соравына японнар, су савыты, дип

[1] Фәукыльгадә – гадәттән тыш.
[2] Истигъмальдә – куллануда.
[3] Ингыйкяс иттерә торган – чагылдыра торган.
[4] Мөяссәр булмаган – мөмкин булмаган.
[5] Мадам ки – шулай да.
[6] Мәгъмулат – эшләп җитештерелгән нәрсәләр.

җавап бирәләр. «Димәк, комган – безгә гарәпләрдән килгән бер нәрсә түгел, үземезнең өемездә электән булган».

Токиодагы көтепханә, Г. Исхакыйның күзәтүләренә караганда, «Петербург көтепханәсенә караганда күп кечкенә, ләкин алай да ярамаслык түгел». Махсус рөхсәт алып, алар китаплар саклана торган бүлмәләргә керәләр. Алты катлы бинаны берәм-берәм карап чыгалар. «Көтепханәнең бинасы һәйбәт иттереп эшләнгән. Эчендә хосусый биш йөз меңләп җилд[1] китап бар икән. Иске кытайча, корейча китаплар да бик күп икән. Иске төрек китаплары юк, гарәп-фарсы әсәрләре юк, дип белешәмез, фәкать бер данә “Мөгаллиме сани”[2] дигән китапка гына очрыймыз. Монда әле тюркология фәне бер дә куелмаган булырга кирәк. Үзләренең әйтүенә караганда, китапларының илле мең җилде генә әҗнәби[3] Европа телендә булса да, күзгә күренүгә караганда, бик күбесе инглизчә булырга охшый».

Хайваннар музеенда Г. Исхакый дөя белән маймылдан башка андый-мондый искитәрлек нәрсәләр очратмый. Бары аквариумнарының бик зәгыйфь булуы гына гаҗәпләндерә *(1919 ел, 26 апрель)* [Исхакый, 2 нче дәфтәр].

Якшәмбе көн японнар ял иткәнгә, төрле дәүләт оешмалары, илчелекләр, кибетләрнең күбесе ябык була. Г. Исхакый мондый көннәрне күбрәк мәдәни чараларга багышлый.

27 апрель якшәмбе булганга, Г. Исхакый диңгез министрлыгы музеен карарга бара. «Зур сарай кебек мөкәммәл[4] бинаның өч каты рус-япон сугышында алынган ганимәт маллары[5] берлә тулган. Сугыш көймәсеме дисең, коралмы дисең? Диварларда – диңгез сугышларының рәсемнәре. Менә Русиянең Шәрыкка таба атлавына беренче зарбә[6] булган Сутим сугышының[7] манзаралары. Менә аның башы, менә аның иң каты вакыты, менә япон флотының галибәсе[8]... Диварлар сугышта батырлык күрсәткән офицер-солдатларның рәсемнәре берлән туп-тулы. Шкафлар руслардан алынган көймәләрнең сыниклары берлән шыгрым тулы. Музәханәнең йортына да иске туплар тезелгән». Г. Исхакый үзенең тәэсирен «Барысы да Русиядән алынган. Барысы да – Русиянең 904 нче елгы ахмаклыгының аяклы

---

[1] Җилд – том.

[2] «Мөгаллиме сани» – («Икенче укытучы»). Биредә сүз Һ. Максудиның 1902 елда өлкән сыйныфлар өчен гарәпчә укырга-язарга өйрәткән әлифбасы турында бара.

[3] Әҗнәби – чит.

[4] Мөкәммәл – камилләшкән.

[5] Ганимәт маллары – сугышта кулга төшерелгән дошман малы.

[6] Зарбә – сугу.

[7] Сутим сугышы – Цусима сугышы – Япон диңгезендәге Цусима утравында 1905 елның 14–15 маенда вице-адмирал З.П. Рождественский җитәкчелегендәге Россия Тын океан флотының 2 нче эскадрасы адмирал Хэйхатиро Того җитәкчелегендәге Япония Император флоты тарафыннан җиңелүгә дучар ителә.

[8] Галибәсе – өстенлеге, җиңүе.

дәлилләре[1]» дигән җөмләләр белән белдерә *(1919 ел, 27 апрель)* [Исхакый, 2 нче дәфтәр].

Г. Исхакый чит илдә булуына, аларның телләрен белмәвенә дә карамастан, концерт, театрларга йөрергә ярата. Кая барса да, Г. Исхакыйның кызыксынучанлыгы сизелеп тора. Тамашаны тасвирлый башлаганчы, ул иң элек концерт залын күз алдыннан кичерә, анда килгән халыкның нинди сыйныфтан булуын тикшерә, хәтта байча киенгән хатыннарны да барлап алырга өлгерә.

*1919 ел, 17 май.* «Бүген мин төрекчә[2] белә торган япон берлән японнарның милли концертларына бардым. ...Өч-дүрт кеше «Юләр яз» дигән музыка парчасын уйнап чыгалар. Беренче башлап уйнаганнары – бию көе, күңелле генә, җиңел генә, безнең «Әтнә көе»нә бик охшаган. Монысында музыйкый як[3] куәтлерәк, урталары да бер җырдан гына гыйбарәт түгел, бер вәзене бар, ахыры тагы күтәренке кылларда шатлыклы, кәефле бию тавышлары берлә бетә. Монысы соңгырак заманның көе икән. Шуннан соң тагы пәрдә ябылып, пәрдә ачылган. Бер хатын, ике ир чыгып тезләнәләр. Хатын уртада, кулында өч кыллы гитара. Хатынның бер ягыннан бер ир курай тоткан, икенче ягыннан бер сукыр берничә кыллы озынча иттереп эшләгән цитра кебек нәрсәне йиргә сузып салган (буе ике аршын кадәре бар). Менә бер яктан уйный башлыйлар, икенчедән, үзләре йырлыйлар. Боларның уен коралларыннан да, үзләреннән дә өчесеннән өч төрле тавыш чыгып, бергә кушылганда бик матур булып китә. Озын бер көй уйныйлар, йырлыйлар, безнең «Агыйдел буйлары»[4] дигән көйне хәтерләтә. Кайбер йирләре тәмам безнең көй төсле булып, кайбер йирләре бөтенләй «чәһәршәмбегә» борыла[5]... Хосусан, курайчының борып йибәрүләре тәмам башкорт дәртләрен күз алдына китерә (курае камыштан). Халык бик каты кул чавып[6] озата.

Аннан соң бер мәгънәсез нәрсәне бик озын чыелдаталар, аннан соң бию. Ләкин бию гади бию түгел: гакылдан язган бер хатынның биюе...». Уйнаучылар, җырлаучылар, биюче хатын – барысы да, тамашачылар дикъкатен җәлеп итсәләр дә, 3 сәгатькә сузылган концерт Г. Исхакыйга артык тәэсир итми. Читтән килгән кеше буларак, «Гомумән, музыкалары бик ибтидаи хиссият калдыра. Бер дә тәрәккый итмәгән булырга тиеш. Номерлары бик озын – тавышның әйләнүе бик бер төсле. Йырлаучыларның тавышлары бер дә матур түгел»

[1] Русиянең 904 нче елгы ахмаклыгының аяклы дәлилләре – Биредә 1904–1905 еллардагы Рус-япон сугышы күз алдында тотыла. Бу бәрелеш, Маньчжурия һәм Корея өстеннән контроль урнаштыру өчен, геополитик көндәшлек аркасында башлана. Сугыш Россиянең җиңелүе белән тәмамлана. Нәтиҗәдә Россия үзенең хәрби диңгез порты булган Порт-Артурны һәм Сахалинны японнарга бирергә мәҗбүр була.

[2] Төрекчә – төркичә.

[3] Музыйкый як – музыка ягы.

[4] «Агыйдел буйлары» – татар халык җыры.

[5] «Чәһәршәмбегә» борыла – биредә: бөтенләй читкә китә, безнең көйгә ошамый, дигән мәгънәдә.

[6] Дөресе: чабып.

кебек күренә. Әдип әлеге концертта европалыларның юклыгына да игътибар итә [Исхакый, 4 нче дәфтәр].

*1919 ел, 22 май.* «Кич берлә безнең «Империал» отельда танса булды. Бик күп кунак. Токио, Йокоһамадагы Европа халкының бик күбесе килгән... Танса – Америка тансасы. Гаҗәп бер танса. Һичбер төрле хәрәкәтләрдә, кыланышларда матурлык юк, һичбер күзне көлдерә торган кеше бизәкләре ясау юк. Ир берлә хатын берсенә-берсе бик янәшә килеп кыймылдашалар да, бик каты ышкынышалар... Тансалар берсе артыннан берсе дәвам итә, ләкин һәммәсендә дә мәркәзе сикълә т[1] музыкальныйлыкта түгел, фәкать тәнне-тәнгә ышкышуда». Биючеләрнең мондый кыланышлары Г. Исхакыйда бары чиркангыч хисләр генә калдыра. Ул үзалдына: «Русларда бу кадәр тупас хайвани тансалар булмый», «ләкин Америкада нәфасәт, нечкәлек кебек хисси нәрсәләр юк булырга тиеш. Һәрнәрсә торгаший аршины берлән, гирь берлән, доллар берлән үлчәнә. Җирәнгеч», – дип язып куя [Исхакый, 4 нче дәфтәр].

Г. Исхакыйны мондый концерт, кичәләргә, беренче чиратта, кызыксыну йөртә булса кирәк. Ләкин шул ук вакытта ул, бу көндәлекләренең киләчәктә басылып чыгуына ышанган кебек, язмаларын укучылар өчен яза. Үзе керәсе бина күренү белән үк, аның һәрбер детален онытып калдырмаска тырышып, җентекләп тасвирлый. «Кич берлән японнарның иске театрларына барамыз. Аяктан ботинкаларны чыгарып, оекчан көенчә керәмез. Театрның бинасы бик зур. Үзе агачтан эшләтелгән булса да, стиле матур. Ишектән керүгә диварга сөяп куйган бик күп сонгый[2] букетлар каршы ала. Болар – артистларга бирелгән бүләкләр. Идәндә җефәк арканнар берлән бәйләгән бүләк сандыклары тезелгән. Эчкә керәмез. Театр дүрт почмаклы иттереп эшләтелгән. Каршы якта сәхнә. Ләкин сәхнә эчкә кереп тормый, бәлки уртага таба чыгып тора. Уртага камыш намазлык җәйгәннәр дә, аны ике кеше сыярлык дүрт почмаклы шакмакларга тәбәнәк кенә киртә берлән бүлгәннәр. Ул шакмакларның идәненә кечкенә мендәрләр салганнар. Сәерчеләр[3] шуларга кереп утырган. Зуррак кешеләр икешәр-өчәр, бала-чагалар дүртәр утыралар. Һәрбер шакмак эчендә бер гаилә. Ул үзенең шакмагында мохтар[4] түгел, камыш намазлыклы мохтар. Яртысы, иң тугрысы, идән сәхнәдән ерагайган саен, өсткә таба күтәрелә барган сәхнәнең сул-уң як канатлары тәмам күтәртеп үк эшләтелгән. Партерыннан соң тагы бер кат бар. Аннан соң тагы бер кат. Без сәгать җиделәрдә барганга, яхшы урын юк. Алай да безне идәндәге бер шакмакка утырталар, астымызга мендәр салалар, алдымызга кечкенә генә мангал бирәләр. Бер чәйнек берлән япон чәе, кечкенә генә савытларда ике төрле япон татлысы, япон хәлвәсе китерәләр. Театр дәвам итә. Фәкыйрь бер гаиләнең ярлылык фаҗигасы.

[1] Мәркәзе сикләт – монда: хикмәт.
[2] Сонгый – ясалма.
[3] Сәерчеләр – тамашачылар.
[4] Мохтар – ирекле.

Әллә нинди сүзләр, бер нәрсә түгел. Уйнаулары һаман бер төсле. Артта чылтыр-чылтыр итеп думбыра суккалыйлар. Әллә нидә бер нечкә, җиңел тавыш берлән бер бала сузып-сузып бер нәрсә сөйли, күренмәенчә әллә кем, әллә нәрсә йырлый. Артистка ролен уйный торган зур иләмсез япон яшел тавыш берлән сөйләп, бер туктамаенча еглый».

Әлеге театр япон халкының айга бер яки ике айга бер мәртәбә иртәнге сәгать уннан кичке сәгать унбергә кадәр утырып, гаиләсе белән ашап-эчеп көн үткәрә торган урыны булганга, алар бик ярат-са да, Г. Исхакыйга мондый уеннар, әлбәттә, тәэсир итми. Чөнки ул аларда эчке матурлык, артистлар уйнавында осталык сизми. Берсе артыннан берсе кабатланып торган уеннарның һәркайсы бертөсле булганга, һәр вакыйга бик озынга сузылганга, Г. Исхакый аларның балаганнан аермасын күрми. «Бәлки бу театрлар тагы тәрәккый итә төшәр» дигән теләк белән, ике-өч уен карагач, кайтып китә *(1919 ел, 26 май)* [Исхакый, 4 нче дәфтәр].

Япониядә өч айга якын торганнан соң, Г. Исхакый Чехиянең башкаласы Прага шәһәрендә дә өч айлап Парижга бару өчен рөхсәт көтәргә мәҗбүр була. Бу тукталыш аны максаты булган Солых конфе-ренциясеннән ераклаштырса да, чех мәдәнияте, сәнгате белән якын-нанрак танышырга мөмкинлекләр тудыра.

*1919 ел, 26 декабрь.* «Шәһәр карап йөргәндә иттифакый[1] тугры килгән бер таныш берлән чех театрына кердем. Уеннары – коруне вөста[2] ахырларыннан бер манзара. Рухани хәят берлән дөньяви тор-мышның чарпышуы[3]. Пьеса шәп түгел, уйнаулары аннан да начар. Артистларда уйнап, бернинди җанландыру фикере һич юк, фәкать караучыны көлдерергә генә маташалар, шуның өчен һич лөзүме бул-маган кыланулар берлән уенны бозалар, балаган характерын бирәләр. Мәсәлән, бер поп кирәкле-кирәксез чиркәү суын манулыклар вакы-тында сибә дә, бөтен залны шаркылдатып көлдерә. Берсе бик гырыл-дап йоклап, бөтен тыңлаучының рәхәтен китерә. Һичберсенең уенын-да табигыйлык юк» [Исхакый, 15 нче дәфтәр].

*1919 ел, 28 декабрь.* «Бүген чехларның милли театрларына[4] (narodni divaido[5]) опера карарга барамыз. Бу чехларның, халыкның ярдәме берлән акча җыеп, үзләренең мөһәндисләре[6], рәссамнары, осталарының ярдәме берлән эшләгән беренче театрлары. Бинасы бик пөхтә, матур, биш яруслы иттереп эшләтелгән. Александринкадан[7] кечкенә булса да, бик җыйнак иттереп, күп кеше сыя торган иттереп эшләтелгән. Пәрдәнең өстенә «Милләт үзенә» дигән сүз алтын берлән

[1] Иттифакый – очраклы.
[2] Коруне вөста – Урта гасырда.
[3] Чарпышуы – бәрелеше.
[4] Милли театр – Прагадагы опера һәм драма театры.
[5] narodni divaido – латин хәрефләре язылган. Дөресе: Narodni divadlo v Praze.
[6] Мөһәндисләре – инженерлары.
[7] Александринка – Александринский театр – Россиянең милли драматик театры (Санкт-Петербург шәһәре).

язылган. Көндезге театр, халык шыгрым тула. Операсы шәп түгел, исеме [...], оркестр бик зур, бик һәйбәт. Куелуы бик бай. Декорациясе, кием-салымы бик тулы. Ләкин артистлар котлылар түгел, араларында менә тавышы бар икән диярлек бер артист, бер артистка юк. Уеннары начар түгел, балетлары шактый һәйбәт, халык үзен бик тәрбияле тота. Һичбер төрле тавыш-кычкырыш юк, хәтта сөйләү дә ишетелми».

Әлеге тамашаны карагач, Г. Исхакый татарның үз театры юклыгын хәтеренә төшерә. «Казанда «Ирек йорты» дигән өй мәйданга куелса да, шуннан билфигыль[1] бер эш эшләтелмәде... Безнең дә Казанда шунда бер театр эшләргә лязим иде», – дип борчыла ул. Чөнки инде 1917 елда ук, татар зыялылары арасында татар театры өчен, «Ирек йорты» исемле махсус бина төзү мәсьәләсе күтәрелгән була. Г. Исхакый үзенең «Тартышу» исемле әле басылмаган пьесасыннан киләчәк бөтен гонорарын да шушы йорт фондына биргән була. Ләкин бу эш тормышка ашмый кала. Г. Исхакый Казанда моны эшләрлек көчләрнең булуына ышана [Исхаков, 8 т., б. 295]. «Исән-сау булсак, Русия[дә] мәдәни хәят берлән торырга имкян[2] туса, иншалла, эшләрмез әле», – дип, киләчәккә өметләр баглый [Исхакый, 15 нче дәфтәр].

*1919 ел, 29 декабрь.* «Кич берлән бөтен Европада шөһрәт тоткан чешский квартетның концертына барамыз. Дүрт мәшһүр музыкант егерме елдан бирле бергә концерт биреп йөриләр икән. Бүген рус музыкасыннан концерт бирәләр. Уйнаячак уеннарын[нан]: Чайковский[3], Бородин[4], Танеев[5]. Искиткеч оста уйныйлар». Г. Исхакый барган һәр җирдә татар милләте өчен борчылырлык сәбәпләр таба. Бу концерттан соң да ул Тамбов губернасы Әҗе татары С.И. Танеевның тудырган музыка, көйләре, дәртләре монда русныкы булып, чех-рус милләтләрен якынлаштырырга хезмәт итүе өчен борчыла [Исхакый, 15 нче дәфтәр].

*1920 ел, 25 гыйнвар.* «Иртүк мин бер таныш чех берлән шәһәрне карарга чыгып китәм... Технический музейга керәмез. ...Бер бүлмә әллә никадәр чех асаре кадимәсенең[6] модельләре берлән тулы. Монда чех театрының моделе дә бар, сарай моделе дә бар, чиркәүләр моделе дә бар. Бик матур иттереп эшләтелгән. Чехстанның суларының агу юллары да бар». Г. Исхакый биредә үзләренең мәмләкәтләренең хәзерге, элеккеге хәле белән танышып йөрүче балаларны күреп, гапгади музейдан да канәгать булып чыга [Исхакый, 16 нчы дәфтәр].

---

[1] Билфигыль – чынлыкта.

[2] Имкян – мөмкинлек.

[3] Чайковский – Петр Ильич Чайковский (1840–1893) – танылган рус композиторы, педагог, дирижер һәм музыка тәнкыйтьчесе.

[4] Бородин – Александр Порфирьевич Бородин (1833–1887) – рус композитоы, химик-органик, җәмәгать эшлеклесе, медик. 1850 еллар ахыры – 1860 еллар башында Санкт-Петербург шәһәрендә рус композиторларының иҗади берлеге буларак оешкан «Могучая кучка» вәкиле.

[5] Танеев – Сергей Иванович Танеев (1856–1915) – рус композиторы, пианист, педагог, музыка теоретигы. П.И. Чайковскийның шәкерте.

[6] Асаре кадимәсенең – археологик истәлекләренең.

*1920 ел, 25 гыйнвар.* «Кич берлән бүген мин Праганың Мещанский урамы тарафында бирелә торган зыяфәткә чакырылган... Залда меңнән артык кеше бар. Зыяфәттә элгәре – концерт, аннан соң – чәй зыяфәте... Концерт башлана. Гади начар концерт». Г. Исхакый – бик җитди тәнкыйтьче. Ул концерт номерларын гына түгел, хәтта тирә-ягындагы тамашачы халыкны да тәнкыйть күзлегеннән күзәтә: «...һәммәсе пөхтә генә киенгән, ләкин хатыннардан һичбер матур иттереп киенгән бер ханым юк. Петроград, Мәскәү, хәтта Казандагы кадәр туалет[1] юк. Дүрт-биш йөз хатын эчендә күзгә ташланырлык матур бер хатын да юк. Бар да – таза гына, нык кына хатыннар. Бар да ямьсез түгел, бар да матур түгел», – дип, ул чех хатыннарын аларның чиле-пешле милли ризыклары белән чагыштыра [Исхакый, 16 нчы дәфтәр].

*1920 ел, 1 февраль.* «Бәйрәм булганга, иртүк торып, шәһәр карарга китәмез... Бер урамда «Жидовский музеюм»[2] дип язып куелган. Ләкин музей ни өчендер бүген ябык. Шуңарга эченә керә алмыймыз.

Урамнарны карап йөреп, немецлардан калган музейларның бер бүлегенә керәмез. Бу – санагать[3] музэсе. Бу – мондагы Рудольфинумның[4] бер кыйсеме генә. Зур бүлеге ябык була. Санагать музейсы һәр йирдә инде бер төрлерәк. Махсус булмаган кешегә әллә ни кызыгы юк. Дикъкатьне җәлеп итә торган нәрсә булса, ул да музэханәдәге костел (чиркәү) бүлмәсе. Бер бүлмәне, тәмамән, чиркәү иттереп җыйнаганнар. Алтарьлар, тәреләре, камкалары, лампалары, кыңгыраулары, төрле төстәге чүпрәкләре, попларның гыйбадәт киемнәре, савытлары – һәммәсе үз урынында. Эченә кергәч, тәмамән чиркәүгә кергән кебек буласың. Ләкин үзе чиркәү түгел. Үзе – чехның сәнгать әсәре, үзе – чехның дин хәятының асаре гатикасы[5]». Чиркәүдә изге саналган тәреләрнең сәнгать музеена куелуы Г. Исхакыйда «дин дә – адәм баласы кулы белән ясалган бер нәрсә» кебек хис калдыра.

«Икенче дикъкать ителә торган нәрсә – чехларның өй тормышларының корылышын күрсәткән бүлмә... Бу бүлмәдә күзгә төрекчә язулы бер тарелка чагыла. Укып карыйм. Матур иттереп тәгъликъ[6] берлән язылган зиннәтле тарелка. Язулары бу рәвешчә: «Ләһ кырале кәмале мәхәббәтлә вә изһары сәдакатьлә иһда идептер. Але Госман падишаһына»[7]. Урта бер йирдә «Мәкамы Варшава» диел-

[1] Туалет – бизәнү мәгънәсендә.

[2] «Жидовский музеюм» – «Яһүдиләр музее».

[3] Санагать – сәнгать.

[4] Рудольфинум – Прага шәһәренең үзәгендә урнашкан концерт һәм күргәзмә залы (галерея), хәзерге вакытта Ян Палач исемен йөртә торган мәйданда. 1885 елның 7 февралендә ачылган. Австро-Венгрия империясе принцы хөрмәтенә Рудольф исеме белән аталган.

[5] Асаре гатикасы – археологик истәлек.

[6] Тәгъликъ – гарәп хәрефләре белән языла торган язу төрләреннән берсенең исеме.

[7] Польша короле камил мәхәббәт белән тугрылыгын күрсәтеп бүләк иткән Госманлы патшасына.

гән[1]. Бу тарелка Польша корольләренең берсе тарафыннан төрек солтаннарының берсенә бирелгән һәдия[2], күрәсең. Төркиянең сарайларыннан урланган да, кулдан кулга йөри-йөри, Праганың музәсенә килеп кергән».

Г. Исхакый музейда хезмәтчеләр булмауга гаҗәпләнә. Чөнки әлеге музейда «кайбер кадерлерәк нәрсәләр шкаф эченә куелган булса да, бик күбе ачык шүрлек, киштәдә булганга, урларга теләгән кешегә урлау бик җиңел булырга кирәк. Безнең Русиядә бу хәлдә булса, ике-өч атнада яртысы урланып беткән булыр иде», – ди [Исхакый, 16 нчы дәфтәр].

*1920 ел, 8 февраль.* «Винограды дигән йирдәге театрга бардык. Театры кечкенә генә, ләхчә генә. «Яшьләргә гыйбрәт» дигән бер пьеса куйдылар. Чехларның истикъляялы[3] өчен тартышу дәвереннән алып язылган. Ләкин пьеса сәнгать җәһәтеннән караганда бик ибтидаи. Темасы нинди бай булса да, шуны матур мантыйкый иттереп чыгара алмаган. Пьесада һичбер мәләкә[4] юк. Керәләр дә, сөйлиләр дә чыгалар, керәләр дә, сөйлиләр дә, чыгалар да, һичбер действия бармый. Ахырдан гына пьесаның җилеге булачак действие килеп чыга. Ул да әхвальдән табигый булып тумый. Күктән төшә. Милли рухны кыздырыр өчен, озын-озын монологлар сөйлиләр». Чехларга тәэсир итсә дә, мондый гади тамаша, әлбәттә, Г. Исхакый кебек театрдан сәнгать көткән кешеләрдә канәгатьлек хисе тудырмый. Әдип моны гүзәллек хисен мыскыл итү дип кенә кабул итә [Исхакый, 16 нчы дәфтәр]. Аның өчен сәнгать – ул матурлык чыганагы. Аның фикеренчә, «матур манзаралар, ямьле төсләр, назик сыннар табигатьтәге дорфалыкны йомшартыр өчен, тупаслыкны күрә-күрә туеп беткән күзләрне хәл алдырыр өчен яратылган кебек, матур тавыш, моңлы көйләр, нечкә сайраулар да дөбер-шатырлы дөньядан үтеп китеп, колакны рәхәтләндерер, тындырыр өчен яратылгандыр» [Исхаков, 6 т., б. 287].

*1920 ел, 1 март.* «Бүген мондагы Немец театрына[5] бардым. Монда театрның иң искесе. Бер-ике йөз ел элек салынганы. Бик зур. Биш ярусны иттереп эшләнгән. Бинасы матур җиһазлы булса да, иске стильдә. Бик яхшы уйнадылар. Бик һәйбәт тавышлар бар. Һәм дә бик оста уйныйлар». Г. Исхакыйның шушы соңгы бер ел эчендә күргән театрлары арасында иң зур күңел азыгы биргәне Прагадагы нәкъ шушы Немец театры була. Әдип уйнаучыларның телен аңламаса да, музыкасыннан, күзләрне рәхәтләндерерлек гүзәллектән алган

---

[1] Урта бер җирдә «Варашавада» диелгән.

[2] Һәдия – бүләк.

[3] Истикъляялы – бәйсезлеге.

[4] Мәләкә – осталык.

[5] Немец театры – бүгенге көндә Прага дәүләт операсы дип аталган Чехия опера театры 1888 елда Яңа немец театры буларак ачылган. 1949–1989 елларда ул Сметана театры дип аталган. 1883 елда ук Прага немец җәмгыятендә үзләренең немец телендәге опера театрын булдыру теләге туган була. Ул вакытта Чехия җирләре Австрия-Венгрия империясенең өлеше булганлыктан Прагада немецлар күп булган.

тәэсирдән: «Күптән мондый уен, мондый оста театр күрмәгән идем» [Исхакый, 17 нче дәфтәр] дигән сүзләр белән үзенең канәгатьлелеген белдерә.

Г. Исхакый дәфтәрләре – көндәлекләр дә, шул ук вакытта сәяхәт язмалары да. Аларда тасвирланган вакыйгалар әлеге күпкырлы шәхеснең мөһаҗирлектәге тормышын һәм эшчәнлеген дөрес бәяләргә ярдәм итәрләр дигән өметтә калабыз.

**Әдәбият**

*Исхаков М.Г.* Әсәрләр. 15 томда. 6 т.: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре / [томны төз.: З. Рәмиев, Ф. Ибраһимова]. 2005. 447 б.

*Исхаков М.Г.* Әсәрләр. 15 томда. 8 т.: Гаяз Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында замандашлары / [томны төз., текст һәм аңлат. әзер., кереш сүз авт. Ф. Ибраһимова]. 2001. 447 б.

*Исхаков М.Г.* Әсәрләр. 15 томда. 14 т.: хатлар һәм автобиографик язмалар / [томны төз., текст һәм аңлат. әзер., кереш сүз авт. Ф.Фәйзуллина]. 2013. 479 б.

Исхакый Г. Көндәлек дәфтәрләре // ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге, 135 нче фонд.

***Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре*

***Ханнанова Гөлчирә Мәхмүт кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 392.122

***З.М. Брусько***

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ТРАДИЦИОН КҮЗАЛЛАУЛАРЫНДА АВЫРЛЫ ХАТЫН ОБРАЗЫ

В статье рассматривается тема беременности и образа беременной женщины в свете ее отражения в языковой, фольклорной, а также мифологической картине мира татар. Объектом исследования стали термины, лексика, синтаксические единицы, отражающие беременность, многочисленные тексты народных представлений, запретов, предписаний о беременной женщине. Материалом послужили в своем большинстве собственные полевые исследования автора, собранные во время многочисленных фольклорно-этнографических экспедиций. Анализ языковых данных, а также семантики действий, связанных с беременной женщиной, подчеркивает ее особый статус и свидетельствует о глубинных архаичных корнях выполняемых действий.

**Ключевые слова:** татары, беременная женщина, поверья, запреты, предписания, ребенок.

The article discusses the topic of pregnancy and the image of a pregnant woman in its reflection in the linguistic, folklore, and mythological picture of the world of the Tatars. The object of the study are terms, vocabulary, syntactic units reflecting pregnancy, numerous texts of folk beliefs, prohibitions, prescriptions about a pregnant woman. The material was mostly the author’s own field research collected during numerous folklore and ethnographic expeditions. The analysis of language data, as well as the semantics of actions related to a pregnant woman, emphasize her special status and testify to the deep archaic roots of the actions performed.

**Keywords:** Tatars, pregnant woman, beliefs, prohibitions, prescriptions, baby.

Дөньядагы барлык халыклар да элек-электән авырлы хатынга ихтирам күрсәтергә, аны төрле бәла-казалардан сакларга, кыерсытуүпкәләтүдән, нахак сүз әйтүдән ерак торырга тырышканнар. Мондый мөнәсәбәт авырлы хатынны уңдырышлылык, үрчем символы буларак кабул итү белән, аның нәселне, киңрәк алганда, кешелек дөньясын дәвам иттерүдә төп рольне башкаруы белән аңлатыла. Еш кына авырлы хатынның үрчем арттыру сәләтеннән файдалануны төрле халыклар традицияләрендә күзәтергә мөмкин. Әйтик, славян халыкларында, баласызлыктан котылу өчен, яңа салган йортның хуҗалары иң элек анда авырлы хатынны керткәннәр; тавык астындагы бөтен йомырка да чебешле булсын өчен, тавыкны йомырка өстенә авырлы хатыннан утырттырганнар [Толстая, 1995, с. 160]. Башкортларда, уңыш мул булсын өчен, яз көне чәчү вакытында авырлы хатыннан межага пешкән йөмырка чәчтергәнннәр [Хисамитдинова, 2011, с. 89]. Татарларда авырлы хатынның түле бала табарга теләгән башка хатыннарга да күчә ала дигән ышану бар – моның өчен авырлы хатынның корсагын тоткан хәлдә Аллаһка бала сорап мөрәҗәгать итәләр.

Халык күзаллаулары буенча, авырлы хатын гомере кыл өстендәге кеше буларак кабул ителә, аның бу халәте, соклану белән беррәттән, борчылу хисе дә уята. Себер татарларының авырлы хатынны тасвирлаган *«бер аягың кырта, бер аягың гүрдә»* [Бер аягың...] гыйбарәсе моның ачык мисалы булып тора.

**Авырлы хатынны белдерүче атамалар.** Татар телендә авырлы булу халәтен белдереп килүче атамалар шактый, аларның килеп чыгышы, лексик мәгънәләре гаять кызыклы һәм үзенчәлекле. Бер төркем атамаларның ясалышы ‘авыр’ (бор. төрки *ayir*), ‘йөк’ (бор. төрки *iclig*) тамырларына барып тоташа һәм турыдан-туры карындагы баланың билгеле бер авырлыкта булуын ассызыклап килә. Бу төркемгә ‘*авырлы*’, ‘*авырлы хатын*’, ‘*авыры бар*’ атамалары да керә. Шул ук авырлык, йөк мәгънәсен белдерүче фарсы тамырлы ‘*көмәнле*’ атамасы да әлеге төркемгә карый. ‘*Корсаклы*’ атамасы игътибарны авырлы хатынның тән төзелешенә, анда барлыкка килгән үзгәрешләргә юнәлтә. Икенче бер төркем атамаларның семантикасы юл мотивы белән бәйле – ‘*авырга узу*’, ‘*балага узу*’, ‘*буйга узу*’, ‘*корсакка узу*’, ‘*корсакка калу*’ атамалары билгеле бер юл үтүне, ниндидер чикне узуны аңлатып киләләр. Шулар белән беррәттән сирәк, кайбер сөйләшләрдә генә очрый торган атамалар да бар. Мәсәлән, себер татарлары сөйләшендә – ‘*авыраяк*’, ‘*авыраяклы*’, ‘*буйында бар*’, әстерхан татарлары сөйләшендә – ‘*буй авыр*’, нократ сөйләшендә – ‘*эстендә бар*’, ‘*янында бар*’, глазов сөйләшендә – ‘*әйләнәсе тулганда*’ атамалары да кулланыла. Бу җәһәттән игътибарны тау ягы сөйләшенә караган татарлардан язып алынган ‘*бай хатын*’ атамасы җәлеп итә. Атамада авырлы хатынны олылау, аның аерым статусын күрсәтү чагылыш таба. Карындагы бала зур байлык буларак кабул ителә.

**Балага узу.** Балага узу, киләчәктә әти-әни булу мәсьәләсенә ир белән хатын һәр чорда да җаваплы карарга тырышкан. Бу исә кабул ителгән таләпләрне үтәүдән, тыюларны бозмаудан гыйбарәт булган. Экспедиция материаллары күрсәткәнчә, якынлык кылу үзе үк билгеле бер шартларны үтәүгә нигезләнергә тиеш – изге гамәл буларак аны Аллаһ Тәгаләгә мөрәҗәгать ителгән догадан башлау сорала. Баланың исәнлек белән тууы һәм киләчәктәге сәламәтлеге турыдан-туры әлеге гамәлне башкару вакытына һәм урынына бәйле. Мәсәлән, бала физик кимчелекләр белән тумасын өчен, дини бәйрәм көннәрендә якынлык кылырга ярамый. Бу очракта мөселманнар Корбан, Ураза гаете көннәрен атыйлар, ә христиан динендәге керәшеннәр Олы көн (Пасха) турында сүз алып баралар. Шулай ук, ышанулар буенча, якынлык кылу ачык һавада, мәсәлән, ялан кырда, болында башкарылырга тиеш түгел: *«Һавада җакыллык кылырга кушмый. Түбә астында кирәк. Шәригать эше диләр бит аны, җакыллык кылуны»* [Якынлык кылу]. Халыкта якынлык кылуга кагылышлы тыюлар белән беррәттән кайбер башкарылырга тиешле гамәлләр дә бар. Бу гамәлләр башлыча туачак баланың җенесенә тиешле йогынты ясау өчен башкарыла һәм җенеснең формалашуында турыдан-туры кайбер предметларны

куллануга кайтып кала. Мәсәлән, ир бала тууын теләүчеләр төрле эш коралларын, ир-ат бүреген эшкә җиксә, кыз бала көтүчеләр савыт-саба, бизәнү әйберләре, хатын-кыз киемнәренең көченә ышана. Татарстанның Теләче районында язып алынган мәгълүматка караганда, хатын-кызга якынлык кылуга уң ягына борылып яту – ир бала, ә сул ягына борылып яту кыз бала табарга ярдәм итә. Әлеге ышануның нигезендә дөнья картинасында ир-атны уң, ә хатын-кызны сул як белән тәңгәлләштерү идеясе ята [Кон, с. 90]. Дини риваятьләрдә урын алган Хәүва Ананың Адәм галәйһиссәламның сул кабыргасыннан яратылу мотивы да нәкъ менә шушы күзаллауларга корылган. Көндәлек тормышта әлеге күренешне ир-атларның киемнәрен уңнан сулга, хатын-кызларныкын сулдан уңга төймәләү тәртибендә күзәтергә була.

Югарыда аталып киткән мисаллар һичшиксез үтәлергә тиешле гамәлләр буларак түгел, ә ассоциатив ышануларга, дини күзаллауларга нигезләнгән киңәш характерындагы күренешләр буларак чыгыш ясыйлар.

**Авырлы хатынга башкаларның мөнәсәбәте.** Сүзебезне дәвам итеп, авырлы хатын янәшәсендә булганнарның аңа булган мөнәсәбәте, үз-үзләрен тотышы тәртибенә күз салыйк. Хатын-кызның авырлы булуы билгеле булганнан алып, аның тирәдәгеләрнең һәр уе, һәр гамәле авырлы хатынны саклауга һәм яклауга юнәлтелә. Борынгырак чорларда бу иң элек аны төрле явыз затлардан, әйтик, Албастыдан, җеннәрдән саклау белән бәйле булган. Татарларның традицион күзаллаулары буенча авырлы хатынны йоклаган вакытта Албасты буарга, карынындагы баласын җен урларга мөмкин дигән ышану яшәп килә. Шуның өчен якыннары, аны саклау ниятеннән, беркайда да ялгызын гына калдырмаска тырышалар. Иң куркыныч урыннарның берсе – мунча, чөнки ул, ышанулар буенча, кара көчләрнең (җен, мунча пәрие, мунча иясе, мунча убыры) яраткан урыны, алар монда берәмләп тә, күпләп тә җыелырга мөмкин. Карынында бала йөрткән хатынга мунчада ялгыз калу аяныч тәмамланырга мөмкин дип санала. Шулай ук авырлы хатын башкалар белән чагыштырганда күз тиюгә күбрәк дучар була дип исәпләнә, бу исә аңа карата игътибарны тагы да көчәйтүне сорый. Явыз затлардан саклану өчен авырлы хатын төрле ысулларга мөрәҗәгать итә. Әйтик, ялгызы йокларга туры килгәндә, ул янәшәсенә пычак куеп ята [Баязитова, б. 179]; *бисмиллаһ* сүзен әйтә-әйтә, корсагын кат-кат сыпыра [Татар халкының..., б. 132]. Болар белән беррәттән, авырлы хатынның якыннарына аны авыры төшүдән саклау вазифасы да йөкләнгән. Мондый куркыныч янаган очракта еш кына төрле магик чараларга мөрәҗәгать иткәннәр. Мәсәлән, әстерхан татарларында авырлы хатынның итәген җеп белән тегеп, йозак белән бикләп куйганнар [Баязитова, б. 179].

Якыннары авырлы хатынның теләкләрен үтәү турында да кайгыртырга тиеш. Бу бигрәк тә аның ризыкка, гомумән ашау тәртибенә карата үзгәргән мөнәсәбәтен исәпкә алудан гыйбарәт. Билгеле булганча, авырлы вакытта хатын-кызда ризык сайлау, моңарчы яратып

ашаган ашамлыкларыннан баш тарту я, киресенчә, яратмаганнарына өстенлек бирү күзәтелә. Авырлы хатынның бу халәте халык мәкалендә дә урын алган: «Көмәнле хатын талымсак булыр». Җирле сөйләшләрдә әлеге күренешнең төрле атамалары яшәп килә: ‘*йәрек булу*’, ‘*йәрек аш*’, ‘*ирег аш*’, ‘*сары булу*’ (тара сөйләше), ‘*аш сайлау*’, ‘*аш талымлау*’ (сергач, казан арты сөйләшләре), ‘*терләнү*’, ‘*терләнеп йөрү*’ (тау ягы сөйләше). Еш кына авырлы хатынның авыз итәсе килгән ризыклары рәтендә табуы кыен булган, ашарга яраксыз, хәтта хәрәм ризыклар булырга мөмкин. Мәсәлән, кыш уртасында җәй көне генә үсә торган җиләк-җимешләр, акбур, күмер, дуңгыз ите. Шулай булуга да карамастан, якыннары аңа бу ризыкларны табу җаен карарга тиешләр. Әлеге теләкләрнең үтәлми калуы карындагы балага килергә мөмкин зыян белән аңлатыла. Ышанулар буенча, теләгән ризыгын авыз итеп карамаган авырлы хатынның баласы нинди дә булса кимчелек белән туарга мөмкин. Шулай ук баланың тәненә чыккан берәр төрле миң дә авырлы хатынның теләген үтәмәүнең нәтиҗәсе буларак кабул ителә. Гадәттә, бу миңнең формасы я төсе авырлы хатын ашамый калган ризыкныкы белән тәңгәл килә. Кайбер җирлекләрдә бала тапкан хатынның күкрәкләре шешү сәбәбе дә шуның белән аңлатыла. Авырлы хатын туклануы турында үзе дә уйларга тиеш – язып алынган мәгълүматлар аның үзе өчен генә түгел, карындагы баласы өчен дә (бигрәк тә балага җан иңгәннән соң) ашарга тиешлеге хакында сөйли: *«Балага да тиешле өлеш дип, ике өлеш бирәдерие безенең кайната»* [Ике өлеш]. Авырлы хатынның гадәти булмаган әйберләрне ашавы туачак баласының тышкы кыяфәтенә йогынты ясый ала дип санала. Моны югарыда телгә алып узган акбур белән күмер мисалында күрсәтү отышлы булыр. Ульяновск өлкәсендә яшәүче татарларның күзәтүләре буенча, көмәнлек чорында озак вакыт акбур я күмер ашаган хатынның баласы нәкъ менә шушы матдәләргә буялып туа [Акбур]. Биредә без бер симпатик магия төренең чагылышын күзәтә алабыз.

**Саклагычлар.** Авырлы хатынның үзенчәлекле халәте аны үзе белән төрле саклагыч предметлар (амулетлар) йөртергә этәрә. Кесәсендә аның еш кына миләш, артыш ботагы, сарымсак, я берәр тимер әйбер була. Әлеге предметлар күпчелек халыклар, шул исәптән татар халкының күзаллавы буенча кара көчләрдән, күз тиюдән саклый алырлык магик көчкә ия. Кайбер очракларда бу предметларны куллану мәҗбүри характер ала. Мәсәлән, мәет озату йоласында катнашырга туры килгәндә, шулай ук мәетнең йөзенә карарга теләк белдергән очракта, авырлы хатын күлмәгенең аскы өлешенә я күкрәк турысына энә яки булавка кадап куярга тиеш. Шул рәвешле ул туачак баласын үлем төсеннән – ак чырайлы (чырайсыз, сары йөзле, мәет төсе кергән) булудан саклап кала ала. Шулай ук бу кагыйдәнең үтәлүе туачак баланың күз нурын мәет алып китүдән дә саклый. Кайбер локаль традицияләрдә (Татарстанның Яшел Үзән районы Бишнә авылы), авырлы хатынны кара көчләрдән саклау ниятеннән, аның эчке

киеменә бер кисәк сарык йоны тегеп куела [Сарык йоны]. Сарык йонына мондый әһәмият бирү, аннан шушы рәвешле файдалану татарларның борынгы анималистик күзаллауларына нигезләнгән һәм кайбер башка хайваннар белән беррәттән сарыкны изгеләштерү, сакральләштерү күренешен чагылдыра. Моңа өстәп, Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районында язып алган мәгълүматны китерү дә урынлы булыр. Биредә яшәүче татарлар арасында, балага җен-зәхмәт тимәсен өчен, бишек бавын махсус ысул белән сарык йоныннан үреп ясарга кирәк, дигән ышану яшәп килә: *«Бишек бавын сарык йоныннан ничектер үзгәчә үрәләр, аны шайтан үңгәрми икән»* [Бишек бавы].

Авырлы хатынның тормышы бөтенләе белән диярлек төрле **тыюлар** һәм **үтәлергә тиешле гамәлләрдән** гыйбарәт. Көмәнлек чорын исән-имин үтеп, сәламәт бала табуы күпчелек вакыт аның үзүзен тотышына бәйле була.

**Тыюлар.** Татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә авырлы хатынга аркылы яткан таяк, бүрәнә, көянтә, кисәү агачы кебек предметларны атлап чыгарга һәм шулай ук үзе аркылы беркемне дә атлатырга ярамый. Әлеге тыюның асылында аркылы яткан предметларның карындагы баланы туган вакытта аркылы китерә алуына ышану ята. Фәндә бу төр ышанулар симпатик магиягә корылган ышанулар дип йөртелә һәм аерым предметларның, гамәлләрнең сыйфаты, үзенчәлеге башка предметларга, гамәлләргә күчә алуны белдерә [Фрезер, с. 21]. Татарстан Республикасының Яшел Үзән районында язып алынган мәгълүмат буенча, шулай ук ике багана арасыннан узу да шушындый нәтиҗәгә китерә [Ике багана]. Бер төркем тыюлар авырлы хатынның хуҗалык өлкәсендәге эшләренә бәйле. Мәсәлән, аңа моңарчы һәрдаим башкарып килгән йон эрләү, йон кату, бәйләү кебек шөгыльләрдән дә туктап торырга туры килә. Ышанулар буенча, бу шөгыльләр аркасында бала туган вакытта кендегенә чорналып туа. Авырлы хатынның чәч кистерүе үзенең һәм баласының гомерен кыскартуы буларак кабул ителә. Телгә алынган тыюлар татарлар яшәгән барлык төбәкләргә дә хас булса, аерым урынчалыкларда гына билгеле булганнары да бар. Мәсәлән, Саратов өлкәсе татарларында авырлы хатынга *«еланыңның буе кыңгыр булмасын өчен, путалокны (түшәмне) юурга ярамый»* [Путалок]; Түбән өлкәсе татарларында ул кунакка кергән кешене озата чыгарга, армиягә китүченең озату кичәсендә катнашырга тиеш түгел [Озатып чыгу]; казан арты керәшеннәрендә авырлы хатын, баласы киләчәктә гырлаучан булмасын өчен, мал чалган җиргә якын килмәскә тиеш [Мал чалган җир]. Шулай ук авырлы хатынның кайбер йорт хайваннарына карата башкарылырга мөмкин гамәлләре дә локаль характердагы тыюлар рәтенә керә. Әйтик, авырлы хатынның эт-мәчегә, мал-туарга тибүе баласының киләчәктә «ныжы» авыруыннан [Ныжы], «мошкач» авыруыннан [Мошкач], кече йомышын авырдан башкарудан [Кече йомыш], аркасына чәнечкеләр чыгудан интегүенә китерә [Шитина]. Аның әлеге гамәле шулай ук баланы карында чакта ук «убыр урлауга» я булмаса

аның берәр физик кимчелек белән тууына [Убыр ала] сәбәп булырга мөмкин дип уйланыла.

Тыюлар авырлы хатынның ашау-туклану тәртибендә дә чагылыш таба. Югарыда без аның ашау үзенчәлекләреннән булган аш сайлау, аш талымлау күренеше турында сүз алып барган идек. Инде килеп, ашарга ярамаган ризыкларны да барлап чыгыйк. Бу төр тыюлар авырлы хатынны көтелмәгән күңелсез хәлләрдән саклау өчен кулланыла. Бер өлеше тыюлар хатын-кызның бала чагында ук башлана һәм үз нигезендә куш булып үскән җиләк-җимеш, чикләвек, көнбагыш ише ашамлыкларны ашаудан игезәк балалар туа дигән ышануга барып тоташа: *«Куш әйберне ашарга кушмыйлар, аннан игезәк малайлар табасың»* [Куш әйбер]. Бу ышану белән таныш кызлар парлы ризыкның берсен кем белән булса да бүлешергә тырышалар. Биредә без халык күзаллавында парлы предметларның (бу очракта ризыкларның) икеләтә арту көченә ия булу күренешен күзәтәбез [Толстая, 1999, с. 21]. Авырлы хатын өчен тыелган ризыкларның булуы – татар халкының барлык этник төркемнәрендә дә киң таралыш алган күренеш. Күп җирдә бу ризыкларның исемлеге бердәй, ләкин локаль төсмер алганнары да бар. Казан арты татарлары бу исемлеккә каз-үрдәкнең бүтәкәсен кертә, аны ашау баланың вакытыннан алда тууына, бәләкәй булуына китерә [Бүтәкә]. Шул ук казан арты һәм тау ягы төркеме татарларында хәрәм иттән әзерләнгән казылык, көнбагыш ашау нәтиҗәсендә баланың аркасына авырттыра торган чәнечкеләр (*кәчеркә*/*кәсеркә*, *җоклык*, *щитина*/*шитина*) чыгуы турында сөйлиләр (Татарстанның Биектау, Алексеевск, Апас районнары). Себер татарларында чуртан балыгы тыелган ризыклардан санала, чөнки *«сорагай балык (чуртан) – кырык төрле авыруыңны кусгай»* [Баязитова, б. 16]. Әстерхан татарлары авырлы хатынга дөя итен ашатмаска тырышалар, чөнки аны ашаган хатын авырын унике ай күтәргән дөя шикелле баласын вакытыннан артык күтәрәчәк: *«Кинчәкләр буй авыр булганда төйәнең итен ашаса, унике ай йөриләр икән. Төйә унике ай корсагында бала үстерә икән»* [шунда ук]. Бу нисбәттән казан татарларында киң таралыш алган ышануга игътибар итү сорала. Биредә авырлы хатынның вакытыннан артык йөрүен айгыр белән биянең чаптырганын (якынлык кылганын) күрү белән бәйләп карыйлар. Бала табуны тизләтү өчен авырлы хатынга арт итәгенә солы салып, шуны айгырга ашатырга киңәш ителә. Экспедиция материаллары әлеге ышануның бүгенге көндә дә актуаль булуын күрсәтә [Атка солы ашату]. Кайчагында артык йөрүнең сәбәбен авырлы хатынның төшендә атка атланып йөрүеннән күрәләр [Атка атланып йөрү].

**Башкарылырга тиешле гамәлләр.** Тыюлардан аермалы буларак, авырлы хатын тарафыннан башкарылырга тиешле гамәлләрнең саны алай ук күп түгел. Ләкин эчтәлеге ягыннан алар да карындагы баланың киләчәген кайгыртуга, аның иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән. Туачак баласы төскә-биткә чибәр булсын өчен, авырлы хатын матур кешеләргә карарга, табигатьнең гүзәл күренешләрен

күзәтергә һәм, киресенчә, ямьсез, авыру, гарип-горабаларга, эчке-челәргә караудан тыелырга тиеш. Бу кагыйдәгә ул баласына җан иңгән вакытта бигрәк тә буйсынырга тиеш. Халык ышанулары буенча баланың ана карынында хәрәкәт итә башлавы аңа җан иңү турында хәбәр итә. Вакыт күрсәткече буенча, бу вакыйга баланың яралуыннан соң дүрт ай да ун көн үткәч була. Бу өлкәгә караган медицина күрсәткечләре дә баланың тәгаен сизелерлек хәрәкәтләр ясый башлавы шушы вакытка туры килүен раслый [Митрошенков, с. 9]. Баланың камил булып тууын тәэмин итүче гамәлләрдән казан арты татарларыннан язып алынган мәгълүмат игътибарга лаек. Информант сүзләре буенча, авырлы хатын һәркөн корсагын сыпыра-сыпыра: *«И, Аллам, шушы баламны саулык-сәламәтлек белән бирсәң иде, кыл-әгъзалары тигез, сау-сәламәт булып, шушы якты дөньяга туса иде»,* – дигән сүзләр белән Аллаһка мөрәҗәгать итсә, баласы дөньяга сау-сәламәт булып туачак [Кыл-әгъза]. Әлеге гамәлне башкару, шулай итеп, Аллаһның бәхәссез көченә, аның үзенә сыенучыларга һичшиксез ярдәм итәчәгенә ышануга нигезләнгән.

**Туачак баланың җенесе белән бәйле эш-гамәлләр**. Өйрәнелүче тема кысаларында аерым урынны авырлы хатынның туачак баласының җенесенә бәйле ышанулар һәм моны ачыклау ниятеннән башкарыла торган юраулар, төш юраулар алып тора. Еш кына карындагы баланың җенесен авырлы хатынның тышкы кыяфәте һәм кайсы төр ризыкларга өстенлек бирүе буенча фаразлыйлар. Мәсәлән, халык күзәтүләре буенча, ир бала табасы хатынның корсагы очлы булып тора, ул йөзгә-биткә әллә ни үзгәрми, ашаганын күбрәк итле ризыклар тәшкил итә. Карынында кыз бала йөртүче хатынның корсагы түгәрәкләнеп, җәенке булып тора, йөзе тутлана, ул сөт ризыкларын, җиләк-җимешләрне яратып ашый башлый. Халыкта баланың җенесен төшләр буенча юрау да киң таралган. Төш юрау тәртибе логик күзаллауга буйсынган. Гадәттә, төшкә кергән теге яисә бу предметның, нинди дә булса күренешнең ир-атка яки, киресенчә, хатын-кызга бәйләнеше аермачык чагыла. Мәсәлән, эш кораллары, сәгать, имән чикләвеге, аяк киеме ир балага юрала, ә бизәнү әйберләре, савыт-саба, энә-җеп, урман чикләвеге кебек әйберләр кыз бала туачагын белдерә. Төшләр арасында баланың үле туачагын хәбәр итүчеләре дә бар. Әйтик, кулдагы берәр әйбернең суга төшеп китүе шул турыда хәбәр итә: *«Өч бала китерде, өч баласы да үле булдылар. Алдан төшенә керә ие. Менә тагын булмый балам, балтам суга төшеп агып китте, дияр ие»* [Суга төшеп китү]. Юрауларга килгәндә, биредә казан татарларыннан язып алынган бер мисалга тукталып китәрбез. Әлеге юрау түбәндәгедән гыйбарәт: авырлы хатыннан кулын алга таба сузуын сорыйлар һәм аның кулының уч төбен өскә каратып сузуын – ир бала, аска каратып сузуын кыз бала табачагына юрыйлар.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: татарларда авырлы хатынны олылау, аңа хөрмәт күрсәтү, һәрдаим һәм һәртөрле саклау чаралары башкару – формалашкан төс алган күренешләр. Авырлы хатынны

белдергән атамалар, традицион күзаллауларны чагылдырган ышанулар, тыюлар, эш-гамәлләр моның дәлиле буларак чыгыш ясый. Эш барышында анализланган материалның борынгы чорлардан безнең көннәргә хәтле килеп җиткәнлеге һәм күпчелек өлешенең бүген дә тотрыклы булуы ачыкланды. Алар татарларның борынгы мифологик күзаллауларын чагылдыралар.

**Әдәбият**


Акбур / Авторның шәхси архивы. 06.10.2007 елны Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районы Яңа Терешка авылында Абдюшева Факия Ризван кызыннан (1922 елгы) З.М. Арикеева (Брусько) тарафыннан язып алынды.

Атка атланып йөрү / Авторның шәхси архивы. 04.12.2007 елны ТР Яшел Үзән районы Бишнә авылында Галиуллина Асия Галәветдин кызыннан (1942 елгы) З.М. Арикеева (Брусько) тарафыннан язып алынды.

Атка солы ашату / Авторның шәхси архивы. 22.02.2022 елны ТР Саба районы Иләбәр авылында Харисова Резеда Гамил кызыннан (1969 елгы) З.М. Брусько тарафыннан язып алынды.

*Баязитова Ф.С.* Халык традицияләре лексикасы: бишек туе (йола һәм фольклор текстлары яссылыгында). Казан: ТӘһСИ, 2012. 331 б.

Бер аягың / Авторның шәхси архивы. 02.07.2007 елны Төмән өлкәсе Төмән районы Талмы авылында Сәгыйдуллина Нурганә Әхмәтулла кызыннан (1927 елгы) З.М. Арикеева (Брусько) тарафыннан язып алынды.

Бүтәкә / Авторның шәхси архивы. 25.05.2006 елны ТР Биектау районы Бишнә авылында Гарифуллина Рузалия Һидият кызыннан (1935 елгы) З.М. Арикеева (Брусько) тарафыннан язып алынды.

Ике багана / Авторның шәхси архивы. 04.12.2007 елны ТР Яшел Үзән районы Бишнә авылында Галиуллина Асия Галәветдин кызыннан (1942 елгы) З.М. Арикеева (Брусько) тарафыннан язып алынды.

Ике өлеш / Авторның шәхси архивы. 17.05.2007 елны ТР Саба районы Сүлә авылында Зарипова Миңнебикә Тимергали кызыннан (1915 елгы) З.М. Арикеева (Брусько) тарафыннан язып алынды.

Кече йомыш / Авторның шәхси архивы. 19.06.2008 елны Төмән өлкәсе Ялутор районы Яңа Атъял авылында Исхакова Фәриха Хәлиулла кызыннан (1927 елгы) З.М. Арикеева (Брусько) тарафыннан язып алынды.

*Кон И.С.* Введение в сексологию. М.: Медицина, 1988. 320 с.

Куш әйбер / Авторның шәхси архивы. 20.06.2013 елны ТР Кама Тамагы районы Ишем авылында Дәминова Рәшидә Гатаулла кызыннан (1930 елгы) З.М. Брусько тарафыннан язып алынды.

Мал чалган җир / Авторның шәхси архивы. 23.05.2014 елны ТР Мамадыш районы Ташлыяр авылында Михеева Матрена Макар кызыннан (1931 елгы) З.М. Брусько тарафыннан язып алынды.

Мошкач / Авторның шәхси архивы. 19.06.2008 елны Төмән өлкәсе Ялутор районы Яңа Атъял авылында Исхакова Фәриха Хәлиулла кызыннан (1927 елгы) З.М. Арикеева (Брусько) тарафыннан язып алынды

Ныжы / Авторның шәхси архивы. 07.10.2007 елны Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районы Иске Зеленай авылында Мусина Равия Исхак кызыннан (1936 елгы) З.М. Арикеева (Брусько) тарафыннан язып алынды.

Озатып чыгу / Авторның шәхси архивы. 30.06.2007 елны Төмән өлкәсе Төмән районы Янтык авылында Сабирова Мәгъсүмә Нурулла кызыннан (1909 елгы) З.М. Арикеева (Брусько) тарафыннан язып алынды.

Путалок / Авторның шәхси архивы. 06.07.2006 елны Саратов өлкәсе Петровский районы Тат. Пакаевка авылында Киримова Асия Мөнир кызыннан (1962 елгы) З.М. Арикеева (Брусько) тарафыннан язып алынды.

Сарык йоны / Авторның шәхси архивы. 04.12.2007 елны ТР Яшел Үзән районы Бишнә авылында Галиуллина Асия Галәветдин кызыннан (1942 елгы) З.М. Брусько тарафыннан язып алынды.

Современная энциклопедия мамы и малыша. От беременности до трех лет // сост.: О.В. Еремеева, А.В. Митрошенков/ М.: РИПОЛ классик, 2009. 512 с.

Суга төшеп китү / Авторның шәхси архивы. 01.06.2014 елны ТР Мамадыш районы Комаровка авылында Мансурова Анастасия Николай кызыннан (1937 елгы) З.М. Брусько тарафыннан язып алынды.

Татар халкының мифологик ышанулары (XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы экспедиция язмалары буенча) // кереш мәкалә авторы Л.Х. Дәүләтшина, төз.: Л.Х. Дәүләтшина, Ф.Х. Җәүһәрова. Казан: Ихлас, 2016. 199 б.

*Толстая С.М.* Беременность, Беременная женщина // Славянские древности.: Этнолингвистический словарь: в 5 т. Т. 1: А–Г / под общ. ред. Н.И. Толстого. М.: Международные отношения, 1995. 575 с.

Убыр ала / Авторның шәхси архивы. 07.10.2006 елны ТР Питрәч районы Янсуар авылында Степанова Мария Яков кызыннан (1930 елгы) З.М. Арикеева (Брусько) тарафыннан язып алынды.

*Толстая С.М.* Два // Славянские древности.: Этнолингвистический словарь: в 5 т. Т. 2: Д–К / под общ. ред. Н.И. Толстого. М.: Международные отношения, 1999. 697 с.

*Фрезер Дж.* Золотая ветвь. М.: Изд-во политической литературы, 1980. 831 с.

*Хисамитдинова Ф.Г.* Словарь башкирской мифологии. Уфа: ИИЯЛ УНЦ РАН, 2011. 164 с.

Якынлык кылу / Авторның шәхси архивы. 23.05.2006 елны ТР Биектау районы Өлә авылында Әхмәтҗанова Рабига Хәйрулла кызыннан (1912 елгы) З.М. Арикеева (Брусько) тарафыннан язып алынды.

Шитина / Авторның шәхси архивы. 01.07.2014 елны ТР Апас районы Багыш авылында Хәлилова Хаҗирә Заһидулла кызыннан (1941 елгы) З.М. Брусько тарафыннан язып алынды.

***Брусько Зәлия Мансур кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, «Татар ядкярләре» үзәгенең халык иҗатына караган материаллар белән эшләүче белгече (Казан)*

УДК 398.3

***И.И. Фазлетдинов***

# БАШКОРТСТАНДАГЫ ТАТАР АВЫЛЛАРЫНА НИГЕЗ САЛЫНУ ТУРЫНДАГЫ РИВАЯТЬЛӘР: ТАРИХИ АСПЕКТ

Статья посвящена исследованию исторических основ преданий о возникновении татарских сел и деревень Башкортостана, их взаимосвязи с социально-политическими процессами, протекающими в описываемые периоды. Отдельно выделяются и анализируются мотивы, связанные с насильственным крещением казанских татар Иваном Грозным, с освоением татарами-переселенцами новых земель, их взаимоотношениями с местным населением, языковой и религиозной самобытностью. Автор приходит к выводу о том, что произведения данной тематической группы являются художественным отражением реальной истории народа через призму фольклорного восприятия.

**Ключевые слова:** татарский фольклор, исторические предания, классификация, мотив, разновидности, исторический аспект, села Башкортостана.

The article is devoted to the study of the historical foundations of the traditions about the origin of Tatar villages of Bashkortostan, their relationship with the socio-political processes taking place in the described periods. The motives associated with the forced baptism of Kazan Tatars by Ivan the Terrible, with the development of new lands by the Tatar settlers, their relationship with the local population, linguistic and religious identity are separately highlighted and analyzed. The author comes to the conclusion that the works of this thematic group are an artistic reflection of the real history of the people through the prism of folklore perception.

**Keywords:** tatar folklore, historical traditions, classification, motive, varieties, historical aspect, villages of Bashkortostan.

Татар халкының авыл тарихларына багышланган риваятьләрен җыю һәм өйрәнү тарихы артык зур түгел. XX гасырның соңгы чирегенә кадәр ул фрагментар характерда була һәм вакытлы матбугатта дөнья күргән берничә мәкалә белән генә чикләнә. Системалы һәм шактый тулы рәвештә әлеге төркемгә караган риваятьләр беренче тапкыр 1987 елда дөнья күргән «Татар халык иҗаты» 12 томлыгының «Риваятьләр һәм легендалар» томында урын ала [Татар халык..., 1987, б. 137–204]. Биредә 94 авыл тарихы урнаштырыла, шуларның 13е Башкортстандагы татарлар күпләп яшәгән районнарда язып алына [Татар халык..., 1987, б. 137–204].

Башкортстан татарларының фольклорын, аерым алганда, риваятьләрен һәм легендаларын җыю һәм өйрәнү тарихы күренекле галим Р.М. Мөхәммәтҗанов тарафыннан 1960 еллар урталарыннан гына башлана. Ул 1962–1990 елларда Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасы доценты сыйфатында республикадагы 150 дән артык татар авылын фольклор экспедицияләре белән

урап чыгып, бай материал туплый; аларны саклау һәм өйрәнү өчен кафедра каршында махсус фольклор фонды оештыра [Фазлетдинов, 2019, б. 95–96]. Тупланмада риваятьләр һәм легендалар, шул исәптән, авыл тарихларына багышланганнары да, шактый күп була, ләкин алар үз вакытында басылып чыкмый һәм фәнни тикшерү объекты буларак каралмый [Фазлетдинов, 2019, б. 96].

Р.М. Мөхәммәтҗановның 1995 елда вакытсыз вафатыннан соң бу эш аның укучысы И.К. Фазлетдинов тарафыннан дәвам иттерелә. Башкортстан татарларының риваятьләр һәм легендалар мирасын өйрәнү буенча махсуслашып, ул 2005 елда «Башкортстан татарларының топонимик риваятьләре һәм легендалары: тарихи нигезләре һәм идея-эстетик функцияләре» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый [Фазлутдинов, 2005]. Хезмәтнең бер бүлегендә авыл атамаларына бәйле этиологик мотивларның риваять сюжетындагы урыны тикшерелә. [Фазлутдинов, 2005, с. 106–173]. Моннан тыш яшь галим Башкортстандагы авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдә XVI–XIX гасырлардагы миграция процессларының чагылышын анализлаган монографик пландагы тикшеренүен бастырып чыгара [Фазлетдинов, 2003, 201 б.]. Аның кушымтасында 173 риваять тексты урын ала [Фазлетдинов, 2003, б. 112–184]. Нигездә, үзе туплаган материалларга нигезләнеп, И.К. Фазлетдинов 2018 елда Башкортстан китап нәшриятында «Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» китабын нәшер итә [Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр..., 2018]. Биредә урын алган 702 фольклор үрнәгенең 169 ын авыл тарихлары турындагы риваятьләр тәшкил итә [Башкортстан..., 2018, б. 37–105]. Остазы Р.М. Мөхәммәтҗанов туплаган материалларны электрон форматка күчереп һәм шуңа үзе җыйган язмаларны өстәп, И.К. Фазлетдинов 2021 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать интитутында өч китаптан торган «Башкортстан татарлары фольклоры» сериясен бастырып чыгара [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021; Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021; Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., 2021]. Тарихи-географик принциптан чыгып төзелгән җыентыкларга башка фольклор жанрлары белән беррәттән 167 авыл тарихы тексты да урнаштырыла [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021, б. 23–46; Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 23–60; Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., 2021, б. 23–61]. Әлеге язмабызның тикшеренү объекты булып әлеге тупланмаларда нәшер ителгән авыл тарихлары турындагы риваятьләр һәм үзебез туплаган аерым материаллар, тарихи чыганаклар хезмәт итә.

Риваятьләр составындагы авыл тарихлары – бик үзенчәлекле төркем. С.М. Гыйләҗетдинов билгеләвенчә, алар «гадәттә, теге яки бу авылның кайдан, кайчан, нинди сәбәпләр аркасында күчеп килүе турында сөйли. Авыл тарихларында төбәккә беренче килеп утыр-

ган кешеләр, аерым нәселләр тормышындагы мөһим вакыйгалар турында төрле мәгълүматлар бирелә. Бу ягы белән алар тарихи риваятьләргә якын торалар. Күп әсәрләрдә авыл исеменең килеп чыгышы да аңлатыла. Монысы исә – топонимик риваятьләргә хас күренеш» [Гыйләҗетдинов, 1987, б. 13]. И.К. Фазлетдинов фикеренчә, «авыл тарихларының шушы үзенчәлеге – бер үк вакытта топонимик та, тарихи да характерга ия булуы – аларны риваятьләр составындагы аерым төркем итеп карарга мөмкинлек бирә» [Фазлетдинов, Кереш, 2021, б. 16]. Шуны истә тотып, автор үзе төзегән җыентыкларда әлеге төркемне топонимик риваятьләргә дә, тарихи риваятьләргә дә кертмичә, аерым урнаштыра.

Н.А. Криничная рус халкының тарихи риваятьләрен 9 тематик төркемгә бүлеп анализлый. Галимә аерып чыгарган беренче сюжет төркеме – аерым бер төбәккә урнашу (күченү) һәм аны үзләштерү турындагы әсәрләр.

Калганнары – төбәкнең борынгы халкы – «аборигеннары»; «паннар» – алпавытлар; яшерен хәзинәләр; алып, батыр, пәһлеваннар; илбасарлар белән көрәш; караклар һәм юлбасарлар; патриарх Никон реформалары белән килешмичә, православие динենең борынгы рәвешенә тугры калган раскольниклар һәм тарихи затларга бәйле риваятьләр [Криничная, 1987, с. 30–220].

Әлеге классификациягә таянып, бу мәкаләдә без беренче сюжет төркеменә караган риваятьләрне тикшерәбез. Аерым бер төбәккә күченеп урнашу һәм аны үзләштерүгә багышланган әсәрләр Башкортстан татарлары риваятьләре составында иң еш очрый торганы һәм ул шактый архаик төркемне тәшкил итә.

Бу сюжет төркемен түбәндәге мотивлар барлыкка китерә.

1. Авылга нигез салучы аерым бер кеше турындагы әсәрләр. Мәсәлән, Куергазы районының Тимербай, Кушнаренко районының Иске Тукмаклы, Кыйгы районының Идрис, Султановка, Мәчетле районының Абдулла, Тәтешле районының Аксәет, Туймазы районындагы Карамалы-Гобәй, Мулла, Тукай, Ярмөхәммәт авыллары тарихларына багышланган риваятьләр [Башкортстан…, 2018, б. 69–70, 71, 74, 75; Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021, б. 31–32, 34, 36–37, 37–38; Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 42–43, 47].

2. Авылга нигез салучы бертуганнар турындагы үрнәкләр. Мәсәлән, Кушнаренко районының Рәсмәкәй, Туймазы районының Сәрдек, Ярмәкәй районының Сөярмәт авылларына багышланган риваятьләр [Башкортстан…, 2018, б. 72; Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021, б. 35, 44–45].

3. Конкрет территориядән тулы гаилә белән күчеп утыру хакындагы әсәрләр. Мәсәлән, Краснокама районының Яңа Каенлык, Кушнаренко районының Әхмәт авыллары тарихлары [Башкортстан…, 2018, б. 70; Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 37–38].

4. Авыллары белән күченүчеләр яки туганлык мөнәсәбәтләрендә торучы халыкның төркем белән яңа җирләргә килеп төпләнүе турындагы үрнәкләр. Мәсәлән, Краснокама районының Яңа Хаҗи, Кушнаренко районының Үгез, Кыйгы районының Йөрәкле, Майский, Тукай, Мәчетле районының Яңа Мөслим авыллары тарихлары [Башкортстан…, 2018, б. 74, 75; Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 38, 40, 44–45].

И.К. Фазлетдинов Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаучы риваятьләрдәге авыл атамасының барлыкка килү мотивлары әлеге версияләргә генә сыешып бетми, дип билгели [Фазлетдинов, 2021, б. 85].

Аерым вакыйгаларга мөнәсәбәттә барлыкка килгән авыл исемнәре турындагы риваятьләрне дә галим яңа төркем буларак күрсәтә. Авыл атамалары, үз чиратында, тарихи вакыйгалар яки шәхесләр турындагы мәгълүматларны гына түгел, халыкның анимистик һәм тотемистик карашларын, борынгы ышануларын да саклый [Фазлетдинов, 2021, б. 85].

Башкорт фольклорчысы Ф.А. Нәдершина үзенең хезмәтләрендә авылларның килеп чыгышына бәйле тагын берничә мотивка туктала: нәсел башлыгының ничә бала үстерүе һәм нәселнең кайларда төпләнүе; беренче урнашкан кешеләрнең ыру-кабилә мөнәсәбәтләре; төбәккә башка милләт вәкилләренең күчеп утыруы; авыл янында аерым бер таш яисә корылма (ныгытма) хасил булу; күчеп утыручыларның балаларга үзенчәлекле исем кушулары; авыл атамасының көндәлек тормышта булган хәл белән аңлатылуы; кайчандыр әйтелгән сүзләргә бәйле мотивлар [Нәҙершина, 2006, б. 152–234].

Татарларның Россиянең төрле төбәкләренә һәм чит илләргә күчеп китүенең сәбәпләре, нигездә, тарихи шартлар белән бәйле. Бу – беренче чиратта, төрле сугышлар вакытында йорт-җирсез калу, басып алучылардан качып котылырга омтылу, җир җитмәү, ачлык. Татар халкына бәйле күченүләрнең тагын бер сәбәбе – халыкның үз диненә калырга теләве, ягъни көчләп чукындырулардан качу. Бу вакыйгалар язма чыганакларда, тарихи риваятьләрдә, шактый шартлы гына булса да, дастаннарда да саклана. Тарихи характердагы матур әдәбиятта да әлеге вакыйгаларга карата мәгълүматлар очрый.

Башкортстан татарларының аерым авылларына нигез салыну, аларның монда килеп урнашуы турындагы мәгълүматлар Әмирхан Еникиның «Соңгы китап» әсәрендә теркәлгән. Автор документаль характердагы әлеге әсәрендә үз нәселенең, ата-бабаларының һәм гомумән төмән кабиләсенең (хәзерге Мордовия Республикасы Темников шәһәре халкы) Башкортстан җиренә урнашу тарихын киң яктырта, тарихын һәм үткәнен ачыклый [Еники, 1987, б. 4–12].

Халык хәтеренең билгеле бер чикләре бар. Белгечләр риваять-легендаларның халык хәтерендә 200–500 ел чамасы саклануын әйтәләр, язмача теркәлмәгән очракта бу әсәрләр күпмедер вакыт үткәннән соң онытылуга дучар була [Толстова, 1983, с. 6–21]. Мәсәлән,

Аксак Тимер басып алулары, шул чорда күчеп килгән авыллар турында тарихи риваятьләр ХХ гасырда бик сирәк очрый. Бу, бер яктан, халык хәтеренең үз закончалыклары белән бәйле булса, икенче яктан, аларны соңрак булган вакыйгалар кысрыклап чыгара. Аксак Тимернең басып алу сугышларына бәйле вакыйгалар Явыз Иванның Казан ханлыгын яулап алуы турындагы риваятьләргә күчерелә. Бу – фольклорга хас анахронизм күренеше булып тора. Шулай итеп, бер риваятьтә берничә тарихи катлам яшәвен дә күзәтергә мөмкин.

Моның ачык чагылышын Башкортстандагы татар авыллары тарихларына багышланган риваятьләрдән дә күрергә мөмкин. Мәсәлән, биредә язып алынган үрнәкләрнең зур өлешендә Казан ханлыгы һәм Сембер губернасында яшәүче татарларның хәзерге Башкортстан җирләренә күчеп утыруы Явыз Иванның басып алу сәясәте, дөресрәге, аның яулап алу сугышларына бәйләп аңлатыла.

Мәсәлән, БДУ студенты Алсу Сөнәгатуллина тарафыннан укытучы Байсар Иманголовтан язып алынган Туймазы районы Карамалы-Гобәй авылы тарихының бер вариантын алып карыйк. «Элгәре Иван Грозный исемле бик явыз патша була. Ул башта мордва халкын басып ала, аннан чират чуваш, мариларга да җитә. Моннан соң Иван патша Урта Идел буенда яшәүче болгарларны да басып алмакчы була һәм Казанга һөҗүм итә. Ул Казанны ала алмый һәм ачуыннан тирәяктагы авылларны туздыра. Шундый авылларның берсе – безнең ата-бабаларыбыз яшәгән Байлар Сердәге исемле авыл була.

Бу авылда Гобәй исемле мулла яшәгән. Ул бик акыллы булган һәм халык аны нык ихтирам иткән. Урыс гаскәрләре килә башлагач, ул авыл халкын өлкән улы җитәкчелегендә Уралга озата. Тик үзе туган төягеннән китми, берничә авыл карты белән шунда кала. Сатлыкҗаннар аны урыс гаскәрләренә тотып бирәләр. Урыслар казанда сумала кайнатып, шунда Гобәйне салып үтерәләр. Калган картларны коллыкка озаталар.

Мулланың өлкән улы Алдаргол авыл халкын башкорт җирләренә алып бара. Алар Өсән елгасының аръягында тукталалар һәм әлеге Алдар тавында төпләнәләр. Яңа авылга Гобәй мулла исемен кушалар. Авылның тирә-ягын карама урманы әйләндереп алганлыктан, тиздән ул Карамалы-Гобәй дип атала башлый...» [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021, б. 31–32].

И.К. Фазлетдинов билгеләвенчә, бу авыл тамырлары белән хәзерге Татарстанның Кукмара районында урнашкан Зур Сәрдек авылына килеп тоташырга тиеш. 1994 елда Кукмара районында телче-галим Дөрия Рамазанова язып алган Сәрдекбаш авылы тарихына нигезләнеп, ул Зур Сәрдек авылын да читтән килүчеләр – хәзерге Киров өлкәсе Малмыж районындагы Старый Бурец авылыннан кайчандыр күчеп утыручылар нигезләвен исбатлый. Шулай итеп, «бер-берсеннән йөзләрчә чакрым читтә урнашкан һәм Россиянең өч төбәгенә караган авылларның тамырлары уртак булып чыга», дип фаразлый галим [Фазлетдинов, 2022, 21 окт.]. Без исә бу мәсьәләдә үз версиябезне

тәкъдим итәбез. Башкортстанның Туймазы районындагы Карамалы-Гобәй авылы, чынлыкта, Татарстанның Балтач районына караган Байлар Сәрдеге (рус. Бурбашский Сардыган) авылыннан күчеп килүчеләр тарафыннан нигезләнгән булырга тиеш. Бу авыл шулай ук заманында Казан губернасының Арча кантонына карый [Бөрбаш Сәрдегәне авылы тарихы]. Риваятьтә авыл атамасындагы «Сәрдек» сүзенең «Сердәк» булып үзгәрүен без гасырлар дәвамында барган фонетик процесслар, риваятьче хәтерендә күп кенә тарихи фактларның конкретлыгын югалта баруы белән аңлатабыз.

Бер үк вакытта нәкъ шушы риваять төрле чорларга караган тарихи катламнарның бер текст эчендә берегеп килүенә дә мисал була ала.

Шунысын да әйтеп үтү кирәк: күп кенә язма истәлекләр раслаганча, Башкортстанда татарлар Алтын Урда заманында ук яшәгән [Гильом де Рубрук..., с. 343]. Шуңа күрә, «Уфа татарлары» термины Идел буеннан Агыйделгә кадәрге территориядә элек-электән полоса булып сузылган татар авыллары утыруы аркасында кулланылышка кереп китмәгән [Миргалеев, Аксанов..., 2016, с. 6], чөнки биредә татарлар Уфа кальгасы барлыкка килгәнче үк (ягъни 1574 елга кадәр) яшәгән булып чыга.

«Фольклорда нәкъ менә шушы чорга кагылышлы, ягъни Казан яулап алынганнан соң Казан татарларының хәзерге Башкортстан территориясенә күчеп утыруларына бәйле ядкярләрнең аеруча күп сакланганлыгы тарих турында берьяклы нәтиҗәләр ясар өчен нигез була алмый, әлбәттә, – дип билгели филология фәннәре докторы Л.Х. Мөхәммәтҗанова. – Монда эпик характердагы фаҗигалы вакыйгаларның халык хәтеренә нык сеңеп, озак дулкынландырган булу фактын истән чыгарырга ярамый. Казан ягыннан килеп утырган татарларның Урал итәгендәге җирләргә урнашу вакыйгалары бу төбәккә татар кавеменең беренче кат аяк басуы дигән сүз түгел» [Мөхәммәтҗанова, 2019, б. 160–170]. И.К. Фазлетдинов фикеренчә, төбәктә язып алынган риваятьләрдә, шул исәптән, авыл тарихларында да, архаик, тамырлары белән борынгы мифологиягә килеп тоташкан мотивларның күп очравы да бу фаразның дөрес булуына ишарәли. Моңа мисал итеп, автор авылларны нигезләгәндә җирне тотем җанвар бүләк итү, яңа урында «изге» теләкнең тормышка ашуы, «илаһи билге» кебек мотивларны китерә һәм авыл тарихлары турындагы риваятьләрдә борынгы мал культы, тимерне изгеләштерү кебек бик ерак дәверләргә нисбәтле күренешләрнең образлы чагылышын билгели [Фазлутдинов, Синтез... 2021, с. 303–307]. Хәтта, беренче карашка, реаль эчтәлекле караклар һәм качкыннар турындагы риваятьләрдә дә мифологик карашлар бик зур роль уйный. Аерым алганда, биредә, «изгелекле» карак образларына мифик алыпларга хас сыйфатлар күчерелә [Фазлетдинов, Башкортстан татарларының качкыннар..., 2022, б. 88–89].

Авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрне анализласак, бер кызыклы күзәтү ясарга мөмкин: XVIII гасыр уртасы – XX гасыр

башында Башкортстан җирләрендә хасил булган татар авылларының күпчелеге эчке миграция, ягъни шушында ук элек нигезләнгән авыллардан халыкның бер өлеше күчеп китеп, яңа урыннарга барып төпләнүе нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Моның бер сәбәбе итеп, патшабикә Анна Иоанновна 1736 елның 11 февралендә кабул иткән Указны да исәпләргә мөмкин. Ул «дворяннарга, офицерларга, мишәрләргә» һәм шулай ук «типтәрләргә, бобыльләргә» башкорт җирләрен чикләүсез сатып алырга рөхсәт итә. Бу документ эчке миграция дулкыны көчәюгә зур этәргеч булган, дип исәпләргә тулы нигез бар. Моннан тыш XX гасыр башында крестьяннарны авыл общинасыннан тартып чыгарып, Европа илләре үрнәгендә аерым хуҗалыклар төзү максатын куйган Столыпин реформаларының да моңа тәэсире зур булган.

Риваятьләрдән күренгәнчә, татарларның элек килеп төпләнгән урыннарын ташлап, яңа җирләрдә авыл хасил итеп утыруларының төп сәбәбен табигый үсеш һәм Идел буеннан яңа күчеп килүчеләр өстәлү нәтиҗәсендә, халык саны артып, иске урында яшәү, иген игү өчен җир җитми башлау тәшкил итә. Билгеле, халыкның бер өлеше тормыш көтәр өчен яңа урыннар эзләргә мәҗбүр ителә. Мәсәлән, Зилаер районы Чуенчы-Чупан авылын Әлшәй районы Чуенчы авылыннан күчеп килгән татарлар 1901 елда Чупан нәселендәге башкорт байларыннан сатып алынган җирләрдә барлыкка китерәләр [Башкортстан…, 2018, б. 52–54].

Гомумән, риваятьләр өчен шундый бер мотив хас: авыл халкының бер өлеше, бүленеп, икенче урынга күчеп утырып, яңа авыл хасил итсә, аңа атама биргәндә, «яңа» сүзе кулланыла. Ягъни, халык элек яшәгән урынының исемен алып, аңа «яңа» сүзен өсти һәм, шул рәвешле, икенче атама хасил була. Бу эчке миграция күренешенең формаль күрсәткече булып хезмәт итә ала. Мәсәлән, авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдә Кушнаренко районы Иске Тукмаклы авылыннан – шул ук районның Яңа Тукмаклы [Башкортстан…, 2018, б. 71], Илеш районы Иске Хаҗи авылыннан – Краснокама районы Яңа Хаҗи [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 38], Иглин районы Иске Юрмаш авылларыннан – шул ук районның Яңа Юрмаш [Башкортстан…, 2018, б. 54], Краснокама районы Бөртек авылыннан – шул ук районның Яңа Бөртек [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 36–37], күрше Каенлык авылларыннан – шул ук районның Яңа Каенлык [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 37–38], Илеш районы Иске Күктау авылларыннан – шул ук районның Яңа Күктау [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., 2021, б. 45], Чакмагыш районы Карьяуды авылларыннан – шул ук районның Яңа Карьяуды [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., 2021, б. 57–58] авыллары бүленеп чыгуы күрсәтелә.

Әгәр аерылып китүчеләр еракка күчеп утырсалар, аларның элек яшәгән урыннарының исеме турыдан-туры яңа урынга күчерелә. Мәсәлән, Ярмәкәй районы Сөярмәт авылы тарихында [Башкортстан

татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021, б. 42–44] аңа нигез салучыларның «Минзәлә аръягындагы Сөярмәт» исемле авылдан күчеп килүләре турында хәбәр ителә. Мәчетле районының Мөслим [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 44–45], Краснокама районының Яңа Кабан авыллары [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 37] атамалары да җирле халыкның кайдан күчеп килгәнлегенә ишарә ясый[1].

Халыкның яңа нигезләгән авылга элек яшәгән урыннарының атамаларын бирүе очраклы түгел. Монда аның үз чыгышын, нәселнәсәбен ягъни тарихын, тамырларын саклап калырга омтылышы күренә. Киләчәк буыннар исем тәңгәллеге буенча, үзләренең бабаларының элек гомер иткән урыннарын тапсын, тамырларын онытмасын, аларның яшәү рәвешен, тормыш итү үзенчәлекләрен өйрәнсен өчен эшләнә бу эш. Ягъни биредә халкыбызның үзенчәлекле тормыш философиясе чагылыш таба.

Кайбер риваятьләрдә элек яшәгән урында төрле милләт, сословие, конфессия вәкилләре арасында низаглар чыгу Башкортстанда эчке миграция нәтиҗәсендә яңа авыллар барлыкка килүнең тагын бер сәбәбе итеп күрсәтелә. Мәсәлән, Авыргазы районы Нугазак авылы [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021, б. 24–25] тарихын тасвирлаган риваятьтә, дин һәм тел аерымлыклары аркасында, татарларның дүрт чуваш гаиләсен авылдан куып җибәрүләре һәм чувашларга, яңа урында төпләнеп, Чуваш Нугазагы авылын нигезләргә туры килүе турында хәбәр ителә. Шушы ук мотив Дүртөйле районы Мәскәү авылы [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., 2021, б. 37–38] тарихында да кабатлана. Биредә яшәүче татарлар һәм башкортлар 1914 елда күчеп килгән мариларны куып чыгарып, Олы Ялан авылына барып урнашырга мәҗбүр итә. Илеш районы Бәләкәй Бишкурай авылының [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., 2021, б. 40] барлыкка килүе исә риваятьтә тел мәсьәләсенә китереп тоташтырыла. Биредә Бишкурай авылы башкортларының типтәрләрне куып чыгарулары һәм яңа урынга күчеп утырырга мәҗбүр итүләре хакында хәбәр ителә.

Күренүенчә, дин һәм тел мәсьәләләре дә халык өчен гаять актуаль була. Динен һәм телен саклап калуны халык үзен саклап калуга тиңли, ят мәдәниятне, тормыш көтү рәвешен кабул итми, аны ничек тә үз мохитеннән кысрыклап чыгарырга омтыла.

Шулай итеп, авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдә халык үзе кичергән вакыйгаларны традицион фольклор алымнарыннан файдаланып, сәнгатьчә гомумләштереп бирә. Шуңа күрә, тарихи риваятьләр татар халкының үткәнен, аның үз тарихын, дөньяга карашын, төрле чорлардагы эстетик идеалларын ачыклау өчен кыйммәтле чыганак булып хезмәт итә.

---

[1] Татарстан Республикасының Мөслим районында – Мөслим, Лаеш районында Кабан исемле авыллар бар. *(И. Ф.)*

**Әдәбият**

Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М. Сөләйманов. Уфа: Китап, 2018. 344 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 312 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 296 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 304 б.

Бөрбаш Сәрдегәне авылы тарихы // Бөрбаш. URL: https://borbash.life.tatar/2011/07/blog-post_8399.html (мөрәҗәгать итү датасы: 20.01.2023).

Гильом де Рубрук о реке Ягаке и о разных землях и народах в этой стране / Приложения. Источники по истории татар Западного Приуралья // История татар Западного Приуралья. Том I. Кочевники Великой степи в Приуралье. Татарские средневековые государства. Коллективная монография. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. С. 343.

*Гыйләҗетдинов С.М.* Риваятьләр, легендалар һәм мифологик хикәятләр турында // Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 5–18.

*Еники Ә.* Соңгы китап. Истәлекләр. Казан: Татар.кит. нәшр., 1987. Б. 4–12.

*Миргалеев И.М., Аксанов А.В.* Введение // История татар Западного Приуралья. Том I. Кочевники Великой степи в Приуралье. Татарские средневековые государства. Коллективная монография. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2016. С. 6–7.

*Криничная Н.А.* Русская народная историческая проза: вопросы генезиса и структуры / ответ. ред. В.К. Соколова. Л.: Наука, 1987. 232 с.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Россия төбәкләрендә татар фольклоры (И.К. Фазлетдиновның «Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» (Уфа: Китап, 2018, 344 б.) китабына мөнәсәбәттә) // Фәнни Татарстан. 2019. № 1. Б. 160–170.

*Нәҙершина Ф.А.* Халыҡ хәтере (башҡорт халыҡ риүәйәт, легендаларының тарихи ерлеге, жанр үҙенсәлектәре). Тулыландырылған икенсе баҫма. Өфө: Ғилем, 2006. Б. 152–234.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов; фәнни редакторы Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 368 б.

*Толстова Л.С.* Использование фольклора при изучении этногенеза и этнокультурных связей народов // Фольклор и историческая этнография. М., 1983. С. 6–21.

*Фазлетдинов И.К.* Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрендә мифологик мотивлар // Фәнни Татарстан. 2021. № 4. Б. 84–97.

*Фазлетдинов И.К.* Башкортстан татарларының качкыннар һәм караклар турындагы риваятьләрендә тарих һәм мифология синтезы // Фәнни Татарстан. 2022. № 3. Б. 84–99.

*Фазлетдинов И.К.* Кереш // Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы

И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 296 б.

*Фазлетдинов И.К.* Риваятьтә халык тарихы. Авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдә XVI–XIX гасырлардагы миграция процессларының чагылышы: уку кулланмасы / фәнни редактор Ә.М. Сөләйманов. Уфа: БДУ нәшрияты, 2003. 201 б.

*Фазлетдинов И.К.* Ришат Төхвәтуллин белән Газинур Морат авылдашлармы? // Кызыл таң. 2022. 21 октябрь.

*Фазлетдинов И.К.* Фольклорчы галим Риф Мөхәммәтҗановның фәнни һәм педагогик эшчәнлеге // Фәнни Татарстан. 2019. № 4. Б. 94–99.

*Фазлутдинов И.К.* Синтез исторических и мифологических воззрений в преданиях населения северо-западного Башкортостана // Славянские этносы, языки и культуры в современном мире: материалы VII Международной научно-практической конференции, посвященной 95-летию со дня рождения доктора филологических наук профессора Леонида Михайловича Васильева (г. Уфа, 23 сентября 2021 г.) / отв. ред. В.Л. Ибрагимова, Л.А. Киселева. Уфа: РИЦ БашГУ, 2021. С. 303–311.

*Фазлутдинов И.К.* Топонимические предания и легенды татар Башкортостана: исторические основы и идейно-эстетические функции: дис. ... канд. филол. наук: 10.01.09. Уфа, 2005. 263 с.

***Фазлетдинов Илназ Илдус улы,***
*Казан (Идел буе) федераль университеты*
*Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникацияләр институтының*
*Журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбе ассистенты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*аспиранты*

УДК 2-725(571.1)

*З.Ә. Тычинских*

# XVI–XVIII ГАСЫРЛАРДА КӨНБАТЫШ СЕБЕРНЕҢ МӨСЕЛМАН ЭЛИТАСЫ

Рассматривается вопрос о составе мусульманской элиты в период Сибирского ханства и в более позднее время. Особое внимание отводится категориям сейидов и ахунов. Показано их присутствие в Западной Сибири в достаточно ранний период. Рассмотрены отдельные персоналии высшего мусульманского духовенства. Показана их роль в распространении ислама в Сибири.

**Ключевые слова:** Западная Сибирь, ислам, мусульманское духовенство, ахуны, сейиды, сибирские татары.

The question of the composition of the Muslim elite during the period of the Siberian Khanate and at a later time is considered. Particular attention is paid to the categories of seyyids and akhuns. Their presence in Western Siberia in a fairly early period is shown. Some personalities of the higher Muslim clergy were studied. Their role in the spread of Islam in Siberia is shown.

**Keywords:** Western Siberia, Islam, Muslim clergy, Akhuns, Sayyids, Siberian Tatars.

## Көнбатыш Себердәге ислам тарихы турында. Историографик аспект

Соңгы вакытта Себердә ислам тарихы буенча хезмәтләрнең саны шактый артуга карамастан, тикшеренүчеләрнең бу тема белән кызыксынулары кимеми [Бустанов, 2009; 2012; 2013; Исхаков, 1997; 2011; Маслюженко, 2019; Селезнев, 2018; Татауров, Корусенко, 2015 һ.б.]. Бу Көнбатыш Себерне исламлаштыру мәсьәләсенең озак вакытлар аз өйрәнелгән тема булып калуы, шулай ук, чыганаклар базасы шактый сай булган шартларда, аны тикшерүнең яңа алымнарын эзләү белән бәйле.

Бүгенге көндә тикшеренүчеләр алдында торган иң мөһим бурычларның берсе – Көнбатыш Себер территориясендә исламлаштыру процессының гомуми схемасын эшләү, аның характерын һәм төп этапларын ачыклау.

Историографиядә мөселман диненең бу территорияләргә үтеп керә башлавы турында берничә фараз бар. Әйтик, Төмән тикшеренүчесе Р.Х. Рәхимов Себергә исламның шактый иртә үтеп керүе турында яза. Аның фикеренчә, бу процесс XII гасырның беренче яртысында башланып китә.

Шуңа бәйле рәвештә, Себергә ислам диненең шактый иртә (XII гасырда) үтеп керүен күздә тоткан Ф.Т. Вәлиев гипотезасы игътибарга лаек. Ул, В.П. Даркевич хезмәтенә таянып, сәүдә кәрваннары составындагы Идел буе болгарлары һәм гарәп руханилары

вәкилләренең, һәм хәтта X гасырда Идел буе болгарларына Багдад хәлифәлеге илчелеге белән килгән гарәп руханиларының Көнбатыш Себердә ислам динен тарату ихтималы зур булуын ассызыклый [Валеев, 1993, с. 171]. Әмма, тулаем алганда, Ф.Т. Вәлиев фикеренчә, «Себер татарлары исламны казан татарларының бабаларына караганда соңрак... ә бараба татарлары XVIII гасырда гына кабул иткән» һәм историографиядә ислам диненең Себергә соңрак (XIV гасыр азагында) үтеп керүе һәм таралуы турындагы версияне тарихта аеруча киң таралган [Валеев, 1993, с. 169].

Мөселман шәех-миссионерларының килүе турындагы легенда белән бәйле әлеге версия күп кенә тарихи хезмәтләрдә урын алган, һәм ул Тобольск музей-тыюлыгында сакланучы, үз вакытында Н.Ф. Катанов тарафыннан тәрҗемә ителгән кулъязмаларга [Катанов: 1904] барып тоташа. Алар, кайбер тикшеренүчеләр фикеренчә, Карагай кулъязмасының соңгы нөсхәләре булып тора. Берсе – Сәид Вәккас б. Рәҗәб Аллакулов, икенчесе Кәшшаф Әбүсәидов тарафыннан һиҗри буенча 797 елда (1394–1395) язылган. Алардагы мәгълүматларга караганда, Нәкышбәндия тарикатына нигез салучының боерыгы буенча 336 шәех, һәм алар белән бергә 1700 җайдак һәм Күк Урда ханы Шәйбан, бергәләп, Иртыш буйлап төшәләр, анда Тархан хан иленнән «дингә нык ышанучылар хакиме кылычыннан качып» килгән халык, шулай ук Хотан, Нугай һәм Кара Кыпчак халыклары яши торган була. Кытайдан качып киткән халык турында кулъязма авторлары «курчакларга, ягъни потларга табынучы татарлар» дип хәбәр итәләр. Кулъязмаларда шулай ук Хуҗа Баһаветдиннең шәехләргә бу халыкларны вәгазьләргә, тәкъдим кабул ителмәгән очракта, алар белән дин өчен бөек сугыш башларга әмер бирүе турында әйтелә. Әлеге халыклар ислам динен кабул итүдән баш тартканнар. Бөек сугыш булган. Яр буйларында татарлар һәм мәҗүсиләр яшәгән бер генә елганы да, сазлыкны да, чокырны да калдырмаганнар. Ләкин үзләре дә авыр югалтуларга дучар булганнар. Исән калган остяклар, исламны кабул итмичә, урманга качканнар, Тархан белән килгән кешеләр кабат Кытайга кайтып киткәннәр. 300 шәех дин өчен сугышларда һәлак булган. Ә исән калган 66 шәехнең өчесе, дингә өйрәтү өчен, Себердә яшәп калган. Шушы вакыйгалардан соң, дип хәбәр ителә кулъязмада, төбәктә ислам дине урнашкан [Катанов, 1904].

А.К. Бустанов Себердә ислам диненең шактый соң тарала башлавы турындагы версияне тәкъдим итә. Тикшеренүче фикеренчә, 1394–1395 елларга караган кайбер манускриптларда телгә алынган шәехләрнең Көнбатыш Себердә Баһаветдин Нәкышбәнд исеме белән бәйле булган «ислам динен кертү» максаты белән оештырылган явы, Ясәвия һәм Нәкышбәндия тарикатлары арасында көндәшлек күзәтелгән XVI–XVII гасырларда уздырылган булырга мөмкин [Бустанов, 2009, с. 159].

Омск шәһәре галимнәре А.Г. Селезнев һәм И.А. Селезнева фикеренчә, Көнбатыш Себердә ислам дине таралу Алтын Урданы һәм

Алтын Урдадан соңгы дәүләтләрне исламлаштыруның гомуми контекстында алып барылган [Селезнев, Селезнева, 2018, с. 243]. Бу хәл әле тагын да тирәнрәк өйрәнүне таләп итсә дә, Себердә исламлаштыру барышын чыганаклар нигезендә, Алтын Урдадагы синхрон процесслар белән чагыштырып карап кына торгызырга мөмкин [Маслюженко, 2019]. Ислам таратуда Ясәвия һәм Нәкышбәндия суфи тарикатлары мөһим роль уйнаган. Д.Н. Маслюженко, Казан тарихчысы Д.М. Исхаков кебек үк, Себердәге бу процесслар Шәйбанилар династиясе белән бәйле дип саный. Аларның конфессиональ сәясәте нәтиҗәсендә ислам башта хөкемдарлар сараенда һәм күчмә аксөякләр даирәсендә, ә аннары гади халык арасында таралган һәм «Төмән һәм Себер ханлыгының дини картасында төп урынны алган» [Маслюженко, 2019].

Археологик һәм этнографик материалга мөрәҗәгать итүгә дә карамастан, чыганаклар базасының сай булуы әлегә фәнни эзләнүләр исламның Себер төрки-татар политийларының аксөякләр катлавына йогынтысын тикшерү кысаларыннан чыгарга мөмкинлек бирми. Төп, ясак түләүче халыкны исламлаштыруга килгәндә, Д.Н. Маслюженко «...для времени Тюменского ханства можно говорить и о том, что процесс исламизации охватил и рядовые группы кочевников» дип фаразлый [Маслюженко, 2019, с. 149]. Шул рәвешле, галим Көнбатыш Себер төрки халкының, һәрхәлдә, аның югары стратларының шактый иртә исламлашу версиясен тәкъдим итә.

Тикшеренүчеләрнең күбесе Себер төбәгендә ислам дине таралу барышында Әхмәтгәрәй һәм Күчем ханнарның аерым роль уйнавын ассызыклый, алар идарә иткән чорда Төмән һәм Себер ханлыкларында ислам төп урынны алган. Тарихи әдәбияттагы өч миссиянең дә Күчем хан тарафыннан оештырылуы турындагы версия бик үк төгәл түгел. Булган чыганакларга таянып, шуны әйтергә мөмкин: Себер ханлыгы җирләрендә ислам динен таратуның беренче миссиясен Күчемнең олы абыйсы Әхмәтгәрәй хан оештырган диярга була. Ул Себер ханлыгында Күчемгә кадәр идарә иткән. «Предание тобольских татар о прибытии в 1572 г. мухаммеданских проповедников в г. Искер» китабында түбәндәге юллар бар: «В его время умер шейхуль ислам Искерской земли» и Ахмед-Гирей обратился к правителю бухарского ханства с просьбой прислать «великого шейхуль ислама» [Катанов, 1897, с. 51].

Һәрхәлдә Искер йортының югары катлавына исламның билгеле булуы Радловның «Образцы...» китабында да раслана. Анда «Происхождение аула Сала» легендасында авылга нигез салучының Сала исемле булуы әйтелә. Аның атасы Сөләйман бай турында болай диелгән: «...пришел на эти земли из Бухары в составе людей Тайбуга-бия, сына Шах-Мурада. Вместе с Тайбугой прибыли на земли будущего Искира 500 человек, среди которых был муфтий и мударрис… Пришельцы основали город Искир…» [Усманов, Шайхиев, 1979, с. 91].

Тайбуга бәклеге (Искер йорты) халкының бер өлеше ислам динен кабул итсә дә, ислам бу төбәктә соңрак ныгып урнаша: «...широкое внедрение ислама в Сибирском ханстве произошло незадолго до его завоевания Московским государством, в связи с чем можно предположить, что становление системы исламского сообщества и формирование исламских институтов происходило достаточно поздно – на рубеже XVI–XVII вв., что во многом может объяснять определенные их особенности» [Татауров, Корусенко: 2015, с. 804].

С.Ф. Татауров һәм М.А. Корусенко Себер төбәгендә ислам дине таралуның түбәндәге чорларга бүленешен тәкъдим иттеләр:

1. XII гасыр ахыры – XIV гасыр башы – җәмгыятьтәге югары катлауның яңа дин белән танышуы;

2. XVI гасырның 60–70 нче еллары – XVI гасыр ахыры – Себер ханлыгы яшәгән вакыт – Себер ханлыгы халкы тарафыннан исламны дәүләт дине буларак кабул итү буенча Күчем хан эшчәнлеге белән бәйле;

3. XVII–XVIII гасырлар – эре шәһәрләр тирәсендә һәм кайбер авыл торак пунктларында җәмгыятьләр оешу дәвам итә;

4. XIX гасыр –XX гасыр башы, Көнбатыш Себернең төрки телле халкы тулаем исламлаша. Бу этап Идел-Урал буе татарларының Көнбатыш Себергә күпләп күчеп утыруы белән бәйле [Татауров, Корусенко, 2015, с. 804].

Безнең карашка, тәкъдим ителгән схемада исламлаштыру процессында зур роль уйнаган «Бохарлылар» факторы исәпкә алынмаган, шулай ук Идел-Урал буе татарларының роле бераз арттырып бәяләнгән. Бу төркем Себергә күпләп күченгән вакытка – XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына – Себер татарлары инде күптән мөселман булган.

**Себер сәетләре**

Себер ханлыгы чорында һәм соңгырак дәверләрдә төбәктәге мөселман руханиларының составы турындагы мәсьәлә бик аз өйрәнелгән. Шунысы билгеле: исламлаштыру нәтиҗәсендә ислам дине әһелләре дә Себер ханлыгы элитасы составына кергән. Төрки-татар дәүләтләрендә иң югары рухани затлар булып сәетләр саналган. Алар Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән булганнар һәм мөселман дин әһелләренең үзенчәлекле категориясен тәшкил иткәннәр [Исхаков, 2011, с. 5]. Алтын Урда дәүләтендә һәм аннан соңгы татар ханлыкларындагы сәетләр институты Д. Де Виза һәм Д.М. Исхаков хезмәтләрендә шактый җентекләп тикшерелә [Исхаков, 1997; Исхаков, 2011; DeWeese, 1994; DeWeese, 1995]. Тикшеренүчеләр төрки-татар дәүләтләрен исламлаштыру процессында сәетләрнең аеруча зур роль уйнавын билгеләп үтәләр. Д.М. Исхаков сәетләрнең Шәйбанилар дәүләтендә, аннары Себер ханлыгында булуын ачыклый [Исхаков, 1997; Исхаков, 2011, с. 24].

Шул ук вакытта, ул билгеләп үткәнчә, Себер ханлыгына кагылышлы сәетләр институты турындагы мәгълүматлар шактый

соң – Күчем хан идарә иткән чорда гына пәйда була [Исхаков, 2011, с. 25]. Шуның белән бергә, сәетләрнең Шәйбанилар дәүләтендә күпкә иртәрәк булуы да билгеле. Чыганакларга нигезләнеп, дәүләт халкын исламлаштыру чорында хан сараенда сәетләрнең роле аеруча зур булган, дип тә әйтергә мөмкин.

Әйтик, Әбелхәер хан даирәсендә үк Кара сәет һәм Колмөхәммәд сәет була, алар ханның кайбер походларында катнашып, дини вазифалар гына түгел, хәрби функцияләр дә үтиләр [DeWeese, 1995, p. 619–620]. С.В. Бахрушин XV гасырда Казан ханлыгыннан качып китеп, Ибәк хан янына килгән Тәвәкәл һәм Касыйм сәетләр турында яза: «К Ибаку поехали другие сторонники Али-хана: Бегиш с сыном Утешем, сеиды Табекай (Тевекел) и Касым и «иные их товарищи»… [Бахрушин, 1955, с. 156]. Д.М. Исхаков Себер ханлыгындагы ике «югары сәетнең» исемен атый – Ярым сәет (1572–1574) һәм аның бертуганының улы Дингали сәет (чама белән 1574–1575 еллардан алып 1582 елга кадәр) [Исхаков: 2011, с. 173–174]. Ярым сәетнең ата-бабалары Искер йортында югары сәетләр булып торган булырга мөмкин, дип фаразлый [шунда ук, б. 170–171]. Югарыда аталганнардан тыш, Күчем хан заманында шулай ук Толмөхәммәд (Толмәмәт) сәет тә киң билгеле булган дип әйтергә мөмкин. Себернең Мәскәү дәүләте составына керү чорына караган документларда аның исеме еш искә алына [АИ, 1841, с. 7]. Толмәмәт сәет 1598 елда Тара воеводасы А. Воейков тарафыннан әсирлеккә төшкән кешеләр арасында була, соңгысы Борис Годуновка язган хатында болай дип белдерә: «...и я холоп твой привел к шерти Кучюмова Тул-Мамета сеита» [АИ, 1841, с. 3]. Хатта шулай ук Толмәмәтне кайда җибәрүе хәбәр ителә: «Кучюма царя сыскивать в Чаты и в Колмаки, и где он Кучюмам царя найдет, и я холоп твой приказал ему говорить Кучюму царю, чтоб Кучюм царь ехал служить к тебе…» и «к Чатцким лутчим людям, чтобы все они шли лутчие люди в твой Государев Царев и Великого князя Бориса Федоровича Всеа Руси город на Тару…» [АИ, 1841, с. 4]. Күчем янына җибәрелгән Толмәмәт ханны тапкан, ике көн буе аның белән бергә һәлак булган татар сугышчыларын җирләгән [АИ, 1841, с. 4–5].

Себер Мәскәү дәүләтенә кушылганнан соң да, биредә сәетләрнең нәселләре сакланып калган. Мәсәлән, бу турыда Г.Ф. Миллер болай дип яза: «...об сеитской семье, которая живет недалеко от Тобольска в Сабанаковых и Тадзымовых юртах, сохранилось предание, что они ведут свой род от времен Кучума. Эта семья замечательна еще тем, что ее родоначальник Дин-аул-ходжа, родом из Ургенча, был женат на дочери хана Кучума по имени Нал-Ханиша. В Тобольске же мне была сообщена следующая родословная: Дин-аул-ходжа имел трех сыновей – Султамет-ходжу, Сеитмемета и Аксеита, которые обосновались в Таре; сыновья Сулмамета: Юсуп-ходжа и Аюп-ходжа жили в Тобольске. Сыновья же Аюп-ходжи: Султамет-ходжа и Яя-ходжа жили в мое время в вышеназванных юртах» [Миллер, 1999, с. 196].

**Себер ханлыгы чоры ахуннары**

Тикшеренүчеләр шулай ук мөселман дин әһелләренең шәех, мулла, хаҗи, абыз (хафиза), мөфти һәм мөдәррис кебек категорияләрен дә атыйлар [Исхаков, Измайлов, 2007, с. 271]. Әлеге мәгълүматлар Себер татарларыннан В.В. Радлов тарафыннан язып алынган «Ильяс мулла атасындан ишеткәне» риваяте белән дә раслана. Анда Әхмәтгәрәй һәм шәехел-ислам белән бергә Себергә килгән дин әһелләре – шәехләр, муллалар, ахуннар һ.б. санап үтелә [Радлов, 1872, с. 212].

Күчем ставкасында «муллалар, сәетләр һәм абызларның...» булуы Себер елъязмаларында, аерым алганда, Есипов елъязмасында искә алына [ПСРЛ, 1987, с. 84]. Дөрес, Себер ханлыгында Әхмәтгәрәй белән бергә килгән мөселман миссиясе һәм руханилар составындагы ахуннар булуы мәсьәләсендә Д.М. Исхаков үзенең шикләнүен белдерә. Бу термин XIX гасыр «эзе», ягъни ахуннар киңрәк билгеле булган заманга бәйле дип саный [Исхаков, 2011, с. 178]. Алар хакында риваятьтә, шулай ук Г.Ф. Миллерның хәбәрләрендә [Миллер, 1999] әйтелүгә карамастан, тикшеренүче ханлыкта ахуннарның булуы гипотетик ревештә, һәм ахуннар дигәндә, дин әһелләренең башка категорияләре – муллалар, абызлар күздә тотыла, дип саный [Исхаков, 2011, с. 178–179].

Әмма кайбер материаллар ахуннарның Себер татарлары тарихында хан заманы һәм ханнан соңгы чор номенклатурасында булуы турында гына түгел, ә XVI гасыр ахыры – XVII гасыр башында ахун вазифасын үтәгән реаль шәхесләр булуын дәлилли. Билгеле булганча, ахун (фарсыча хаванд яки ахунд – остаз, әфәнде) дип, гадәттә, ислам дине илаһиятчеләрен, галимнәрен, баш рухани затларын, мәхкәмә карарларын һәм дини-хокукый күрсәтмәләр чыгару хокукына ия мөселман хокукы белгечләрен атыйлар.

...Сәетләр династиясенә килгәндә, Себер ханлыгы чорыннан билгеле һәм Күчемнең кияве булган Дингали сәет XVI гасыр ахыры – XVII гасырның беренче өч унъеллыгына караган документларда искә алына: «тарский юртовской татарин сеид Тенелей Берелеев», находившийся на русской службе [Исхаков, 2011, с. 168; Бахрушин, 1955, с. 165]. Ул һәм аның варислары ханлык чорындагы югары дин әһеле статусларын югалталар, әмма сәетләр нәселеннән булулары аркасында татар халкы арасында аларның дәрәҗәсе дә, абруе да саклана.

**«Шәҗәрә рисаләсе»ндә ахуннар**

Ахуннар категориясе XVII һәм XVIII гасырларга караган Себер материалларында бар. Әйтик, Тара сәетләренең шәҗәрәсе язылган «Шәҗәрә рисаләсе»ндә хикәяләү Йосыф бинең улы Хуҗам-Шөкүр исеменнән алып барыла, ул үзен Тубыл шәһәренең ахуны дип атый. Алга таба ул түбәндәгеләрне хәбәр итә: «наш отец Йусуф был бием во времена хана Кучума. Наш отец из этого мира переселился, но от него мы, Ходжам-Шукур-ахун, слышали о прибытии для обуче-

ния исламской вере Дин Али-ходжи, а также его происхождение от Сайид-Аты…» [Бустанов, 2009].

Китерелгән мәгълүматлардан чыгып, ахун Хуҗам-Шүкүр XVI гасыр ахыры – XVII гасырның беренче яртысында Тубылда (Тобольск) яшәгән. Рисаләдә әйтелгәнчә, Дингали хуҗа Тарадан Тубылга килгән, анда ул мөселман руханилары белән очрашкан, алар арасында ахун Хуҗам-Шүкүр, шулай ук Шәрбәти шәех исемнәре атала. Дингали хуҗа аларга «Ермак фетнәсендә» үзенең шәҗәрәсен югалтуын һәм аны торгызу өчен Үргәнҗкә барырга җыенуын хәбәр итә. Әмма югарыда исеме телгә алынган ахун аны сәяхәттән баш тартырга үгетли һәм болай ди: «Мы Вам сами напишем родословие на основе свидетельства всего народа и со слов и свидетельства прибывшего с Вами Шербети-шайха» [шунда ук]. Тубыл ахунының Дингали хуҗаның «сәетләр» нәселеннән булуын раславы һәм аның югалган нәсел шәҗәрәсен шул вакыйгаларның шаһитлары булган кешеләрнең сөйләве буенча торгызуы Тубыл губернасы Тара өязе Хуҗа авылында яшәгән хуҗаларның шәҗәрәләрендә сакланып калган [шунда ук].

Тубыл тарих-архитектура музей-тыюлыгы фондларында саклаучы Сәгъде Вәкъкас б. Рәҗәб Мәмәт-Аллакулның «Тубыл кульязмасын»да (ул күбрәк «Көнбатыш Себер халыкларына (инородецларына) каршы Шәех Баһаветдиннең дини сугышлары турында» кульязмасы буларак билгеле) шулай ук ахуннар турында әйтелә. Кульязма текстының шактый өлеше Көнбатыш Себерне исламлаштырганда һәлак булган шәехләрнең изге каберләрен теркәүгә багышланган. Бу чарада, Сәгъде Вәкъкас б. Рәҗәп Мәмәт-Аллакул күрсәткәнчә, Ибне Йәмин хуҗа белән бергә изге каберләрне (астана) бер шәҗәрәгә туплаган «Тубыл һәм Томск» ахуны Габделкәрим казый да катнашкан. Аннары сүз астананың тулыландырылган исемлегенең «Тубыл ахуннары»на җибәрелүе турында бара [Бустанов, 2011, с. 61–65]. Ә «Тара йорты ахуннары» 49 астананың ачык булуы турындагы серне белеп тора [Бустанов, 2011, с. 61–65]. Күчем хан идарә иткән вакытта ук Себергә килгән Шәрбәти шәех астаналарны исәпкә алуны оештыручыларның һәм анда катнашучыларның берсе дип күрсәтелгән. Кульязмада тасвирланган вакыйга авторларының берсе «Тубыл һәм Томск» ахуны дип аталу сәбәпле, әлеге хәлләр XVII гасыр башына (1604 елдан да иртәрәк түгел), Томскига нигез салынган вакытта карый дип фаразларга мөмкин. Шулай итеп, XVII гасыр башында яшәгән тагын бер Тубыл ахунының исеме ачыклана. Мөгаен, нәкъ менә ул әлеге вазифада Хуҗам-Шүкүр б. Йосыфны алыштырган.

### Тубыл ахуны Хуҗам-Шүкүр б. Әвәзбакый

Чыганакларда яңадан Хуҗам-Шүкүр исемен Тубыл татарларының ахуны сыйфатында без XVIII гасырның беренче яртысында очратабыз, аның атаклы Себер морзалары Колмәмәтовлар нәселенә (алар төбәкнең йомышлы һәм ясаклы татарлары белән татарлардан башлыклар сыйфатында идарә иткәннәр) турыдан-туры мөнәсәбәте

бар [Тычинских, 2010, с. 118–125]. Күптән түгел Пермь крае Дәүләт архивында Чиләбе тарихчысы Г.Х. Сәмигуллов тарафыннан Колмәмәтовлар гаиләсенә кагылышлы яңа документлар табылды. Шулар арасында Колмәмәтовларның морза «Әвәзбакый Колмәмәтовтан» башланган «Поколенная роспись»е дә бар. Ул шәҗәрәдәге XVIII гасырга нисбәтле кайбер моментларны ачыкларга ярдәм итте. Әйтик, XVII гасырда яшәгән Әвәзбакый Колмәмәтовның биш улы булган – Назар, Морзат, Сабанак, Мәмәтморат и Хоцамшүкүр. Аларның берсе, Сабанак, йомышлы татарларның башлыгы булып торган дип күрсәтелә, ә Хоцамшүкүр ахунлык иткән [ГАПК. Ф. 314. Оп. 1. Д. 109. Л. 82]. Шулай итеп, «Роспись»тәге мәгълүматларга караганда, Тубыл йомышлы татары Әвәзбакый Колмәмәтов улларының берсе ахунлык иткән [Тычинских, 2010, с. 117]. XVIII гасырның беренче чирегендә Тобольскида тоткын швед офицеры Ф.И. Табберт-Страленберг тарафыннан Әбелгази Баһадир ханның «Шәҗәрәи төрк» тарихи хроникасы күчермәсе табылу тарихы Әвәзбакыйның шушы улы белән бәйле. А.К. Бустанов тарафыннан Табберт-Страленберг көндәлегеннән китерелгән өзеккә таянсак, кульязма «баш рухани Ахун Әзбакый улыныкы» булган [Бустанов, 2013, с. 17]. А.К. Бустанов аны «Сабанак мирзаның һәм әсирлеккә төшкән швед офицеры Табберт-Страленбергның дусты» дип атый һәм исемен дә әйтә: Хуҗам-Шүкүр б. Әвәзбакый [Бустанов, 2013, с. 18]. Шулай ук Хуҗам-Шүкүр б. Әвәзбакый Ясәвия шәехе Дәүләт-шаһ Шаһ Габделваһһаб әл-Хөсәйни әл-Испичафиның шәкерте булган дип хәбәр итә. Һәм ул, мөгаен, мөгаллименең ярдәме белән кульязманы кулга төшергән [Бустанов, 2013, с. 18]. Ун елдан соң, 1734 елда, тарихчы Г.Ф. Миллер кульязманы Тобольскида «дини дәрәҗәле бер бохаралыда» күрүен әйтә, күрәсең, ул шул ук ахун булып чыга [Миллер, 1999, с. 192]. Ахунның әтисенең исемен̆ә (Әввәзбакый (Гәввәзбакый, Әвәзбакый)), шулай ук документта аның йомышлы татарлар башлыгы Сабанак Колмәмәтов белән якын мөнәсәбәттә булуы ассызыклану безгә Хуҗам-Шүкүр б. Әвәзбакыйның Тубыл йомышлы татары, ә 1692 елдан – йомышлы татарлар башлыгы, Себернең сәяси тормышында күренекле роль уйнаган Әвәзбакый Колмәммәтовның улы булган дип уйларга мөмкинлек бирә [Тычинских, 2010, с. 117–118]. Пермьдә табылган «Роспись» Хоцамшүкүр, яки Хуҗам-Шүкүр б. Әвәзбакый, «Агун Азбакеевич» – Тубылның баш дин әһеле – Тубыл йомышлы татарлары башлыгы Сабанак Колмәмәтовның бертуганы булган дип раслый [ГАПК. Ф. 314. Оп. 1. Д. 109. Л. 82].

Күрүебезчә, Колмәмәтовлар татарлар өстеннән дөньяви хакимиятне дә, дини идарәне дә үз кулларына тупларга омтылганнар. Шуңа күрә XVIII гасырның икенче яртысында морза Әвәзбакый (икенче) Колмәмәтов һәм ахун Әбтигарим Тацимов, шулай ук башлык Сабанак (икенче) Колмәмәтов исеменә «Мөселман кануннары» буенча барлык эшләрнең бары тик алар карамагына гына тапшырылуы турында иң югары күрсәтмә килә [РО ТИАМЗ. Д. № 12864. Л. 3]. Моннан тыш,

указда шулай ук «әлеге мөселман канунында» булган Тара, Томск, Төмән һәм Югары Тура ведомстволары татарлары аларга «дини эшләр буенча буйсынырга» тиеш, дип билгеләп үтелә. «По смерти помянутых головы Кульмаметева и агуна Тацимова те законные дела разбирательством случаи по их махометанскому закону и духовных чинов поныне головою Сабанаком Кульмаметевым производятся» [РО ТИАМЗ. Д. № 12864. Л. 3]. Шунысы игътибарны җәлеп итә: «мөселман кануны буенча» эшләр белән җитәкчелек итүне башта, ахун Тацимов белән берлектә, дин әһелләренә түгел, ә аристократларга – йомышлы татарлар башлыгы Әвәзбакый Колмәмәтовка һәм аның улы Сабанакка тапшырганнар. Документтан күренгәнчә, XVIII гасырның икенче яртысында әлеге эшләр белән татарлар башлыгы Сабанак Колмәмәтов шәхсән үзе шөгыльләнгән. Әмма, билгеле булганча, Тубылда ахун дип йөртелгән, Себердә татар дини иерархиясенең баш кешесе булган Әбтигарим Тацимовны Г.Ф. Миллер Сабанак Колмәмәтовның туганы дип атаган [Юшков, 1861, с. 299]. Күрәсең, Колмәмәтовлар кланы, төп дин әһелләре буларак, ахуннар вазифасын да, күпмедер вакыт үз кулында тоткан һәм нәсел буенча тапшырып барган.

Икенче яктан караганда, йомышлы татарларны гына түгел, татарлар башлыгы карамагында булган ясаклыларны да «хөкем итү һәм җәзага тарту» «мөселман кануннары» нигезендә башкарылуын игътибарга алмый мөмкин түгел [Миллер, 1996]. Күрәсең, XVIII гасырның икенче яртысында һәм дөньяви, һәм дини хакимият күпмедер вакыт Сабанак Колмәмәтов (икенчесе) кулында тупланган. Әйтергә кирәк, бу очраклы хәл түгел. Колмәмәтовлар, йомышлы татарлар башлыгы буларак, Тубылда ислам динен һәм аның позицияләрен саклауда шактый зур роль уйнаганнар. Җирле халык өстеннән зур хакимияткә ия булып һәм җирле хакимият сәясәтенә җитди йогынты ясап, алар христианлаштыру сәясәтенә актив каршы торганнар. Йомышлы татарлар шушы этник сословие төркеме булып яшәгән дәвердә, аларның уйланып оештырылган эшчәнлеге нәтиҗәсендә мөселманлыкта калганнар, дип уйларга кирәк.

XVII гасырда ук Тубыл митрополитларына патша грамоталары белән чит ил кешеләрен дә көчләп чукындыру тыелса да, бу боерыклар урыннарда еш кына үтәлмәгән. Җирле православие хакимияте барлык ысуллар белән Чиркәү тарафдарларын арттырырга омтыла, шуңа бәйле рәвештә Тубыл татарларыннан һәм бохаралылардан күпсанлы шикаятьләр килә. Татарларны актив христианлаштыруга каршы көрәшнең башында Әвәзбакый (беренче) Колмәмәтов җитәкчелегендәге йомышлы татарлар торган. Мәсәлән, 1686 елда Әвәзбакый Колмәмәтовның Тубылда яшәгән йомышлы татарларның, җирле өстенлекле татарларның (захребетные татары), ясак түләүче татарларының һәм бохаралыларның үтенеч язуы нигезендә, православие динен кабул итәргә теләүчеләрнең башта приказлар йортына гариза юлларга тиешлеге, аларны воеводалар караганнан соң гына, христиан диненә кабул итү турындагы бу үтенечләрне митрополитка

җибәрү хакында Мәскәүдән күрсәтмә килә. Митрополитның үзенә әлеге үтенечләрне кабул итү тыела һәм «не дождався из приказныя избы памятей – тех людей не крестить» дип боерык бирелә [Андриевич, 1889, с. 331–333]. Тубыл митрополиты, православиегә тарту өчен, нинди дә булса җинаять кылып, җәзадан яки элеккеге кабаладан котылу максаты белән диндәшләреннән качкан кешеләрне кабул иткән. Бу чара менә шул сәбәпле күрелгән. Тубыл воеводасына җибәрелгән 1697 елгы наказда көчләп христианлаштыруның тыелуы турында күрсәтмәләр тагын бер кат раслана: «беркемне дә көчләп чукындырмаска» [шунда ук]. XVIII гасыр башыннан Себерне колонияләштерүнең яңа этабы башлана, аны күренекле тарихчы А.В. Головнев «Филофей Лещинский эпохасы», яки «конфессиональ басып алулар эпохасы» дип атый [Головнев, 1995, с. 90]. XVIII гасырның беренче чирегендә актив рәвештә Себер халыкларын массакүләм христианлаштыру сәясәте үткәрелә башлый. Гомумән алганда, ул Пётр Беренченең эчке сәясәте белән билгеләнә. Огрызко бу турыда болай дип яза: «ставил перед церковью на первый план практическую задачу: средствами религиозного воздействия на верующих служить делу укрепления самодержавной власти» [Огрызко, 1941, с. 27]. 1706 елда Пётр митрополит Филофей Лещинскийга төньякка, остяк һәм вогуличларга (ханты һәм мансиларга) «Евангелие вәгазе» белән барырга куша. Ф. Лещинский, аның иптәшләре һәм дәвамчыларының миссионерлык эшчәнлеге нәтиҗәсендә XVIII гасырның 40–70 нче елларына Березовский краендагы ханты һәм манси халкының төп өлеше чукындырыла [шунда ук]. 1714 елгы указда вогуллар, остяклар, якутлар белән беррәттән татарларны да чукындырырга кушыла [Щеглов, 1883]. Тубыл һәм Себер митрополиты Филофей Лещинский заманында 1718–1720 елларда Тура татарлары, ә 1720 елда Обь һәм Чулым татарлары да чукындырылган. Ф.Т. Вәлиев китергән мәгълүматларга караганда, Тубыл губернасында 10 ел эчендә (1749–1758) 2 500 кеше христиан диненә күчкән [Валеев, 1993, с. 173–174]. Йомышлы татарлар яңадан көчләп чукындыруга актив каршылык күрсәткәннәр. 1724 елда митрополит Филофей Лещинский Синодка түбәндәгеләрне җиткерә: татары «подъезжают к новокрещенным и, смущая, велят именем своего начальника Сабанака церкви жечь, попов и причетников до смерти побивать и кресты побросать» [Огрызко, 1941, с. 68]. В.П. Клюева китергән мәгълүматларга караганда, 1755 елда православиегә күчкән, яңа чукындырылган (новокрещен) Павел Крупенин һәм аның иптәшләренең (16 кеше) митрополит Павел исеменә үтенеч язулары сакланган. Алар анда татарлар башлыгы Сабанак һәм бохаралылар старшинасы Алимов өстеннән шикаять белдерәләр «…Восприяли мы, нижайшие, православную христианскую веру. А понеже на нас по восприятии святого крещения по происку и домогательству татарского головы Азбакея Сабанакова и, да бухарского старшины Муллы Алимова положен неумеренной ясак. А именно по 2 рубля в год, которой они с нас спрашивают с немалою строгостию…

угрожают держать под караулом…» [ГБУТО ГА в Тобольске. Ф. 156. Оп. 2. Д. 265. Л. 3–3 об.; Клюева, 2002, с. 186–188]. Шул ук үтенеч язуында мондый юллар да бар: «Причем они, Сабанаков и Алимов, произносят и такие еще к поруганию христианской веры речи, что де хотя мы и крестились, а ис-под их власти не вышли, и что де хотят, то с нами новокрещеными, они и делают, и впредь делать будут» [ГБУТО ГА в Тобольске. Ф. 156. Оп. 2. Д. 265. Л. 3–3 об.].

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: «конфессиональ басып алу» этабы Себер татарларына һәм йомышлы татарларга карата, аерым алганда, Идел буендагы йомышлы татарлар белән чагыштырганда, – йомшаграк, ә Себердәге мәҗүси халыкларныкына караганда уңышсызрак уздырылган. Ерак Себердә, татар аристократиясенең социаль һәм хәрби ярдәме хакимият өчен дә бик зур әһәмияткә ия булган, бу – гаять зур Себер вотчинасының үзәктән ерак урнашуы, аның бетү куркынычы, хәтта XVIII гасырда да «башкортлар һәм кыргыз-кайсаклар» белән көрәштә татар атлы гаскәренә ихтыяҗ булу белән бәйле. Бу чорда мөселман дине мәнфәгатьләрен үтәү сәясәтен гамәлгә ашырган йомышлы мөселман татарларның ислам позицияләрен яклауда роле аеруча зур була. Себер-татар йомышлылар сословиесенә карата «йомшаклык» күрсәтү, безнең карашка, әнә шуның белән билгеләнгән. Монда дөньяви һәм дини лидерлар, шул исәптән Колмәмәтовлар кланы әйдәп баручы роль уйнаган. Клан кулында татар башлыклары һәм ахуннары, ягъни татарлар өстеннән дөньяви һәм дини хакимият югары затлары вазифаларының туплануы аның вәкилләренә мөселман конфессиясе позицияләрен яклау буенча уйланылган сәясәт алып барырга мөмкинлек бирә.

### XVIII гасыр мөселман дин әһелләре системасында ахуннар

1788 елда Екатерина II Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя (Оренбургское магометанское духовное собрание) оештыру турында указ чыгара. Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя оештырылгач, Россия империясенең элеккеге мөселман җәмгыятен оештыру системасы үзгәреш кичерә. Мөселман дин әһелләре иерархиясенең яңа структурасы шулай ук Урал һәм Себергә таратыла.

XVIII гасыр ахырыннан Россиянең закон актларында рухани затлар категорияләре төгәл регламентлаштырыла башлый. Әгәр Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя төзелгәнгәнче ахуннар җирле мөселман җәмгыятенең иң югары җитәкчеләре булсалар, ул оештырылгач, аларның статусы түбәнәя. Сайлап кую туктатыла, ахун вазифасы имамнарга Эчке эшләр министрлыгы яки Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя тарафыннан аларның аерым дини-административ хезмәтләре өчен бирелә торган мактаулы дәрәҗәгә әйләнә. Дин әһелләренең әлеге төркеменә карата яңа таләпләр куела: ахун бер сыйныфлы халык училищесы курсы күләмендә рус телен белергә тиеш була. Статуслары түбәнәюгә карамастан, ахуннар, кагыйдә буларак, берничә волость кергән төбәктә вазифалары буенча руханилар арасында өлкән

дин әһеле сыйфатында зур йогынтыга ия булганнар. Аларның, шулай ук хокуклары шактый киң булып, аерым дин-көнкүреш мәсьәләләрен хәл иткәндә имамнар һәм Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя арасында арадашчылар булганнар. Ахун вазифасын башкаручыларның өстенлекләренә килгәндә, Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыянең барлык рухани дәрәҗәләре һәм аларның балалары кебек үк, аларга да тән җәзасы бирү тыелган. Шул ук вакытта алар, үз сословиеләренә тиешле салымны түләргә, йөкләмәләр үтәргә тиеш булганнар (башка конфессия руханилары кебек өй башыннан алына торган салымны түләмәгәннәр). Шулай ук мәхәлләләр, авыл җәмгыятьләре карарлары нигезендә салымнар түләүне үз өсләренә алып, аларны салым түләүдән азат итә алганнар. Ахуннар, шәригатькә каршы килә торган гамәлләр кылган очракта, Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыядә җавап тотканнар. Мәхкәмәи шәргыя аларны рухани дәрәҗәдән вакытлыча яки бөтенләйгә мәхрүм итү турында карар чыгара алган [Указ Именной, 2001, с. 46–47; Мусульманское духовенство, 2006, с. 286–292]. Шулай итеп, без, мөселман дин әһелләренең бер категориясе буларак, «ахун» терминының документларда шактый иртә очравын күрәбез. Ахуннар XVI гасырда ук булганнар. XVII гасырда ахуннар дип мәхкәмә карарлары чыгару һәм дини-хокукый күрсәтмәләр бастыру хокукы булган баш дин әһелләрен атыйлар. XVIII гасырда, күрәсең, бу термин югары дини хакимияткә ия булган затны аңлаткан, өстәвенә, ул төбәк мөселманнарының дөньяви идарәсе белән тыгыз бәйләнгән булган. Шуңа күрә XVIII гасыр дәвамында мөселман халкы арасында зур абруй казанган Себер морзалары Колмәмәтовлар нәселе вәкилләренең шушы вазифада булуы очраклы хәл түгел. Мөгаен, мондый хәл Екатерина II нең 1788 елгы Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя оештыру турында указына кадәр дәвам иткәндер. Ул Россия империясе мөселман җәмәгатьчелеген оештыруда элеккеге системаны тамырдан үзгәртә. Гомумән алганда, шуны әйтергә кирәк: Көнбатыш Себердәге ислам институтлары турындагы мәсьәлә алга таба да өйрәнүне таләп итә.

**Әдәбият**

Акты исторические, собранные и изданные Археографическою комиссией (АИ). СПб.: Тип. Экспедиции заготовления гос. бумаг, 1841. Т. 2. 472 с.

*Андриевич В.К.* История Сибири. СПб.: тип. и лит. В.В. Комарова, 1889. Ч. 2. 487 с.

*Бахрушин С.В.* Сибирские служилые татары в XVII в. // Бахрушин С.В. Научные труды. М.: Изд-во Акад. наук СССР, 1955. Т. III: Избранные работы по истории Сибири XVI–XVII вв., ч. 2: История народов Сибири в XVI–XVII вв. С. 153–175.

*Бустанов А.К.* Фамильная хроника сибирских сайидов. Шаджара Рисаласи (текст, перевод, комментарии) // Ислам в современном мире. 2009. № 1–2 (13–14). С. 45–61.

*Бустанов А.К.* Ранняя версия сочинения об исламизации Сибири // «Сулеймановские чтения»: материалы XII Всерос. науч.-практ. конф. с междунар. участием. Тобольск: Тобольск. гос. пед. ин-т им. Д.И. Менделеева, 2009. С. 159.

*Бустанов А.К.* Манускрипты суфийских шайхов: туркестанская традиция на берегах Иртыша // Этнографо-археологические комплексы: проблемы культуры и социума. Омск: Наука, 2009. Т. 11. С. 195–229.

*Бустанов А.К.* Суфийские легенды об исламизации Сибири // Тюркологический сборник. 2009–2010. Тюркские народы Евразии в древности и средневековье. М.: Вост. лит., 2011. С. 33–78.

*Бустанов А.К.* Книжная культура сибирских мусульман. М.: Марджани, 2013. 264 с.

*Валеев Ф.Т.* Сибирские татары. Культура и быт. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. 208 с.

*Головнев А.В.* Говорящие культуры: традиции самодийцев и угров. Екатеринбург: УрО РАН, 1995. 606 с.

Государственный архив Пермского края (ГАПК). Ф. 314. Оп. 1. Д. 109.

Государственное бюджетное учреждение Тюменской области Государственный архив в г. Тобольске (ГБУТО «ГА в Тобольске»). Ф. 156. Оп. 2. Д. 265.

*Катанов Н.Ф.* Предания тобольских татар о прибытии в 1572 году мухаммеданских проповедников в г. Искер // Ежегодник Тобольского губернского музея. Вып.8. Тобольск, 1897.

*Катанов Н.Ф.* О религиозных войнах учеников шейха Багауддина против инородцев Западной Сибири (по рукописям Тобольского губернского музея). Казань: Изд-во Казан. гос. ун-та, 1904. 28 с.

*Клюева В.П.* К вопросу о деятельности Следственной о татарах и бухарцах комиссии (сер. XVIII в.) // Тюркские народы: материалы V Сибирского симпозиума «Культурное наследие народов Западной Сибири». Тобольск; Омск, 2002. С. 186–188.

*Маслюженко Д.Н.* Деятельность суфийских орденов на территории Тюменского и Сибирского ханств // Вестник Томского государственного университета. История. 2015. № 2 (34). С. 5–9.

*Маслюженко Д.Н.* Процесс исламизации населения юга Западной Сибири в XIII–XVI вв. // Золотоордынское обозрение. 2019. Т. 7, № 1. С. 131–158.

*Миллер Г.Ф.* Сибирь XVIII в. в путевых описаниях // История Сибири. Первоисточники. Новосибирск: Сиб. хронограф, 1996. Вып. 6. 310 с.

*Миллер Г.Ф.* История Сибири. 2-е изд. М.: Вост. лит., 1999. Т. 1. 630 с.

Мусульманское духовенство // Ислам на территории бывшей Российской империи: энцикл. словарь. М., 2006. Т. I. С. 286–292.

*Исхаков Д.М.* Сеиды в позднезолотоордынских татарских государствах. Казань: Татар. кн. изд-во, 1997. 78 с.

*Исхаков Д.М.* Институт сейийдов в Улусе Джучи и позднезолотоордынских тюрко-татарских государствах. Казань: Фэн, 2011. 228 с.

*Исхаков Д.М., Измайлов И.Л.* Этнополитическая история татар (III – середина XVI вв.). Казань: Школа, 2007. 356 с.

*Огрызко И.И.* Христианизация народов Тобольского Севера в XVIII в. Л.: Учпедгиз, Ленингр. отд-ние, 1941. 148 с.

*Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. СПб., 1872. Ч. IV: Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар. 411 с.

Рукописный отдел Тобольского историко-архитектурного музея-заповедника (РО ТИАМЗ). Д. № 12864.

*Селезнев А.Г., Селезнева И.А.* Сибирский ислам: региональный вариант религиозного синкретизма. Новосибирск: Изд-во Ин-та археологии и этнографии СО РАН, 2004. 72 с.

*Селезнев А.Г., Селезнева И.А., Белич И.В.* Культ святых в сибирском исламе: специфика универсального. М.: Марджани, 2009. 216 с.

*Селезнев А.Г., Селезнева И.А.* Религиозная культура // Тюменское и Сибирское ханства. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. С. 232–255.

*Татауров С.Ф., Корусенко М.А.* История ислама в Западной Сибири: междисциплинарный подход к хронологии и периодизации // Былые годы. 2015. Т. 38, ч. 4. С. 798–807.

*Тычинских З.А.* Служилые татары и их роль в формировании этнической общности служилых татар (XVII–XIX вв.). Казань: Фэн, 2010. 288 с.

Полное собрание русских летописей (ПСРЛ). М., 1987. Т. 36: Сибирские летописи, ч. 1: Группа Есиповской летописи. 384 с.

Указ Именной, данный Генерал-Поручику Каменскому 28 января 1783 г. – О дозволении подданным Магометанского закона избирать сами у себя ахунов // Ислам в Российской империи (законодательные акты, описания, статистика). М., 2001. С. 46–47.

*Усманов М.А., Шайхиев Р.А.* Образцы татарских народно-краеведческих сочинений по истории Западной и Южной Сибири // Сибирская археография и источниковедение. Новосибирск: Наука, 1979. С. 85–103.

*Щеглов И.В.* Хронологический перечень важнейших данных из истории Сибири (1032–1882 гг.). Иркутск: Вост.-Сиб. отдел ИРГО, 1883. 779 с.

*Юшков И.Н.* Сибирские татары // Тобольские губернские ведомости. Тобольск, 1861. № 35–45.

*DeWeese D.* Islamization and Native Religion in the Golden Horde: Baba Tukles and Conversion to Islam in Historical and Epic Tradition. Pennsylvania University Press, 1994. 638 p.

*DeWeese D.* The Descendants of Sayyid Ata and the Rank of Naqib in Central Asia // Journal of the American Oriental Society. 1995. Vol. 115, № 4. P. 619–634.

***Тычинских Зәйтүнә Әптрәшит кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, Россия Фәннәр академиясе Урал бүлегенең*
*Тубыл комплекслы фәнни станциясе өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 792.09

***Е.Н. Шевченко***

# ШИЛЛЕРНЫҢ «ЮЛБАСАРЛАР»Ы ТАТАР СӘХНӘСЕНДӘ

Статья посвящена истории постановок драмы выдающегося немецкого драматурга Фридриха Шиллера «Разбойники» на татарской сцене. Целью исследования является выявление причин интереса татарского театра к драматургии Шиллера на разных этапах его развития, анализ различных подходов и режиссёрских интерпретаций пьесы. Сделанные в ходе исследования наблюдения выводят на важную теоретическую проблему взаимодействия различных культурных традиций, а его практические результаты могут быть использованы в деле дальнейшего освоения татарским театром наследия классиков мировой драматургии и современной зарубежной пьесы.

**Ключевые слова:** немецкая драматургия, Фридрих Шиллер, пьеса «Разбойники», татарский театр, сценическая интерпретация, взаимодействие традиций.

This article is devoted to the history of productions of the drama of the outstanding German playwright Friedrich Schiller «Robbers» on the Tatar stage. The purpose of the study is to identify the reasons for the Tatar theatre's interest in Schiller's dramaturgy in different periods of its development, to analyze various approaches and director's interpretations of the play. The observations made in the course of the study lead to an important theoretical problem of the interaction of various cultural traditions, and its practical results can be used in the further development of the heritage of the classics of world drama and modern foreign dramaturgy by the Tatar theatre.

**Keywords:** German dramaturgy, Friedrich Schiller, the play «Robbers», Tatar theater, stage interpretation, interaction of traditions.

Татар театры оешуының беренче елларыннан ук дөнья драматургиясе классиклары Шиллер, Мольер, Шекспир, Лопе де Вега һ.б.ның әсәрләрен үз репертуарына ала. Татар театрының чит ил драматургиясе белән үзара арадашлыгы, эстетик аерымлыклар булуга карамастан, һәрвакыт шома гына бармаса да, дөнья классикасына мөрәҗәгать итү аның үсешендә мөһим роль уйный. Татар театры тарихын өйрәнүче күп кенә галимнәр әлеге фактны һәрвакыт ассызыклый [Иялова, 2016; Салихова, 2016]. Көнбатыш драматургларының пьесалары буенча куелган спектакльләр җитди режиссерлык һәм актерлык осталыгы мәктәбенә әверелә һәм сәхнә культурасы дәрәҗәсен күтәрергә ярдәм итә. Немец драматургиясенә килгәндә, татар тамашачысы Фридрих Шиллер әсәрләрен аеруча яратып карый, ә аның «Юлбасарлар» драмасы йөз ел дәвамында күп тапкырлар татар театры репертуарына кертелә.

Революциягә кадәрге чорда Шиллер драматургиясе Россиядә аеруча популяр була. Шиллер һич арттырусыз уй-фикерләр хакименә,

Россия сәхнәсендә иң соралган чит ил классикларының берсенә әйләнә. Совет чорында да Россия театрлары һәм СССР составындагы милли республикалар театрлары аның әсәрләре белән кызыксынудан туктамый. Алар «Юлбасарлар» һәм «Мәкер һәм мәхәббәт» драмаларына еш мөрәҗәгать итә.

Шиллер пьесалары «Сәйяр», «Нур» һәм «Ширкәт» кебек революциягә кадәрге татар труппаларында ук куела. 1913 елның 29 мартында «Сәйяр» труппасы «Мәкер һәм мәхәббәт» спектаклен сәхнәдә уйный. Бу вакыйга – татар театрының немец драматургы мирасына иң беренче мөрәҗәгате буларак тарихка керә. Соңрак әлеге пьеса берничә тапкыр татар театры афишасында урын ала һәм шушы театрда алты тапкыр төрле интерпретацияләрдә барган «Юлбасарлар» драмасы белән популярлыкта ярыша. Вакытлы матбугатта әлеге постановкалар турында дөнья күргән мәкаләләр генә түгел, ә сакланып калган афиша һәм плакатлар да кыйммәтле чыганак булып тора [Султанова, 2017].

«Юлбасарлар» пьесасы дөнья театры тарихында аерым урын тота. Шиллерның беренче идеалист герое – корал көче белән гаделлек урнаштыру өчен юлбасарлар отряды башлыгы булган Карл Моорның фаҗигалы тарихы тамашачыларда иҗтимагый гаделсезлеккә карата ачу хисе тудыра. Социаль-тарихи катаклизмнар вакытында театр «Юлбасарлар»га тагын да ешрак мөрәҗәгать итә. Октябрь революциясе һәм Гражданнар сугышы елларында Ф. Шиллер драматургиясе белән кызыксыну яңа баскычка күтәрелә. Һәм бу бер дә гаҗәп түгел. Ә революцион идеяләр белән аваздаш «Юлбасарлар» бу чорның репертуарга иң күп кертелгән әсәрләреннән санала. Пьеса рус, татар, азәрбайҗан, украин, грузин театрларында бара, һәр фронт бригадасының диярлек репертуарында була [Иляслова, 1985].

Революциядән соң татар театрында идеологик факторларның йогынтысы көчәя, реалистик позицияләр ныгый. Г. Арсланов фикеренчә, искене җимереп, яңаны үзләштергәннән соң, татар театрының жанр кысалары да киңәеп китә, яңа жанр – героик-революцион драма барлыкка килә. Режиссерларның «чик жанрлар»га – трагедия, романтик драма, сатирик комедияләргә мөрәҗәгать итү очраклары ешая [Арсланов, 2004, с. 30]. Мондый вазгыятьтә Фридрих Шиллер драматургиясе белән кызыксынуның көчәюе бер дә гаҗәп түгел. Режиссер Мөхтәр Мутин Татар драма артистлары труппасында «Юлбасарлар» (1918) пьесасын куя, алга таба да ул аңа тагын ике тапкыр – 1920 һәм 1925 елларда мөрәҗәгать итә. Мутиннан соң «Юлбасарлар» Казанда татар сәхнәсендә тагын өч тапкыр куела: 1927 елда (режиссеры Р. Ишморатов, рәссамы П. Беньков), 1934 елда (режиссерлары С. Булатов, В. Чиркин, рәссамы П. Сперанский) һәм 1997 елда (режиссеры В. Ярюхин, рәссамы С. Скоморохов). Әстерхан һәм Оренбургтагы татар труппалары да «Юлбасарлар»га мөрәҗәгать итәләр [Татар совет театры, 1975, б. 427, 472, 475].

Яхшы режиссер, революциягә кадәрге милли сәхнә сәнгатенең күренекле эшлеклесе, атаклы артист, актив җәмәгать эшлеклесе

булган М. Мутин революциядән соң татар театрында иң зур фигураларның берсенә әверелә. «Мутин первым из татарских режиссёров применил принцип революционного переосмысления большой классики. Именно поэтому его спектакли, поставленные по классическим образцам драматургии, нужны были тогда, ибо отвечали «нужде в героическом» у зрителя, совершающего небывалые перемены в общественной жизни страны. <…> Мутин принёс в татарский театр революционный пафос, романтическую окрылённость, высокую патетику своего искусства», – дип яза Г. Арсланов [Арсланов, 1992, с. 31]. Шиллер пьесалары аның шәрехләвендә болгавыр заман рухын чагылдыра, режиссер аларда үзен җәлеп иткән героик характерларны таба. Әлбәттә, ул бунтарь, ирек һәм гаделлек өчен золымлыкка каршы көрәшүче Карл Моор образын калкуландыра, аны спектакльнең мәгънәви һәм эмоциональ үзәге итә, башка персонажларның әһәмиятен «хор партиясе»нә кайтарып калдыра. «На сцене главенствовал “царь и бог” – Карл Моор – М. Мутин. А все остальные вокруг него были лишь более или менее необходимыми частицами целого, помогающими раскрыть мятежный, бунтарский дух главаря разбойников» [Арсланов, 1992, с. 85]. Мондый концепция драманың идея сурәтен төзәйтеп җибәрсә дә, барысы да Мутинның гаҗәеп уены белән аклана: «Психологически насыщенный, в то же время романтически приподнятый образ Карла, являющийся центром, скрепляющим ядром постановки, потрясал зрителей бурным, взрывчатым темпераментом, страстностью, силой чувств, буйством характера. В своеобразной стилистике спектакля сливался воедино реализм и романтика, интеллект создателя спектакля и его эмоциональная мощь» [шунда ук]. Мутин баш геройның фаҗигасын тирәнтен ачуга ирешә. Беренче чиратта, аның уены аша спектакль тамашачылар арасында гаять зур уңыш казана һәм кискен театр тәнкыйтенә дучар булмый.

1926/27 еллар сезонында режиссер Риза Ишморатов Шиллерның «Юлбасарлар»ын тагын сәхнәгә куя, әмма Мутиннан аермалы буларак, спектакль татар театры өчен традицион стильдә булып, тормыш чынбарлыгын дөрес чагылдыру законнарына буйсындырыла [Арсланов, 2004, с. 38].

30 нчы еллар башында Татар дәүләт академия театрына Сәет Булатов килә. Яшь режиссер рус һәм чит ил классикасы белән яхшы таныш була. Аның спектакльләр кую эшчәнлегендә татар режиссурасының 20 нче еллар башында Мутин иҗатында көчле чагылыш тапкан романтик традицияләре яңадан торгызыла [Арсланов, 1992, с. 43].

1934 елның мартында С. Булатов һәм читтән чакырылган режиссер В. Чиркин бергәләп эшләгән «Юлбасарлар» спектакленең премьерасы була. Шиллер пьесасында конфликт күбрәк әхлакый ясылыкны колачлый. С. Булатов һәм В. Чиркин өчен әлеге фаҗиганың социаль тамырларын ачу мөһим: «По их мнению, в эпоху дифференциации классовых сил, когда феодализм пошатнулся, а буржуазия еще не обрела власть, изображённые в пьесе события не могут быть

оценены лишь с позиций добра и зла. В данной ситуации весьма важно учесть социальную природу явлений» [Арсланов, 1992, с. 236]. Әлеге мәсьәләне хәл итү өчен, текст яңадан сүтеп җыела, Шиллерның башка әсәрләреннән дә өзекләр кертелә. П. Сперанскийның Урта гасырлар архитектурасының авыр монументаль формаларын торгызган сценографиясе дә, композитор Хаэт музыкасы да шушы режиссурага хезмәт итә. Әмма социаль яңгырашка, барыннан да элек, образларны ачу хисабына ирешелә: «В понимании режиссёров и актёра Ш. Шамильского, Франц – наиболее яркий экземпляр последних, предчувствующих свою близкую кончину феодалов. <…> В.Чиркин и С. Булатов, вместе с ними и актёр М. Мутин Карла Моора трактовали как трагический образ, как одиночку-ренегата своего аристократического сословия. Карл – М. Мутин в силу своей внутренней противоречивости оказался между двумя классами – буржуазией и феодалами. Отсюда безысходность, трагичность его положения» [Чиркин, Булатов, 1934].

Алга таба театр немец драматургының әлеге пьесасына 1997 елда гына, сәхнәгә Шиллерның «Юлбасарлар»ы шагыйрь Зөлфәт (Дөлфәт Госман улы Маликов) тәрҗемәсендә кайткач мөрәҗәгать итә. Баш режиссер Марсель Сәлимҗанов чакыруы буенча, спектакль өстендә режиссер Валентин Ярюхин (Анатолий Васильевның укучысы) эшли. Р. Игъламов Шиллер драмасының соңгы куелышын чиста һәм кызыклы дип саный. Тикшеренүче билгеләп үткәнчә, спектакльдә затлы юлбасарлык, башка сүзләр белән әйткәндә, социаль протест, революцион хәрәкәт эволюциясе ачык чагыла; биредә гадел көрәш кан кою белән тәмамлана һәм, әйтергә кирәк, гаепсезләрнең дә каны коела [Игламов, 2007, с. 73]. Р. Игламов бу күренештә куелышның иң көчле ягын күрә, ул дөньяны яңадан бүлүгә заманча карашка туры килә.

А. Салихова фикеренчә, бу спектакль театрның иҗади үсеше һәм эстетик эзләнүләре яктылыгында аеруча игътибарга лаек [ТГАТ им. Г. Камала, 2009, с. 115]. А. Салихова куелышның үзенчәлеген кече сәхнәнең уңай мөмкинлекләре белән бәйли, ул, бер яктан, спектакльнең аз санлы тамашачыга адреслануын тәэмин итсә, икенче яктан, кыю иҗади тәҗрибә өчен шартлар тудыра. Сәхнәдә «читлек» – буйбуй һәм аркылы балкалардан торган (кирәк булганда алар баскыч ролен дә үти), колосникларга китүче җиңел күппочмаклы металл конструкция корылган (рәссамы С. Скоморохов). Агач ябалдашлары астында эзәрлекләүчеләрдән яшеренгән кебек, юлбасарлар алар буенча югарыга үрмәлиләр, финалда Карл алар буйлап үз язмышына каршы күтәрелә. «Читлек» ябыла һәм ачыла, түгәрәк сәхнә белән бергә әйләнеп, я комлыкка (анда балалар – Карл, Франц һәм Амалия уйный), я Моорлар замогындагы бүлмәгә, я юлбасарлар оясына, я төрбәгә әверелә. Соңгысында Францның ихтыяры белән карт граф фон Моор тилмерә. Әлеге күпфункцияле конструкция уен мәйданын зурайтырга мөмкинлек бирә. Р. Игъламов анда ябык бунт, Карлның һәм аның иптәшләренең рухи әсирлеге символын күрә [Игламов, 2007, с. 73].

А. Салихова сценографиянең шартлы һәм кыска булуы классик пьесага заманча яңгыраш бирә дип саный [ТГАТ им. Г. Камала, 2009, с. 115]. Спектакль сценографиясенең әлеге үзенчәлеген журналист О. Стрельникова да билгеләп үтә. Аның фикеренчә, рәссам С. Скоморохов конкрет урын һәм вакыт белән бәйле тормыш-көнкүреш нечкәлекләреннән китә [шунда ук, б. 118]. О. Стрельникова Камал театры версиясендәге абыйлы-энеле ике туган тарихын акыллы һәм матур уйналган шахмат партиясе белән чагыштыра, анда уенга акрынлап барлык фигуралар да җәлеп ителә. В. Ярюхин эшләгән сәхнә интерпретациясенең асылын А. Салихова Ф. Достоевский белән яшерен әңгәмәдә күрә: «…спектакль на первый план выдвигает проблему “преступления и наказания”, и решена она совсем по Достоевскому» [шунда ук, б. 115]. Тәнкыйтьче Франц Моорны (Искәндәр Хәйруллин) Раскольников белән чагыштыра: үзенең файда алуны күздә тоткан гамәлләрен идеологик нигезләргә тырышып, ул даими фәлсәфә кора, шул ук вакытта Карл Моорның (Рамил Төхфәтуллин) төп темасы – кешенең әхлакый сайланыш өчен җаваплы булуы. Шул ук вакытта тәнкыйтьче бунтарь-идеалист Карл Моор образының спектакльдә түбәнсетелүен һәм гадиләштерелүен билгеләп үтә, нәтиҗәдә Франц Моор белән чагыштырганда ул оттыра, һәм ике туганның каршы торуы тиешле югарылыкта бирелми. Юлбасарлар башлыгы образы турында шуңа охшаш фикерне О. Стрельникова да әйтә. Р. Төхфәтуллин героеның үз-үзен тикшерүче интеллигент белән бернинди уртаклыгы булмавын билгеләп, ә совет театрында ул еш кына шундый итеп күрсәтелә дә, ул болай ди: «…ему, конечно, хватит силы воли взять на себя ответственность и понести заслуженную кару за содеянное. Но если под покаянием понимать нечто большее, духовное усилие, то этот Карл, в лучшем случае, только на пути к нему…» [шунда ук, б. 118]. Нәтиҗәдә басым көчлерәк Франц образы ягына күчә. Ул табигать тарафыннан рәнҗетелгән, ата һәм хатын-кыз мәхәббәтеннән мәхрүм, шуңа күрә акрынлап явызлык һәм үчле кансызлык гәүдәләнешенә әверелә. Спектакльнең геройларның балачагыннан башланып китүе дә очраклы түгел: олы яшьтәге Франц тамашачыга аркасы белән утырып, комлыкта уйнаучы малай белән кызны күзәтә. Бу Карл һәм Амалия. Инде шул вакытта ук Амалия аның абыйсын өстен күргән, шул вакытта ук явызлык һәм нәфрәт туган, һәм вакытлар узу белән, алар Францның асылын билэп алган. Искәндәр Хәйруллин үзенең нервлы, темпераментлы уены белән рольнең гаҗәеп нәфис һәм тәфсилле психологик сурәтен тудырган, явызның җанында дулаган җәһәннәмне ачып салган. Францның финалдагы монологы – спектакльнең иң көчле мизгеледер, мөгаен. Әмма бу – кешенең яхшы сыйфатлары күпмедер дәрәҗәдә кимчелеккә әйләнгән очрак. Р. Игъламов та шуңа ишарәли. Ул билгеләп үткәнчә, мәкерле Францның явызлыгы белән бәйле вакыйгалар чиктән тыш детальләштерелгән булып чыга һәм спектакльнең мәгънәви ориентирларын үзгәртә: «Тем более что здесь (парадокс) блестящее исполнение роли Франца

в реалистическом ключе, то есть со всеми психологическими мотивировками, талантливым молодым Хайруллиным, оказалось для постановки излишним» [Игламов, 2007, с. 73].

Режиссер Валентин Ярюхин, артистлар белән эшләвен искә төшереп, алардагы хас эмоцияләрнең хәрәкәтчәнлеген, дәрт һәм һәвәслеккне ассызыклый, спектакльдә яшьлек энергиясе хөкем сөрә иде, ди. Алар белән сәхнәдә үзенең көче, тамашалылыгы, һәртөрле куелыш трюклары һәм сәнгатьле чараларга байлыгы белән аерылып торган иң кыю алымнарын да гамәлгә ашыру җиңел булды, ди.

Билгеле булганча, пьесаның финалында Карл Моор хакимияткә бирелергә бара, шул ук вакытта ул үзен унбер кешене ашатучы фәкыйрь кулына тапшыра. Моны ул мәшһүр юлбасарны тоткан өчен вәгъдә ителгән мең луидорны әлеге фәкыйрь алсын өчен эшли. Спектакльдә Карл баскычтан кечкенә малай (үзенең бала вакыты) белән бергә өскә күтәрелә. Ахырда Шиллерда булмаган фразалар яңгырый. Бала: «Мин куркам», – ди. Карл: «Аска карама!» – дип җавап бирә. Күккә юнәлгән вектор – тәүбә итү, кичерелү һәм ярлыкану символы.

Спектакльдә яктылык партитурасы мөһим роль уйный. Яктылык һәм күләгә уенына корылган кайбер күренешләрнең аклы-каралы чишелеше дә бик уңышлы: тереләй күмелгән граф фон Моорның кешегә ошаган коточкыч сурәте; Францның Амалияне мыскыл итү күренеше һ.б. Сәхнәнең төрле сегментларында, якынлашып килүче һәлакәт, ут һәм кан коелу билгесе буларак, әледән-әле кабатланып торган кызыл ут балкышы да символик мәгънәгә ия.

В. Ярюхин тарафыннан куелган музыкаль бизәлеш тә уңышлы. Спектакльдә Берлин электрон музыка мәктәбе әсәрләре файдаланылган, алар үзенчәлекле атмосфера тудыруга хезмәт итә.

Спектакльнең концептуаль үзенчәлеге булган шартлылык костюмнарда да күренә (костюмнар буенча рәссам – Людмила Листовская). Аларның кайберләре генә тарихи характерда булып, күбесе стильләштерелгән, ә кайчакта урын һәм вакыт таләпләренә бөтенләй буйсынмыйлар. Әйтик, Карлның дуслары – азгын яшьләр сәхнәгә, карате алымнарын күрсәтеп, ак кимонодан килеп чыгалар (көрәшләрне Николай Фролов куйган). Соңрак, юлбасарларга әйләнгәч, алар каратэчылар кимоносын камуфляж киемгә алыштырачак. Беренче чечен сугышының 1996 елда (спектакльнең куелышына бер ел кала) тәмамлануын искә алсак, тамашачылар аңында нинди ассоциацияләр туачагы шактый ачык тоемлана. В. Ярюхин постановкасының тагын бер мөһим үзенчәлеге – хәзерге заманга ишарәләү.

Р. Игъламов Ярюхин версиясендә тере режиссерлык фикеренең ачык мисалын күрде [Игламов, 2007, с. 72–73]. Кызганыч ки, берничә сәбәп аркасында, спектакль озак бармады. Әмма ул Камал театрында Шиллер драматургиясен үзләштерүнең истә калырлык сәхифәсенә әверелде һәм бүгенге көнгә кадәр бу сәхнәдә аңа соңгы мәртәбә мөрәҗәгать итү булып кала бирә.

В. Ярюхинның «Юлбасарлар»ы «Мировая классика на провинциальной сцене…» монографиясе авторлары фикеренең дөреслеген раслый: «…вплоть до последней трети XX века провинциальная сцена не знала такого разнообразия интерпретаций, стилистических подходов и экспериментов, которые захлестнули казанскую сцену на рубеже XX–XXI веков. Оказалось, что даже достаточно традиционные татарские театры не только не остались в стороне, но в чём-то даже опередили русские театры в смелости и яркости трактовок классических пьес» [Мировая классика на провинциальной сцене, 2018, с. 5].

Табигый ки, татар театрлары, беренче чиратта, милли драматургиягә юнәлеш тота. Мәсәлән, республиканың әйдәп баручы театры саналган Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры тарихында аның репертуарының 8 % ы гына чит ил классикасына туры килә. Шул ук вакытта спектакльләрнең дүрттән бер өлеше немец авторларының пьесалары буенча куелган, аларның иң зур күпчелеге – 16 ның 11 е – Фридрих Шиллер драмалары буенча. Шулай итеп, Камал театрында Шиллер популярлык һәм еш мөрәҗәгать итү буенча Мольер, Гольдони, Лопе де Вега һәм дөнья драматургиясенең башка корифейларын артта калдырып, бары Шекспирга гына оттырды. Шуның белән бергә, әйткәнебезчә, татар театрын Шиллерның ике генә драмасы – «Юлбасарлар» һәм «Мәкер һәм мәхәббәт» кенә кызыксындыра. Күргәнебезчә, Шиллер драматургиясе белән кызыксынуның иң югары ноктасы революциядән соңгы беренче дистә елларга туры килә, «Юлбасарлар» һәм «Мәкер һәм мәхәббәт» татар сәхнәсендә һәр ике-өч ел саен диярлек куела. Немец драматургы пьесаларында яңгыраган социаль гаделлек өчен көрәш идеясенә бу вакытта совет җәмгыятендә ихтыяҗ зур була, һәм бу милли театр репертуарында да чагылыш таба. Моннан тыш, Шиллер пьесаларының һәрвакыт фаҗигалы чишелешкә китергән лирик, мәхәббәт линиясе татар театрына хас мелодраматизмга бик якын булып чыга.

Шиллерның «Юлбасарлар» пьесасы буенча куелган кайбер спектакльләрдә иҗатчыларны революция һәм социаль көрәш идеяләре кызыксындырды, башкаларында изгелек һәм яманлык көрәшенә, гомумкешелек кыйммәтләренә басым ясалды. Шиллер пьесасы буенча куелган спектакльләр һәрдаим әһәмиятле вакыйгага әверелми, әмма немец драматургының иҗаты белән кызыксыну кала бирә. Гәрчә Шиллерның «Юлбасарлар»ы еш кына кыскартуларга дучар ителеп, милли сәхнә мөмкинлекләренә һәм ихтыяҗларына яраклаштырылса да, татар театры репертуарының мөһим өлешен тәшкил итә, аның сәнгать палитрасын баетып, бөтендөнья театраль процессына кереп китүенә булыша.

**Әдәбият**

*Арсланов Г.* Режиссёр Ширъяздан Сарымсаков: Монография. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 222 с.

*Арсланов М.Г.* Татарское режиссёрское искусство (1906–1941). Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. 336 с.; с ил.

*Игламов Р.М.* Испытание временем. Казань: Отечество, 2007. 260 с.

*Илялова И.* Межнациональные связи татарского театра. Казань: АН СССР, Казанский филиал, ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова; Татар. кн. изд-во, 1985. 240 с.

*Илялова И.* Современное звучание мировой классики на татарской сцене // Tatarica. 2016. № 1 (6). С. 137–162.

Мировая классика на провинциальной сцене: русские и татарские театры Казани за два столетия / О.О. Несмелова, В.Б. Шамина, Е.Н. Шевченко и др. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. 178 с.

*Салихова А.Р.* Особенности формирования и развития татарского сценического искусства. Казань: ИЯЛИ, 2016. 360 с.

*Султанова Р.Р.* История татарского театра в плакатном искусстве. Казань, 2017. 352 с.; 320 ил.

Татарский государственный академический театр имени Галиасгара Камала. Сто лет: в двух томах. Т. 1: Спектакли. Казань: Заман-Татар. кн. изд-во, 2009. 568 с.: ил.

Татар совет театры: (Очерклар). Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 496 б., 32 б. ил.

*Чиркин В., Булатов С.* «Разбойники» Ф. Шиллера в Татарском академическом театре // Красная Татария. 1934. 24 марта.

***Шевченко Елена Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 165.9

***Д.С. Булатова***

# «МИФ», «ЭПОС», «ТАРИХ» ТӨШЕНЧӘЛӘРЕНЕҢ ҮЗАРА БӘЙЛӘНЕШЕ ТУРЫНДА

В статье автор рассуждает о соотношении понятий «миф», «эпос», «история», определяет особенности и культурно-историческую значимость эпического наследия татар в современном мире. Для проведения исследования использованы материалы современных авторов, соответствующие заявленной тематике. В поисках ответов на сущностные вопросы бытия современного человека автор возвращается к «детству» культуры народа, в частности, к её этнокорням. Благодаря многовековому формированию научной картины мира, Логосу современного исторического знания, современный человек способен мыслить окружающий мир как многомерный континуум, где прошлое влияет на настоящее, а настоящее содержит перспективы будущего развития. В статье утверждается, что к этому готовит не только наука, но и миф, и эпос как самые ранние формы образного мышления в истории человечества. Демонстрируется их участие, в качестве «рудиментов» сознания, в становлении мировосприятия любого человека от его младенчества до зрелости.

**Ключевые слова:** психоанализ, эпическое творчество, соотношение понятий, миф, эпос, история.

In the article, the author discusses the relationship between the concepts of «myth», «epic», «history», defines the features and cultural and historical significance of the epic heritage of the Tatars in the modern world. Materials of modern authors corresponding to the stated topic were used to conduct the study. In search of answers to the most important questions of modern man’s life, the author returns to the «childhood» of folk culture, especially to its ethnocorns. Due to the centuries-old formation of the scientific picture of the world, the logic of modern historical knowledge, modern man is able to think of the surrounding world as a multidimensional continuity in which the past influences the present, and the present includes development prospects. The article claims that by this time not only science, but also myths and epics were prepared as the oldest forms of imaginative thinking in the history of mankind. As their «rudiments» of consciousness, the participation of a loving person in the formation of a worldview from infancy to adulthood is indicated.

**Keywords:** psychoanalysis, epic creativity, correlation of concepts, myth, epic, history.

Психоанализ «тарихи мәктәбе» [Фрейд, 2021, с. 186–197; Фрейд, 2013] индивидуаль аң генезисы һәм кешелекнең мәдәни тарихы этаплары арасында охшашлыклар таба һәм бу юкка гына түгел. Хәзерге заман образлы аң генезисы теориясе миф – эпос – тарихны аның тарихи барлыкка килү этаплары буларак карарга мөмкинлек бирә. Ә әлеге образлы фикерләү формаларының һәркайсы – каршылыклы өлешләрнең диалектик берлеге, бу берлек күптөрле фәлсәфи

категорияләрдән тора – бердәнбер һәм гомуми, субъект-объект һәм статик-динамик, архаик-тотрыклы һәм яңарып торучан һ.б. Бүгенге көндә безнең алда торган теоретик-гамәли бурыч – миф, эпос, тарих төшенчәләрен ачыклау, чөнки аларның чикләре вакытлар узу белән «юыла» бара. Еш кына, эпос турында сөйләгәндә – миф, миф дигәндә – «тылсымлы әкият» күз алдында тотыла, ә эпоска миф та, әкият тә, фольклор да, тарих та (stories) керә ала.

Шулай ук сирәк, аерым формаларны анализлаганда, фикерләү, мәдәният үсешенең билгеле бер этапларында миф-эпос-тарих кебек күренешләрнең барлыкка килүендә генетик һәм социаль-психологик сәбәпләрне ачыклау мөһим. Бүген мәдәниятләрнең тарихи яктан төрле типлары һәм, аерым алганда, Пафос – Этос – Логос кебек борынгы грек терминнары арасындагы тәңгәллекләрдән качып булмый. Гомумиләштерелгән күзаллауларга эвристик импульс сыйфатында, филология, фольклор, тарихи белемнәрнең төрле өлкәләрендә белгечләрнең калыплашкан традицион карашларына өстәмә рәвештә әлеге тәңгәллекләргә мөрәҗәгать итү кирәк.

Тарихи яктан чынбарлыкны төшенүнең башлангыч формасы буларак, мифның эпос белән туганлыгы ачыклана. Миф – шул ук хикәят, риваять, ә мифология – аларның җыелмасы. XIX–XX гасырлардан башлап, төрле халыкларның мифлары һәм эпослары интенсив рәвештә өйрәнелә башлагач, фәнни берләшмәдә нәрсәне – эпос, ә нәрсәне миф дип атау турында бәхәсләр юкка гына тумый. Н. Исәнбәтнең профессиональ сизгерлеге һәм инанганлыгы нәтиҗәсендә фәнни берләшмә тарафыннан «Идегәй», оппонентлар раславынча, миф түгел, бәлки татар эпосы дип таныла. Һәм нәкъ менә татар эпосы булганга күрә, ул аның драма әсәренең һәм опера либреттосының («Түләк») нигезенә ята да. Филологлар һәм фольклорчыларның конкрет тикшеренүләре күрсәткәнчә, эпос чыннан да мифологиядән һәм аның нигезендә барлыкка килә [Мухаметзянова, Давлетшина, 2022, с. 3775]. Нәкъ менә мифлар һәм әкиятләр – әле дә аерым халыкларда, шул исәптән төрки телле халыкларда да сакланган архаик формалы эпосның төп нигезе.

Әмма миф һәм эпосның охшашлыкларын билгеләгәндә, үзенчәлекләрне ачыклау кирәк. Беренчесе – миф йомык структуралы, аның башы һәм ахыры «йомылган». Мифта вакыт төшенчәсендә булган дәвамлылык һәм үсеш юк. Анда вакыйгалар «бармый», ә бәлки хәтергә алына, мәңгелеккә теркәп куела, ягъни тотрыклы хәлдә саклана. Алар хәтта вакыйга да түгел, ә геройларның эш-гамәлләре: органик ыру-кабилә берләшмәсенең һәр әгъзасы тарафыннан кичерелү мөһимлеге принцибы буенча бер-берсенә «ялганып», тезелеп баралар.

Иң архаик мифларның берсе булган космогоник мифларда Җир асты, Җир, Җир өсте һәм Күк дөньяларыннан торган күп катламлы яшәү тирәлеге ачыла. Төп герой – кабилә өчен аеруча мөһим табигый объектларның җанлы гәүдәләнеше. Мәсәлән, Урал-елгалар, яки Урал-таулар. Ә Шүлгәнташ башта тау һәм мәгарә булган, тора-бара,

мифологиядәге коткаручы ана кочагы кебек, изге әйбергә әверелгән. Ә инде соңрак этносның шул ук исемдәге төрки телле эпосында төп герой булган. Мифлар героеның портрет сурәте дә булмый, ул индивидуальләштерелмәгән һәм характеры үсеш кичерми. Образ гипербола дәрәҗәсендә гомумиләштерелгән, анда күбрәк физик сыйфатлар өстенлек итә, әйтик, ир-атлык сыйфатлары фантасмагорик зурлыкка җиткерелә. Гильгамешның ир-атлык сыйфатлары яки унөченче каһарманлыгын күрсәткән вакытта Гераклның сыйфатларын моңа мисалга китерергә мөмкин. Мифик герой ул шәхес түгел, әмма гомумиләштерелгән образ – кабиләнең яшәү сәләте өчен аеруча мөһим социомәдәни функцияләрне башкаручы.

Мифның һәм чынбарлыкны мифологик төшенүнең асылы кешенең үзен чолгап алган әйләнә-тирә дөнья белән абсолют бердәйлегендә, алар арасында аңның абстракция яки рефлексия кебек арадаш формалары әле эшләнмәгән. Кешенең дөньяны кичерүе (кабул итүе) һәм объектив чынбарлык арасында аерма юк. Моны әкият героеның бәхетсезлекләрен яки үлемен үз фаҗигасы кебек кичерүче бала күзаллавы белән чагыштырырга мөмкин булыр иде. Шуңа күрә безнең нинди геройлар үрнәгендә үсүебез һәм балаларыбызга нинди геройларны күрсәтүебез бик тә әһәмиятле. Без яраткан мифлар һәм әкиятләр, шулай ук балачак геройлары балаларыбызныкы һәм оныкларыбызныкы белән туры килсә, буыннар арсындагы бәйләнеш өзелмәячәк.

Миф, чыбарлыкны кабул итүнең иң иртә формасы буларак, беркадәр шартлылык белән, борынгы грек төшенчәсе Пафоска аваздаш. Чөнки борынгы грек кешесенең Пафосына аның гүзәл һәм гармонияле Ойкуменадай дөньяны кичерүенең (кабул итүенең) эстетик мәгънәсе дә салынган. Миф, эпос һәм тарих нисбәтендә игътибарны җәлеп итәрдәй икенче момент – мифологик аңның тирән психологик үзенчәлекләргә ия булуында. Нәкъ менә алар чынбарлыкны кабул итүнең нигезен тәшкил итәләр һәм, минем карашка, барлык образлы, шул исәптән сәнгати этник аңның тарихи яктан соңрак барлыкка килгән формалары үсешенең алшартлары булып торалар. Беренче чиратта, эпосның үсеше шушы шартларга бәйле. Соңрак барлыкка килгән формаларның алшартлары буларак, мифның бу үзенчәлекләренә түбәндәгеләр керә: беренчесе – барысын да бәйләү өчен ассоциатив сәләт; икенчесе – персонификацияләү (кешеләштерү) сәләте; өченчесе – персонажның «гомуми, универсаль магик үзгәреш кичерү» принцибы [Лосев, 2021, с. 197–264; Лосев. Очерки античного символизма и мифологии]. Соңгырак этапларда әлеге алшартлардан образлы фикерләүнең тарихи яктан күпкә функциональ билгеләнгән формасы буларак эпос барлыкка килә. Ул – мифологик аңның акрын, ләкин тарихи яктан котылгысыз таркалу этабы күренеше. Сәбәбе – кешенең үз берләшмәсе, шулай ук күпкә киңрәк һәм төрлерәк Ыру-кабилә берләшмәсе эчендәге элемтәләрнең катлаулануы.

Кыйсса-хикәятләр һәм риваятьләр комплексы буларак, эпос этник яктан төрле халыкларда бар һәм төрлечә атап йөртелә: манас, олонхо,

кыйсса, дастан һ.б. Әмма алар барысы бергә этник яктан якын халыклар арасында генетик бәйләнеш булуын раслый, мәсәлән, татарлар эпосы белән башка төрки халыклар эпосы арасындагы охшашлыклар әлеге параллельне уздырырга мөмкинлек бирә. Мифлар кебек үк эпик хикәятләр – принципиаль рәвештә телдән сөйләнә торган форма, һәм өлкән буын аны үзеннән соңгыларга «телдән телгә» сөйләп тапшыра. Ыру-кабилә элитасының, үзенә күрә «аксөякләр»нең үз-үзен тотышы тәҗрибәсен тапшыруны иң мөһим эпик бурыч дип санарга мөмкин: эпоста аларның казанышлары, ыруның һәм яшәргә җайлаштырылган территорияләрнең бөтенлеген саклау буенча героик гамәлләре мактала. Героик мисалларда өйрәтү – эпосның гаять мөһим этик функциясе, ул бигрәк тә татарларда һәм башка төрки халыкларда сакланып калган һәм аларның мифларыннан һәм баһадирлар турындагы әкиятләреннән барлыкка килгән героик эпоска хас. Эпосның героик төрләренең яшәү көче, бәлки, нәкъ менә шундадыр: алар гаять әһәмиятле этник концептларны тапшыру һәм саклау буенча үзләренең этик функцияләрен намус белән үтәгәннәр. Этник-социаль-мәдәни институцияләрне тапшыру һәм саклауда да эпосның роле зур. Гаиләдә һәм җәмгыятьтә үз-үзеңне тоту этик нормалары, атаның ролен күтәрү, ә алга таба – аңа табыну һәм изгеләштерү. Болар барысы да эпосның борынгы халыклар аңында, ягъни этномәдәни бергәлектә коллектив тәртип нигезләре һәм принциплары буларак аңлауда Этос белән охшашлыгы турында сөйли.

Мифтан аермалы буларак, эпоста Пространство һәм Вакыт тоташ, өзлексез (континуаль). Ул өзек, ачык һәм хәрәкәт итә. Бу хәрәкәт «агым»ны хәтерләтә, ә аның башы да, ахыры да юк, ул көйләп бәян итүгә тиң. Халыкларның бөек күчеше чорында татарларның зур территорияләргә таралып утыруы, әйтик, халыкның эпик иҗатының төрлелеген, башка төрки халыклар белән генетик уртаклыкны саклаган хәлдә, аның трансформациясен һәм бер-берләренә йогынтысын билгели [Мухаметзянова, 2014, с. 16–65]. Халыкларның гаять зур киңлекләр буйлап хәрәкәте эпосның принципиаль структур «өзеклеген» тәэмин итә. Һәм аннары, һәр «профессиональ» әкиятче, ул чәчәнме, манасчымы һ.б., эпик хикәятнең эзлеклелеген һәм «рухы»н катгый саклап, вакытлар узу белән барыбер үзенең яңа шартларга аваздаш зур булмаган өстәмә, төзәтмәләрен кертә. Мифтагы автор кебек үк, субъект – аноним, күмәк. Герой – автор кебек үк – Урал батыр, Идегәй, Алпамыштай героик затның гомумиләштерелгән һәм кешеләштерелгән образы. Өстәвенә, эпосның авторы аноним, әмма берләшмәдә әкиятчеләр киң танылганнар һәм аларны хөрмәт иткәннәр. Ә инде язма-китаби дастаннар туу белән аны «башкаручы»ның исемен телгә алу традициясе дә барлыкка килә [Мухаметзянова, 2014, с. 31–50].

Шулай итеп, эпоста Этосның, Пафос белән беррәттән, характерлы көчәюе эпик хикәяләүнең функциональлеге белән аңлатыла. Вакыйгаларның «объектив» эзлеклелеген саклау белән бергә, бу

вакыйгалар тыңлаучыларда көчле эмоциональ реакция тудырырга тиешлеген дә онытмыйк. Анысы да бик мөһим. Моннан, башкаруның ассызыкланган энергетикасы, аерым ритмлаштыру, кабатлаулар, тавыш модуляцияләре (карлыккан тавышлы баслардан башлап бик югары тавыш белән кычкырып җибәрүгә кадәр), чамалап кына «трансагентлы» кулларны селтәү, эффектлы идеологемалар, сүз формулалары, әфсеннәр куллану. Мондый төрдәге «тере сөйләм» тыңлаучыларның төрле катлауларына һәм шул исәптән аңның эчке реакцияләренә юнәлдерелгән. Тере эпик сөйләмнең бурычы, бер яктан, – илһамландыру, берләштерү, рухи һәм эмоциональ яктан былина көче белән баету, ә икенче яктан, – тотрыксыз психика белән магик «манипуляцияләр» ясау, авыр контрольдә тотыла торган инстинктларны, эчке реакцияләрне яңадан кузгату һ.б.

Каһарман ата-бабаларыбызның батырлыгы белән таныштыру этик функциясе тарихи яктан акланган һәм кабилә-ыру берлекләре эчендә зур этнослар оешу шартларында, территорияләр өчен туктаусыз сугышлар барганда аеруча әһәмиятле. Эпик дөньяга караш – зур территорияләр буйлап туктаусыз күченеп йөргән урдаларның Пространство һәм Вакытта «ачык» яшәеше. Эпоста әлеге бергәлек аша үзбилгеләнүче һәм еш кына башка, «чит» бергәлекләр белән сугышучы ыруг кешесенең катнашуы һәм урнашуы теркәлә. Моннан акрынлап халык булып оешкан ыруның эпик иҗатында теркәлгән әлеге бергәлекне туплый торган кыйммәтләр, үз-үзеңне тоту маркерлары һәм мөнәсәбәт үрнәкләренең әһәмияте арта баруы аңлашыла.

Тарих исә – борынгы грек Логосына туры килә торган күренеш һәм хәзерге формалардагы тарихи фикерләүнең формалашу һәм бизәлешенең шактый соңгы этабы. Тарихи яктан соңрак барлыкка килгән күренеш буларак, ул ыру-кабилә мөнәсәбәтләренең таркалуы, матди эшчәнлектән рухи-гамәли формаларның бүленеп чыгуы белән бәйле. Географик һәм социомәдәни тәҗрибәне киңәйтү аша. Бу этапта Пространство һәм Вакытны континуум буларак башкача аңлау барлыкка килә: аларның өзлексез булуы һәм үзара элемтәләре искә алына. Пространство күптөрле, иксез-чиксез һәм бер үк вакытта билгеле бер табигый-климатик һәм этномәдәни чикләре булган яшәү тирәлеге буларак, аның гаҗәеп күптөрлелегендә катлаулы һәм вакланган бөтенлек буларак кабул ителә башлый.

Шул ук вакытта Вакыт – озын һәм өзеклекләргә ия, үзенең алга таба үсешендә гади формалардан катлаулыга, башлангычтан ахырга таба хәрәкәт итә. Дөньяның яралтылуы идеясе аның башын һәм беренчел сәбәбен, шуңа күрә ахырының да котылгысыз булуын күздә тота. Тарихи вакыт үзе дискрет һәм дөньяның, җәмгыятьнең иң гади формалардан катлаулырак, «түбән»нән «иң югары» формаларга бара торган аерым бер этапларга бүленгән.

Субъект – мөстәкыйль, ул инде табигатьтән, ыруглык берләшмәсеннән аерым; абстракцияләр, рефлексия һәм үзрефлексия

күнекмәләре белән эш итә алган шәхес-индивид буларак аерылып чыккан. Аның белән мифоэпик дөнья арасында – катлаулана барган коммуникацияләрнең турыдан-туры булмаган формалары, эшчәнлекнең яңа предметлы-гамәли формалары, ирекле интенцияләр торган саен күбрәк очрый.

Тарихи яшәеш – кешенең дөньяда хәзер һәм биредә булуының чикле һәм котылгысызлыгы. Бары тик Ыру төшенчәсе генә, Ыру Яшәешенә, ыру тормышына, тулаем алганда, аерым шәхескә мәңгелекне тою хисе бирергә сәләтле [Кант, 1994, с. 12–29]. Әмма ырулык таркалу белән индивид ялгыз кала, мөстәкыйльлек ала, югалып, гаять зур дөнья белән икәүдән-икәү генә кала. Бәлки шуңа күрә дә бездә үзебезне гади «без», кешеләр булган өчен яраткан туганнарыбызның һәм якыннарыбызның яшәргә җайлаштырылган, уңайлы һәм күз җитәрлек дөньясына ихтыяҗ зурдыр. Моны үзенең Ойкуменасы белән үзен гармониядә хис иткән борынгы грек белән, үзенең эстетик ихтыяҗына туры китереп, бербөтенне тәшкил иткән Пафос-Этос-Логос белән чагыштырырга мөмкин булыр иде. Безнең балалар әкиятләре, гаилә тарихлары, уртак халык җырлары һәм анекдотлары, хикәятләр һәм героик риваятьләр – һәммәсе дә безгә яшәргә җайлаштырылган континуумда булуны куркынычсыз итә. Анда үткәннәр хәзергедә органик рәвештә катнаша һәм киләчәккә ышаныч белән карарга мөмкинлек бирә.

Миф, эпос, тылсымлы әкият, безнең шәхси һәм бер үк вакытта иҗтимагый аңыбызның тарихи яктан борынгы рудиментлары буларак, беркая да китмиләр, юкка чыкмыйлар. Алар теләсә кайсы, иң «алга киткән» заманча мәдәниятнең һәм иң интеллектуаль иҗади шәхеснең тирәнтен серле мохитен барлыкка китерәләр. Аннан неврозларга сәбәп булган курку һәм, шуның белән бергә, сәнгатьтә даһи образлар, социаль мөһим символлар, актуаль идеологемалар һәм халыкны уртак кыйммәтләр тирәсендә туплау өчен ритуаллар туарга мөмкин, алар арасында безгә риваятьләрдә «васыять» ителгәннәре һәм «массага» әверелергә ирек бирмәгәннәре дә бар.

Миф, эпос, тарих (stories), хәзерге заман аңы рудиментлары буларак, әлегә теләсә кайсы этнокультураның константасын барлыкка китерә. Аның ни дәрәҗәдә перспективалы булуын киләчәк күрсәтер. Без аларны төрле караштан чыгып өйрәнү һәм саклау буенча зур тырышлык куябыз. Алар барысы да төрле фәннәр өлкәсендәге белгечләрнең комплекслы тикшеренүләрендә урын ала. Миф, эпос, тарих өчен гомуми булган нарратив, пространствода һәм вакытта хәрәкәт итү формалары – мотивлар, образлар, геройлар – шулай ук аларның үз дөньяларында яшәве кебек формалар бүгенге көндә комплекслы өйрәнү өчен иң перспективалылары.

**Әдәбият**

*Фрейд З.* Будущее одной иллюзии. Введение в психоанализ. М.: АСТ, 2021. 400 с.

*Фрейд З.* Неудовлетворенность культурой. Малое собр. соч. СПб.: Азбука, 2013. 608 с.

*Лосев А.Ф.* Диалектика мира. М.: Изд. дом ЯСК, 2021. 355 с.

*Лосев А.Ф.* Очерки античного символизма и мифологии. М.: Академ. проект, 2021. 775 с.

*Мухаметзянова Л.Х., Давлетшина Л.Х.* Роль устных и письменных памятников в изучении мифологии татар // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2022. Т. 15. № 12. С. 3772–3776.

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос: книжные дастаны. Казань. ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АНРТ, 2014. 380 с.

*Кант И.* Идеи всеобщей истории во всемирно-гражданском плане. 1784. Сочинение: в 8 т. Т. 8. М.: Чоро, 1994. 455 с.

***Булатова Дания Сергеевна,***
*фәлсәфә фәннәре кандидаты, доцент*

УДК 821.512.145, 82:801.6

***Н.М. Юсупова***

# АЗӘРБАЙҖАН ШАГЫЙРЕ ӘЛӘСКӘР ИҖАТЫ ҺӘМ ТӨРКИ ШИГЪРИЯТТӘ «ГЫЙШЫК ӘДӘБИЯТЫ» ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

В данной статье в контексте творчества азербайджанского поэта второй половины XIX – начала XX века Ашуга Алескера рассматриваются традиции ашугской поэзии в тюркских литературах. Особое место в творчестве Алескера занимали такие жанры ашугской поэзии, как «теджнисы», «дивани», «мухаммесы», «устаднаме», «гыфылбенд», «гошма», «герайлы», «джыгалы теджнисы», «додагдеймезы». Поэт писал самые сложные по форме стихи, создавал на них ашугские напевы и сам же виртуозно исполнял их на сазе. Мастерски исполнял «герайлы», «диваны», «мухаммес», «Гейчэ гюлю», «Кереми», «Яныг Кереми», «Керем гезеллемеси», «Короглу», «Короглу дженгиси», «Атлы Короглу», «Пияда Короглу», Мисри», «Джалили», «Сарытель», «Баш Сарытель», «Дубейти», «Гезеллеме», «Яныг Кереми», «Дилгеми», «Афшары», «Шерили», «Нахчываны» и другие ашугские напевы. Сравнительное изучение позволяет уточнить общее и особенное в разных национальных литературах, имеющих общую основу, сформировавшихся в разных национальных литературах, выявлять отдельные закономерности и особенности трансформации, определить литературные факторы, оказавшие на них влияние.

**Ключевые слова:** Ашуг Алескер, азербайджанская поэзия, ашугская поэзия, татарская поэзия.

In this article, in the context of the work of the Azerbaijani poet of the second half of the XIX – early XX century, Ashug Alesker, the traditions of Ashuk poetry in Turkic literatures are considered. A special place in the work of Ashug Alesker was occupied by such genres of Ashug poetry as «tejnis», «divani», «muhammeses», «ustadname», «gyfylbend», «goshma», «geraily», «jygaly tejnis», «dodagdeimezy». The poet wrote the most complex poems in form, created ashug melodies on them and himself masterfully performed them on saz. Masterfully performed «geraily», «sofas», «muhammes», «Geyche gulu», «Keremi», «Yanig Keremi», «Kerem gezellemesi», «Koroglu», «Koroglu cengisi», «Atli Koroglu», «Piyada Koroglu», Misri», «Jalili», «Sarytel», «Bash Sarytel», «Dubeyti», «Gezelleme», «Yanig Keremi», «Dilgemi», «Afshary», «Cherili», «Nakhchivan» and other Ashug melodies, he loved to tell heroic and love dastans. Against the background of his work, the peculiarities of Tatar Sufi poetry are revealed. Comparative study makes it possible to clarify the common and special in different national literatures that have a common basis, formed in different national literatures, to identify individual patterns and features of transformation, to determine the literary factors that influenced them.

**Keywords:** Ashug Alesker, Azerbaijani poetry, Ashug poetry, Tatar poetry.

Татар һәм азәрбайҗан әдәби бәйләнешләренең күпгасырлык тарихы бар. Төрле милли-мәдәни яссылыкларда, үзгә менталитет тәэсирендә үсеш-үзгәреш кичерсәләр дә, азәрбайҗан һәм татар әдәбиятларын төрки тамырлар, Көнчыгыш әдәби фикерләү үзенчәлеге,

уртак әдәби бәйләнешләр берләштерә. Әдәбият белемендәге тикшеренүләр раслаганча, сүз сәнгатендә уртак традицияләрнең формалашуы өчен тарихи, географик һәм социаль шартлар булуы мөһим. Моннан тыш, Х. Миңнегулов әдәби бәйләнешләр өчен конфессиональ уртаклыкның, хакимлек итүче әдәбиятның милли әдәбиятларга йогынтысының да зарурлыгын күрсәтә [Миңнегулов, 1993, б. 78]. Урта гасырларда азәрбайҗан әдәбияты татар әдәби һәм мәдәни фикере үсешенә зур йогынты ясый, билгеле бер дәрәҗәдә алгарыш юлларын билгели. «Бер яктан, азәрбайҗан шагыйрьләре үзләре төрки яки Көнчыгыш әдипләренең иҗатыннан, әдәби казанышларыннан файдаланса, икенче яктан, үзләре дә шул әдәбиятлар вәкилләре өчен илһам чыганагы булып тора. Әдәби элемтәләр даирәсе, әсәрләр генә түгел, хатлар, үрнәк җаваплар һәм хәтта берәр шигырьгә язылган истикъбаль (дәвамнар) хисабына да киңәя» [История..., 2002, б. 5] дигән фикер татар шигърияте мисалында да актуаль яңгырый.

Әлеге мәкаләдә XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы азәрбайҗан шагыйре Ашуг Әләскәр иҗаты контекстында төрки әдәбиятларда киң таралган гыйшык поэзиясе традицияләрен ачыклау, шушы фонда татар әдәбиятының үзенчәлекләрен төгәлләштерү күздә тотыла. Чагыштырма өйрәнү уртак нигезгә сүз сәнгатьләрендә әдәби күренешләрнең милли үзенчәлекләрен төгәлләштерергә, аларның уртаклыгын һәм үсеш-үзгәреш, трансформация үзенчәлеген күрергә, тәэсир ясаган әдәби факторларны билгеләргә, канун булып калган аерым сыйфатларны аерып чыгарырга мөмкинлек бирә.

Әләскәр (1821–1926) иҗаты азәрбайҗан сүз сәнгатенең генә түгел, төрки әдәбиятларның алтын фондын тәшкил итә. Сазда уйнап, яттан бик күп Көнчыгыш романтик шигырьләрен һәм мәхәббәт дастаннарын башкару белән чикләнмичә, ул үзе дә шушы юнәлештәге әсәрләр иҗат итеп, гыйшык-остага әверелә. Төрки әдәбиятларда аңа ияреп, охшатып язу, аның иҗатыннан үрнәк алу күренешләре пәйда була. Гыйшык әдәбияты юнәлешендә аның үз укучылары булуы да билгеле, тикшеренүләр күрсәткәнчә, исемнәре билгеле булган 170 тән артык гашыйкның күбесе Әләскәр укучылары булып санала [Әләскәр, 2004, б. 9].

Фольклордан үстерелеп киткән гыйшык әдәби традицияләре күп кенә төрки әдәбиятларда актив юнәлеш булып санала. Ул үзәккә мәхәббәт темасын ала, илаһи мәхәббәт культын алга сөрә, үзенчәлекле стильгә ия булып санала. Анда гадилек, матурлык алга куела, мондый шигырьләрдә халык теленең бөтен гүзәллеге ачыла. «Гыйшык әдәбияты» термины әлеге әдәби агым вәкиле булган кешене белдерә торган «гашыйк» сүзеннән килеп чыга. Алар, «халык шигърияте вәкиле» буларак, үз әсәрләрен яки башка авторларның әсәрләрен саздагы уен озатуында башкара торган булалар. Мондый авторлар халык арасында бик популяр булулары белән характерланалар.

Әләскәр 1821 елда Эриван ханлыгының Гёкчи мәхәлләсе Агкилис авылында туа. Аның әтисе Алимәмәт балта остасы булып эшли,

шул ук вакытта гошма һәм бәет кебек шигъри жанрларда яхшы эшләүче буларак билгеле була. Әтисенең малаена зур йогынты ясавы турында да фикерләр әйтелә. Әләскәргә шактый ярлы гаиләдә үсәргә туры килә, аңардан тыш, гаиләдә тагын 5 бала була. Шуңа да Әләскәргә 14 яшьтән үк бай җир биләүче Карбалай Гурбан фермасында эшләргә туры килә. Үзенең көчле хәтере һәм тарихны сөйли белүе аркасында, кечкенәдән үк үз авылындагы чараларда катнаша, ул вакыттагы шактый дастаннарны истә калдыра, аларны яттан сөйләргә ярата торган була.

Халык авыз иҗатын, дастаннарны яхшы белгән, әтисендә остазлык мәктәбе үткән Әләскәр үзе дә гыйшык әдәбияты вәкиленә әверелә. Әләскәр иҗатында «диван», «мөхаммәс», «гошма», «герайл», «тәҗнис» һ.б. гыйшык шигърияте жанрлары аерым урын тота. Ул формасы буенча иң катлаулы шигырьләр яза, аларга көйләр чыгарып, үзе үк аларны сазда виртуозларча башкара торган була. Ул «Гайшә гөле», «Кәрәми», «Янган Кәрәми», «Кәрәм газәлләре», «Атлы Короглу», «Мисри», «Газәлләмә», «Афшар», «Шәрили» һәм башка шундый көйләрне башкара. Беренче шигырьләрендә аның газапланулары, беренче бәхетсез мәхәббәт тарихы урын ала, кичерешләрнең тирәнлеге һәм киеренкелеге сизелеп тора. Ул сөйгән яры белән аерылышуны бик авыр кичерә. Бу хисләр соңрак шәхси чикләрне үтеп китеп, Әләскәр шигырьләрендә гомумкешелек хисләренә әверелә, чын мәгънәсендә аны халык шагыйренә әверелдерә.

Гыйшык шигърияте вәкиле буларак, Әләскәр иҗатында мәхәббәт һәм матурлык культы көчле яңгыраш таба. Аның шигырьләрендә гади җир кызына, кешеләргә булган мәхәббәт сурәтләнә, Әләскәр яратып язган Асли, Басти, Парзад, Гевер, Гөлли, Мөшгуназ, Телли, Гила, Һаҗәр һәм башка гүзәлләр – барысы да гади җир кызлары. Аларны сурәтләү барышында автор азәрбайҗан халык авыз иҗатыннан үстерелеп килгән фольклор образларыннан һәм Көнчыгыш поэтик алымнарыннан файдалана.

Көнчыгыш әдәбиятлары белгече Р. Ганиева XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы азәрбайҗан һәм татар әдәбиятында, европалашу тенденциясе башлануга карамастан, фольклор традицияләренә, Көнчыгыш ренессанс казанышларына тартылуның көчле булуын билгели. Аның фикеренчә, азәрбайҗан һәм татар романтикларының фольклор һәм Көнчыгыш ренессансы алымнарына, мотивларына өстенлек бирүе мәхәббәт культының чагылышында аеруча көчле күзәтелә [Ганиева, 2002, б. 59]. Бу үзенчәлек Әләскәр иҗаты мисалында да актуаль кабатлана ала. Шагыйрь хатын-кыз матурлыгын Аллаһ бүләге дип саный, хатын-кызларны фәрештәләргә тиңләп, аларның матурлыгын тормышның иң югары кыйммәтләре рәтенә күтәрә. Аны хатын-кыз матурлыгы сокландыра, рухландыра, шушы матурлык аны гыйшык әдәбияты вәкиле дә итә.

«Матурлык һәм мәхәббәт феноменын» тудыру юлында шагыйрь, Көнчыгыш әдәбиятларындагыча, идеаль кыз тибын тәкъдим итә,

Көнчыгыш ренессансы стилендә мәхәббәтне илһам чыганагы итеп күтәрә. Элгәреләр кебек үк, Әләскәр кешенең җаны, йөрәге мәхәббәт аша гына чистарына ала [Гаджиева, 2018, б. 76] дип саный. Шагыйрь шушы юлда йөрәк, чәч толымы, гөл, ялкын, роза чәчәге, Ләйлә, кош, Пәри кебек тышкы һәм эчке матурлыкны ачуга бәйле Көнчыгыш романтик образларын актив куллана. Көнчыгыш романтиклары үрнәгендә шагыйрь үзенең сөйгәнен Пәри дип атый. Пәри фарсы һәм иран мифологиясендә «вакытлыча җәннәттән куылган һәм кешеләрне җеннәрдән саклаучы фәрештә» булып тора [Бертельс, 1997, б. 142–144]. Мисал өчен, Әләскәрнең «Пери» шигырендә ул лирик геройны тормыш авырлыкларыннан саклаучы, илһамландыручы образ итеп бирелә. Шушы юлда беренче шигырьләрнең берсендә ул сөйгәненең күкрәген Кәгъбәгә, ә күлмәген Кәгъбә тышлыгына тиңли.

Шушы ук чорда – XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы татар романтик шигъриятендә дә – мәхәббәт һәм матурлык культы актив булып, охшаш образ һәм мотивлар белән характерлана. Ләкин татар поэзиясендә гыйшык поэзиясе аерым юнәлеш хасил итми, ә бәлки, романтик мәхәббәт лирикасы һәм суфичылык поэзиясе кысаларында яши. Моннан тыш татар әдәбиятындагы мондый шигырьләрдә, фольклор традицияләреннән бигрәк, Көнчыгыш әдәби традицияләре өстенлек ала. Мәсәлән, Г. Тукай «Мәхәббәт» (1908), «Бер рәсемгә» (1908), «Гашыйк» (1909) кебек романтик шигырьләрендә эчкерсез саф мәхәббәткә, аның кодрәтенә, хатын-кыз гүзәллегенә дан җырлый, Көнчыгыш ренессанс традицияләрендәгечә, мәхәббәтне илһам чыганагы итеп күтәрә, мәхәббәт мотивы фольклордан үстерелә килгән, татар поэзиясе өчен традицион булган образлар аша ачыла. Ш. Бабичның «Минем фәрештәм» (1915), «Гыйшык» (1916), «Исемнәр бакчасында» (1917) шигырьләрендә дә мәхәббәтнең илаһилыгы, күңел офыкларының чиксезлеге хакындагы караш җиткерелә. Шагыйрь чын мәхәббәтнең Аллаһ бүләге булуын исбатлый. Шуңа бәйле аның күп шигырьләре нәфис затларга – хатын-кызларга атап язылган. Ул аларга дан җырлый, матурлыкларын чиктән тыш арттырып, сыйфатларының камиллегенә сокланып, бөек зат буларак сурәтли. Романтик образлылыкка тәңгәл аның кызлары – күк фәрештәләре, алар кояш белән айга караганда да нурлырак; аларның гүзәллеге ал розаларны, оҗмах гөлләрен хәтерләтә; тавышлары – көмеш чишмә җыры кебек; чәчләре – көлтә төсле, ефәк кебек; кашлары – яңа туган айдан нечкәрәк; күзләре – кара, кайчак зәңгәр, тылсымлы; иреннәре – кәүсәр, мәрҗән; тешләре – гәүһәр һ.б. «Исемнәр бакчасы» дип исемләнгән циклда бу сыйфатлар аеруча калку гәүдәләнә. Охшаш мотивлар М. Фәйзинең «Хәйран булам» (1912), «Табигать манзарасы» (1912) кебек шигырьләрендә дә гәүдәләнеш таба. Б. Мирзановның «Җен туе» (1915), Һ. Такташның «Таң кызы» (1921) әсәрләренә игътибар итсәк, мәхәббәтне идеаллаштыру юлында, Көнчыгыш әдәби традицияләрендәгечә, Пәри кызы образына мөрәҗәгать ителә. Татар шигырьләрендә ул мәхәббәт чыганагы булып кына калмый, матурлык

һәм җан символы булып күтәрелә. Аңа булган мәхәббәт аша платоник мәхәббәт фәлсәфәсе җиткерелә, мәхәббәт яшәешнең асылын аңлауга ачкыч кебек аңлатыла.

Платоник мәхәббәт концепциясен сурәтләү юлында татар шагыйрьләре халык авыз иҗаты мөмкинлекләреннән һәм Көнчыгыш романтик образларыннан гына түгел, суфичыл символикадан да оста файдалана. Мондый шигырьләрдә ике эчтәлек белдерү сыйфаты көчле булып, образлар еш кына суфи һәм дөньяви эчтәлекләрне җиткерүгә юнәлтелә. Объектив эчтәлектә җир кызына мәхәббәт кебек кабул ителгән шигырьләр субъектив эчтәлектә илаһи гыйшык мотивын гәүдәләндерә, Аллаһ белән кушылу, аңа булган мәхәббәтне сурәтли. Нәкъ менә шундый мәхәббәт лирикасы үрнәкләрендә татар поэзиясенең үзенчәлеген тәшкил иткән әдәби синтез күренеше пәйда була. Мәсәлән, Г. Тукайның «Гыйшык бу, йа?..» (1906), «Алла гыйшкына» (1906), «Ифтирак соңында» (1906), «Мәхү идәрмисән?» (1906), «Сөеклемнең кабер ташында» (1906) һ.б. шигырьләре суфичыл символикага корылып иҗат ителә һәм шигырьләрне өч юнәлештә – саф суфичылык, дөньяви мәхәббәт һәм әдәби иҗат фәлсәфәсе рухында аңлау-шәрехләүгә мөмкинлек калдырыла. Бу күренешнең С. Рәмиев, Дәрдмәнд иҗатларында да актив кулланылуы әдәби синтез күренешенең XX гасыр башы татар шигъриятендә тулы канлы алым булып формалашып җитүе хакында сөйли.

Әләскәрнең дә аерым шигырьләре Көнчыгыш суфичылык әдәбияты мөмкинлекләреннән файдаланып языла, мондый шигырьләрдә Аллаһка мәхәббәт мотивы, мистик мәхәббәт үзәккә куела. Мисал өчен, суфиларда илаһи мәхәббәтне ачуга юнәлтелгән ут эчендә яну мотивы, дәрвиш образлары Әләскәр шигырьләрендә шушы юнәлештә файдаланыла. Шагыйрьнең «Аллаһның аты илә», «Пәйгамбәрнең мирасы», «Рәнҗ али аба», «Бах бах», «“Вәли”, – диеп...» кебек шигырьләрендә лирик герой камил инсан буларак чыгыш ясый. Изгелек, кешеләрне сөю, дуслык, ярдәмчел булу, булганга канәгать булу, Аллаһ кушканча яшәү, юмартлык, тәкъвалык, шәфкатьлелек, һәрдаим гыйбадәттә булу, шәригать кануннарын җиренә җиткереп үтәү, Аллаһтан ярлыкау һәм җәннәт өмет итү Әләскәрнең лирик герое тарафыннан камил инсанның төп сыйфатлары буларак кабул ителә. Шуңа мөнәсәбәттә кешелеклелек сыйфатлары мактала, гуманизм идеясе күтәрелә, лирик герой кешеләрне мәрхәмәтле булырга өнди. Аның фикеренчә, мөселман кешесе – үзендә иң игелекле, иң югары уңай сыйфатларны туплаган, динебезнең күрсәтмәләрен игътибар белән үтәп, кеше сыйфатларын җыйган кеше. Моннан тыш Ашуг Әләскәр әсәрләрендә «ک ,ك» («кяф»), «ن» («нун»), «الم» («әлиф, лям, мим»), «د» («дәл») һ.б. гарәп хәрефләренең дә мистик мәхәббәт мәгънәсендә символлашуы күзәтелә.

Бу чор татар шигъриятендә дә мәхәббәт феноменына корылган әсәрләрнең бер өлеше Аллаһка булган илаһи мәхәббәт белән сугарыла. Ш. Зәки, Ә. Каргалый, Г. Чокрый шигырьләрендә сандугач,

күбәләк, күк, җил, гөл, бакча һ.б. образлары илаһи гыйшыкны ачуга юнәлтелә. Мәсәлән, Ш. Зәкинең «...Йазыкым чук, азыгым юк» шигырендә мәхәббәт баскычындагы лирик герой кичерешләре сурәтләнеп, ул хис-тойгылар парлы суфичылык символлары аркылы җиткерелә. Шигырь ике катламлы булып, суфи контекстта былбыл образы – суфи, ә гөл образы Аллаһ буларак шәрехләнә, гөлгә омтылган, аны мактап сайраган былбыл халәте илаһи мәхәббәтне җиткерүгә юнәлтелә. XIX гасыр шагыйрьләре Ш. Зәки һәм Ә. Тубыли әсәрләрендә хәрефләр символикасы د («дәл»), ک, ك («кяф»), ن («нун»), ق («каф») күзәтелә. Хәрефләрне символ статусында куллану мистик эчтәлекне көчәйтә һәм шигъри текстларны стилистик яктан бизи һәм баета. Аллаһка мистик мәхәббәт, суфи шагыйрьләргә хас булганча, хисси сөю образларында тасвирлана, шуңа да гыйшык шигырьләрен укыганда һәрвакытта да сүзнең нинди (мистик яки җир) мәхәббәт хакында баруын аеру кыенлаша. Бу татар әдәбиятында суфи шигърияткә хас нәфис стильнең үсеш алуы һәм нәкъ шушы чорда иң югары үсешкә ирешүе белән аңлатыла ала.

Шул рәвешле, Әләскәр иҗатын шул чор татар шигърияте белән чагыштырма аспектта өйрәнү, бер яктан, образлылык, поэтик яссылыкта төрки һәм Көнчыгыш әдәбиятларда канунлашкан әдәби фикерләүнең ныклыгын, поэтик яссылыкта, образлар, мотивлар бирелешендә күп уртаклыклар булуын күрсәтә. Шул ук вакытта һәр халыкның сүз сәнгате осталары үз әдәбиятларының үзенчәлекле әдәби фикерләүгә ия тугрылыклы вәкиле булып кала. Бу үзе үк һәр әдәбиятның үз үсеш юлын салуы турында сөйли.

**Әдәбият**


Aşıq Ələsgər. Əsərləri. Bakı: Şərq-Qərb, 2004. 400 s.

*Бертельс А.Е.* Художественный образ в искусстве Ирана IX–XV веков (Слово, изображение). М.: Изд. фирма «Вост. лит.» РАН, 1997. 422 с.

*Гаджиева К.Г.* Сравнительное изучение азербайджанской литературы XV века в контексте исследования классической восточной поэзии // Актуальные вопросы современной филологии и журналистики. 2018. № 2 (29). С. 72–76.

*Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 272 с.

История Азербайджанской литературы. Баку, 2002. 575 с.

*Миннегулов Х.Ю.* Татарская литература и восточная классика: вопросы взаимосвязи и поэтики. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1993. 383 с.



***Юсупова Нурфия Марс кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф*
*Югары мәктәбенең татар әдәбияты кафедрасы профессоры,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге доценты*

УДК 82.091

***Н.Ә. Хөббитдинова***

# БАШКОРТ ӘДӘБИЯТЫНДА ФОЛЬКЛОР ИНТЕРТЕКСТЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

В статье в общем плане представляются возможности интертекстуального метода исследования в башкирской литературе. Выявляются интертекстовые связи – связи или «диалоги» между текстами. Автор приводит примеры заимствований фольклорных текстов, использованных в литературном произведении, обращает внимание на то, что иногда они расходятся с его первоначальным фольклорным назначением, вплоть до полного противопоставления. Делается вывод о том, что использование данного метода постмодернизма позволяет глубже выявить семантическую природу фольклоризмов в литературе.

**Ключевые слова**: башкирская литература, интертекстуальность, фольклор, метод, аллюзия, реминимценция, художественность.

In the article, in general terms, the possibilities of the intertextual method of research in Bashkir literature are presented. Intertext connections are revealed – connections or «dialogues» between texts. The author gives examples of borrowings of folklore texts used in a literary work, draws attention to the fact that sometimes they diverge from its original folklore purpose, up to a complete opposition. It is concluded that the use of this method of postmodernism makes it possible to reveal more deeply the semantic nature of folklorisms in literature.

**Keywords:** Bashkir literature, intertextuality, folklore, method, allusion, reminiscence, artistry.

Билгеле булганча, әдәбият гыйлемендә фольклор белән әдәбият бәйләнешләре проблемалары шактый тикшерелгән. Бу өлкәдә бигрәк тә А.Н. Веселовский, В.Я. Пропп, Е.М. Мелетинский, В.М. Жирмунский, М.К. Азадовский, У.Б. Далгат, М. Ауэзов, К.Ш. Нурланова, Б.Н. Путилов, Д.Н. Медриш, А.Г. Яхин кебек рус һәм башка милләт галимнәре [Веселовский, 1989; Пропп, 1986; Мелетинский, 1986; Жирмунский, 1979; Азадовский, 1960; Далгат, 1981; Ауэзов, 1959; Нурланова, 1987; Путилов, 1988; Медриш, 1980; Яхин, 1978; 1984] белән беррәттән Кирәй Мәргән (Ә.Н. Кирәйев), Ә.И. Харисов, К.Ә. Әхмәтйәнов, Г.Б. Хөсәйенов, Ә.М. Сөләймәнов, С.Ә. Галин, Г.С. Кунафин кебек башкорт тикшеренүчеләренең [Харисов, 2007; Әхмәтйәнов, 1982; Сөләймәнов, 2009; Хөсәйенов, 1984; Ҡунафин, 2011; Галин, 1972] хезмәтләре мөһим. Тик моңарчы башкорт әдәбиятының художестволы бизәкләре, шул бизәкләрне тагын да ачыграк, яктырак иткән халык иҗатының үзенчәлекле поэтик чагылышын тикшерүләр традицион, калыплашкан әдәби-гыйльми методларга нигезләнә килде. Әмма шул ук вакытта бу җәһәттән яңа карашлы тикшеренүләрнең акрынлап башлануын да күз уңыннан ычкындырырга ярамый [Хөббитдинова, 2005; Хуббитдинова, 2016].

Тәкъдим ителгән әлеге мәкаләнең нигезендә дә, һичшиксез, әле әйтелгән комплекслы – фольклористика, әдәбият гыйлеме, культурология фәннәре мәгънәсендә, эзлекле һәм системалы тикшерену ысулы ята. Бу очракта гуманитар фәннәр өлкәсенә караган әдәби анализ бернинди дә фәнни-техник, табигать фәннәре өлкәләре белән бәйләнештә түгел. Бу очракта фән күренеше буларак әдәбият белән фольклор өлгеләре анализланып, аларның әдәбияттагы художестволы чагылышы постмодернистик гыйльми мәктәптән билгеле булган *интертекстуальлек алымы* ярдәмендә, ягъни культурология мәгънәсендә каралды. Алга таба сүзебез шушы алым турында.

Совет чорында фәнни эзләнү-тикшеренүләрнең тарихи-материалистик методологиясе марксизм тәгълиматына таяна иде. Гыйльми хезмәтләрдә шушы алым телгә алынып кына кителә дә, гадәттә, шулайрак яңгырар иде: «Методологической основой диссертации (яки башка берәр хезмәт. – *Н.Х.*) явились теоретические положения классиков марксизма-ленинизма о культурном наследии, решения партийных съездов и пленумов ЦК КПСС. Научно-теоретическим ориентиром исследования служили работы советских литературоведов»; «...Теоретической базой нашего исследования послужили работы классиков марксизма-ленинизма по вопросам языкознания и научные труды ведущих деалектологов нашей страны» һ.б. [Сөләйманов, Хөббитдинова, б. 5].

Постсовет чорында исә диссертация белән авторефератларның тиешле җирендә «Методологическую основу работы составляют труды следующих авторов» дип, яңгырашлы исемнәр теземе бирелүчән. Мондый гадәт бүген дә саклана, әмма кулланылган методлар конкрет һәм объектив бирелергә тиеш, әлбәттә.

Шул ук мәлдә фәндә барлыкка килгән төрле карашларның, методологик алымнарның бүгенге көндә дә мөһим булып калуы хакында онытырга ярамый. XX гасырның икенче яртысында илебездә барган «фәнни тикшеренүләрдә комплекслылык», соңрак «системалылык» (системность) кебек ысуллар белән беррәттән, «эшмәкәрлек күзлегеннән чыгып эш итү юлы» (деятельностный подход) дигән методологик карашлар әнә шундыйлардан [Шәрипова, б. 30–31].

Бүген исә төрле фәннәрнең берләшү – интеграция процессын кичерү күренеше күзәтелә. Хәзерге гыйльми хезмәтләрдә методологик ысул итеп телгә алынган комплекслы һәм системалы тикшеренү юлы (подход) файдаланыла. Шушы урында модага әверелеп барган методларга тукталып китү зарурдыр. Аларның нигезендә теге яки бу гыйльми тикшеренүнең максаты һәм бурычларына ярашлы рәвештә төрле фәннәрнең ысулларын, алымнарын, методларын берләштереп карау ята. Комплекслы юл (подход) белән тикшерү дигәндә, аның төрле фәннәрнең (хәтта берничек тә якын булмаган гуманитар һәм техник фәннәр булуы ихтимал) бәйләнешендә алып барылуы күз уңында тотыла. Мәсәлән, фольклор белән әдәбият, әдәбият белән лингвистика, әдәбият белән этнология яки әдәбият белән культурология,

математика, химия яки архитектура һ.б. фәннәрнең бәйләнеше дә булуы мөмкин. Мәсәлән, С.И. Сухих тикшеренүенең гыйльми юллары, ысуллары хакында сүз йөрткәндә, М.М. Бахтинның «Проблемы поэтики Достоевского» дигән хезмәтендә еш кына «полифония»[1], «полифонический роман» кебек музыка өлкәсенә караган терминнарны куллануы хакында да әйтеп үткән иде [Сухих, с. 303]. Яки А.А. Арзамазовның удмурт әдәбияты образлылыгы белән лингвосемантик үзенчәлекләрне берләштереп, филология күзлегеннән каравы җитмәгән, аны хәтта «флористическо-фаунистический блок», «удмуртский континуум», «корреспонденция мифическая» кебек төрле фәннәр өлкәсеннән (ботаника, биология, физика, лингвистика, журналистика һ.б.) билгеле булган терминнарны җәлеп итү сөземтәсендә, удмурт әдәбиятының поэтик үзенчәлекләрен ачыклауда кызыклы нәтиҗәләргә килде [Арзамазов, 2016]. Я булмаса, экиятләрне философия күзлегеннән чыгып, аларны әхлакый сайлау проблемасын (проблема выбора) тикшерүче Л.Ә. Иткулова, мәсәлән, халык иҗатының бу жанрын фольклористика, әдәбият гыйлеме, этнография, археология, философия фәннәре материалларын бергә укмаштырып, файдаланып өйрәнүне хуп күрә [Иткулова, 2002]. Мондый тикшеренүләр *комплекслы* тикшеренү дип атала.

*Системалы* юл белән алып барылган тикшеренүдә исә (биредә сүз, әлбәттә, әдәбият хакында бара) әдәби әсәрне художестволы әсәр иткән өлешләр төрле методка таянып анализлана. Ягъни әсәр үзе бер структура, система булып чыгыш ясый, әнә шул системаны булдырган сюжет, композиция, мотив яки әдәби формасы, жанры һ.б. мәсьәләләре бер-бер артлы, логик бәйләнешле карала. Аларның үзенчәлекләрен ачык күрсәтү максатында төрле методларга мөрәҗәгать ителә (тарихи-чагыштырма, типологик- яки генетик-чагыштырма, аналитик һ.б.) Мәсәлән, безнең очрактагы әдәби сюжетны булдырган мотив семантикасының фольклор традициясенә нигезләнүе ихтимал. Фольклор традициясенә мөрәҗәгать иткәннән соң гына әдәби әсәрнең художестволы үзенчәлегенә башка күзлектән карап, анда ярыйсы ук чагылыш тапкан фольклор традицияләрен анализлап, кызыклы тәҗрибә, күзәтү ясарга була. Бу очракта әсәрнең поэтик нечкәлекләре бөтен киңлегендә һәм тулылыгында күренеп, төрле төсләрдә ачыграк чагылуы ихтимал. Яки халык иҗатында (әкияттә, эпоста, легендада һ.б.) сурәтләнгән фольклор мотивлары, сюжетлары «күз өйрәнгәнлектән» бөтен үзенчәлегендә ачык ук күренми башларга да мөмкин. Әдәбиятта урын алганнары исә яңа художестволы киңлектә (пространство) трансформацияләнеп, көчлерәк чагылуы, хәтта ки аның шулай бөтен сафлыгында, тулылыгында саклануы мөмкин. Ягъни язма әдәбият халык иҗаты традицияләрен язма килеш, ташта бастырылган рәвештә саклап, мәңгеләштерүгә ирешә, үзенә күрә саклау функция-

[1] Кара: **Полифо́ни́я** в теории музыки – склад многоголосной музыки, определяющийся функциональным равноправием отдельных голосов (мелодических линий, мелодий в широком смысле) многоголосной фактуры.

сен үти. Мәсәлән, бу бигрәк тә рус язучылары иҗатында көчлерәк төс ала: халкыбызның «Куҙыйкүрпәс белән Маянһылыу» эпосының бер варианты тулысынча XIX гасырда Т. Беляев әсәрендә («Куз-Курпяч, башкирская повесть, писанная на башкирском языке одним курайчем и переведенная на российский в долинах гор Рифейских, 1809 года» (Казань, 1812) әнә шундый яңача художестволы яктырту табып, фәндә «Беляев версиясе» дип аталып яшәп килә яки шул ук чорда В. Даль тарафыннан шундый ук эшкәртелештә «Заятүләк белән Һыуһылыу» эпосының бер варианты «Башкирская русалка» исеме астында ташка бастырылып, фәндә исә «Даль версиясе» дип аталып йөри.

Тагын шуны искә төшереп китү зарурдыр. Әле үткән гасырның 60–70 нче елларында милли фольклористика өлкәсендә актив эшләгән, башкорт әдәбияты гыйлеменә нигез салучы күренекле галим Ким Әхмәтйәновның «Поэтик образ һәм тарихи контекст» дигән мәкаләсе безнең өчен кызыклы. Анда ул РСФСР Язучылар союзы Оештыру комитетының Икенче (Өфе) пленумындагы Мостай Кәримнең чыгышына сылтама ясап, 20–30 нчы елларда иҗат иткән кайсыбер әдипләребезнең (М. Гафури, Д. Юлтый ишеләрнең), сыйнфый көрәшне тасвирлаган тарихи чорны чагылдырганда, мәҗбүри халык иҗаты, мифологиясе традицияләренә мөрәҗәгать итүләрен билгеләгән иде. Ягъни сыйнфый көрәшне алып баручылар тик изге зат булып, – экият батырларын, инде дошманнары исә – явыз, кире көчләр лагерен тәшкил итүчән. Шушы моментка галим һәм тәнкыйтьче Ким Әхмәтйәнов бөтен әдәби фикер һәм тормыш закончалыкларына таянып ачыклык кертте. Моны ул «башкорт халкының эстетик аңының мифтан художестволы фикерләүгә күчү» процессында катлаулы юл үтүе белән бәйләде. Һәм шушы процесс барышында борынгы мифик образлар белән заман герое арасында бәйләнешнең булуын билгеләде. Дәверләр артыннан дәверләр үткән мәлдә заман таләпләре дә үзгәрә, «яңа законнар ачылу белән, фән һәм техникадагы карашлар бик тиз искерә һәм, асылда, яшәүдән туктый». Әдәбиятта, художестволы фикер киңлегендә исә борынгы традицион образлар, тема һәм сюжетлар саклана, яки «искергән дип исәпләнгән формалары бүген мөстәкыйль рәвештә дә, соңгы дәверләрдә язылган әсәрләрнең образлар системасы эчендә бераз үзгәртелгән көенчә дә яши» [Әхмәтйәнов, 1994, б. 112], дип дәвам иткән иде фикерен. Икенче төрле әйткәндә, кайчандыр әйтелгән сүз, сурәтләнгән образ яки сюжет, вакытның күпме үтүенә карамастан, яңадан кабатлана, сак кына үзгәреш кичерсә дә, үзен таныта, искә төшерә. Ягъни галим әйткән борынгы мифология поэтикасы бүгенге әдәбиятта да үзен сиздерә, художестволы сынланыш таба, ягъни, инде бүген фәнни итеп әйткәндә, интертекст бәйләнеш тудыра. Ким Әхмәтйәнов, күрәсең, М.М. Бахтинның хезмәтләре белән хәбәрдар булган, чөнки гел текстлар, фикерләр диалогы хакында әйткән кебек.

Тормышның тиз үскән, үзгерешләр, яңарышлар – модернизацияләр кичергән бер мәлендә нindider яңалык, прогрессив алымнарны

сынап караганда, кайчак, күптән булдырылган, әмма нindидер сәбәпләр аркасында онытылган гыйльми ачышлар, гомумиләштерүләр нәкъ шул «яңалыкның» булу ихтималын ачыклый. Филология фәнендә кайчандыр ачылып та онытылуга дучар ителгән *интертекст* теориясе билгеле. Бу бүгенге галимнәрнең иркен фикер йөртеп, тикшеренү эшләрендә төрле методологик юлларны чамалап карау белән бәйледер. Үз чиратында аны бертөрле фикерләүдән, калыплашкан карашлардан арынуга омтылу белән дә аңлатып буладыр. Милли фәнгә килгәндә исә, әлегә традицион ысулларның кулланылуы күзәтелә. Әмма, моңарчы салынган теоретик нигезләрне инкяр итмичә, шуңа таянып, яңача фикерләүчеләр дә юк түгел.

Шушы яссылыкта әдәбиятны тәкъдим ителгән метод ярдәмендә карау фольклор традицияләренең кулланылу механизмына төшенергә, аларның әсәрдә нинди художестволы функция үтәп килүен, семантикасын ачыкларга, текстара бәйләнешләрне барларга ярдәм итә. Боларның барысын да башкару максатында, алда телгә алынган комплекслы һәм системалы, чагыштырма, тарихи-мәдәни кебек методологик алымнар белән беррәттән, күптән билгеле һәм герменевтиканың бер төре булып та, әмма совет фәнендә телдән төшеп калган җирдән бүгенге Россия гыйлемендә тергезелгән, *интертекст ысулына* аеруча мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Моның белән нindидер искиткеч ачыш ясау артыннан кумыйча, дөнья мәдәниятенең бер өлеше булган башкорт милли әдәбиятын да шушы ысуллар ярдәмендә тикшереп карап, аны киңрәк даирәләргә чыгару нияте өстенрәк дип табылды. Бу җәһәттән безнең өчен әдәби әсәрдә чагылыш тапкан, файдаланылган фольклор традицияләрен санап кына үтмичә, аларны тулаем сәнгати-эстетик караштан чыгып, әдәбият белән фольклор арасындагы бәйләнешне ачыклап, төрле чорда иҗат ителгән әдәби әсәрләр арасындагы интертекстны өйрәнү бигрәк кызыклы булыр иде.

*Герменевтика*, билгеле булганча, текст, сүз мәгънәсенә төшенүне, интепретацияләүне аңлата. Әдәби әсәрдә фольклор традицияләренең чагылыш табуы, әсәргә нindидер рәвештә сәнгати һәм эстетик яктан тәэсир итүе, аның поэтик үзенчәлекләрен арттыруы яхшы аңлашыла. Әсәрдә урын алган халык иҗаты элементларын һәркем җиңел генә күреп, атап чыга яки фольклор сюжеты белән әдәби әсәр я булмаса, бер авторның әсәре белән башка автор әсәре арасындагы (яки анда бирелгән герой образлары, мотивлары) охшашлык, параллельләрне күреп, шуның белән интертекстуаль бәйләнеш хакында сүз йөртә ала. Әмма чын мәгънәсендәге гыйльми тикшеренү моның белән генә чикләнми әле. Чөнки билгеле галим Б.В. Томашевский әйтүенчә: «…обнаруженные “параллели” будут носить характер мало значащего “сырого материала”, а “выискивание этих параллелей” вне уяснения их характера, сути, функции будет представлять собой что-то вроде “литературного коллекционирования”» [Томашевский, с. 81–82]. Безнең очракта да чагылыш тапкан фольклор традицияләренең семантик үзенчәлекләрен өйрәнгәч, аларның әсәрдәге художестволы функциясе, роле, тоткан

урыны, мәгънәсе (ягъни теге яки бу фольклор күренешенең семантикасы, табигате, идея-эстетик торышы) янә төрле яклап ачыклана һәм яктыртыла. Чөнки фольклор беренче карашка гади төшенчә кебек кабул ителсә дә, асылда, Р.Ә. Солтангәрәева дөрес әйтәкәнчә, «в нем (в фольклоре. – *Н.Х.*) нет ничего случайного, бессвязно выдуманного из ничего и не имеющего когда-то практического применения… фольклорный жанр… сложный мировоззренческий код, полимерный тест-символ традиционной культуры…» [Султангареева, с. 7]. Моның белән, ягъни шушы үзенчәлекләргә ия булган халык иҗаты традицияләрен үз иткән әдәби әсәрнең төп асылына, аның башка әдәбият, рухи-мәдәният, җәмгыять күренешләренә (традицияләренә) бәйле булуына, авторның моның белән нәрсә әйтергә теләвенә тирәнрәк төшенү мөмкинлеге туа. «Актуальные проблемы методологии литературной критики» дигән хезмәттә әйтелгәнчә, «…всякий текст при всей своей неповторимости является представителем некоей общности, … определенной культурной традиции, символ присутствия духовности. Интерпретация может быть направлена на выявление этой объективной духовности, которая имеет исторически меняющиеся формы, но имеет некую неизменную сущность, своим постоянством обеспечивающую непрерывность культурной традиции, отражающую единство исторического процесса» [Сөләймәнов, Хөббитдинова, б. 14]. Башкорт әдәбиятын шушы һәм интертекстуальлек күзлегеннән карау аны мәдәни, художестволы универсалий (культурные, художественные универсалия) фонында тикшерү, аның художестволы гомуми һәм уртак урыннарын күзәтү, ягъни башкорт художестволы сүз сәнгатен бөтендөнья мәдәнияте яссылыгында, аның бер өлеше булуын исбатлап тикшерү мөмкинлеге дә бирә.

Шул ук вакытта без әсәрнең поэтик үзенчәлекләрен өйрәнүдән дә читләшмәскә тиеш. Билгеле ки, поэтика әсәрнең жанрын тикшерә, персонажлар характерын ачыклап анализлый; темасын аныклый, ягъни символик формада гына булса да, әсәрне интерпретацияләү мөмкинлеге биргән кодларны (конвенция системасы) билгеләүдән гыйбарәт. Поэтиканың бурычы булып тик әдәби әсәрдә художестволылыкны тудырган төрле чараларны аңлату тора [Сөләймәнов, Хөббитдинова, б. 14, 15].

Интертекст белән поэтиканы аерып карау үзен акламас төсле. Бу бигрәк тә художестволы әсәрнең семантик структурасын гына түгел, аның поэтик үзенчәлекләрен дә мәҗбүри тикшергәндә мөһим. Бу җәһәттән художестволы әсәрнең поэтикасын махсус рәвештә төрле яклап өйрәнгән Ә.Ш. Абдуллина дөрес билгеләгәнчә, «…интертекстуальность – это использование поэтики того или иного произведения в структуре другого произведения, присутствующее в открытом (эксплицитном) или завуалированном (имплицитном) виде и проявляющееся как перекодировка поэтики чужого произведения в собственных художественных целях» [Абдуллина, с. 314]. Язучының әлеге иҗади эшмәкәрлеге аңлы һәм аңсыз, интуитив рәвештә башкарылуы ихтимал.

Янә дә башкорт әдәбиятында башка халыклар фольклор традицияләре чагылырга мөмкин. Һәм дә бер үк сюжетның төрле халыклар авыз-тел иҗаты репертуарында очраган версияләрен тарихи-генетик планда өйрәнүне дә интертекст ысулы ярдәмендә башкарып, кызыклы нәтиҗәләргә килү форсатын тудыра. Мәсәлән, мәшһүр татар халык шагыйре Габдулла Тукай иҗатында очраган башкорт һәм татар халыклары мифологик карашы, фольклор традицияләренең ярылып ятуы әнә шул хакта сөйли [Хөббитдинова, 2022, б. 46–54]. Алай гына да түгел, художестволы универсалийга ярашлы рәвештә, хәтта ки милли әдәби әсәр белән башка милләт кинофильмы яки сүз сәнгате белән сынлы сәнгать арасында интертекст бәйләнешләрен күзәтү мөмкинлеге дә бермә-бер арта. Мисалга башкорт совет язучысы Һәзиә Дәүләтшинаның «Айбикә» (1931) повестен китерергә мөмкин. Аның нигезендә кичәге басынкы, сабыр яшь кызыкай, вакыт үткән саен, тормыш авырлыкларына һәм каршы искән җилләргә бирешмичә ныгып чыныккан характерга әверелеп, ирләр һөнәрен үзләштереп, алардан калышмый хезмәт итә башлаган эмансипацияләнгән хатын образына бәйле хәл-вакыйгаларга корылган сюжет ята. Ул, асылда, 1980 елда киң совет экраннарына чыккан «Мәскәү күз яшенә ышанмый» (реж. Владимир Меньшов, «Москва слезам не верит») кинофильмының В. Черных хикәясенә нигезләнгән сюжеты белән имплицив бәйләнешкә кергән булуы ачыклана. Ягъни башкорт әдибәсенең 30 нчы елларда иҗат ителгән әсәре белән рус авторының әсәре арасында шулай интертекст бәйләнеш барлыкка килгән. Болар үз милли үзаңы, поэтик нечкәлеге булган башкорт әдәбиятын шушы универсалийлар гомумилегендә карарга мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, кайчандыр барлыкка килеп тә, онытылып калган, соңыннан Россия әдәбият гыйлемендә янә дә тергезелгән интертекстуальлек теориясе яшәүгә хаклы. Аның мөмкинлекләре милли әдәби фикерне бөтен тулылыгында, поэтик киңлегендә тикшерү мөмкинлеге бирә. Традиция буларак файдаланыла килгән билгеле әдәбият методлары белән беррәттән ниндидер мәгънәдә новатор ысулына әверелгән текстара бәйләнеш – «диалог» ысулының да файдасы зур булуы танылды.

**Әдәбият**

*Абдуллина А.Ш.* Поэтика современной башкирской прозы. Уфа; ИИЯЛ, 2009. 352 с.

*Азадовский М.К.* Статьи о литературе и фольклоре. М.-Л.: Наука, 1960. 547 с.

*Арзамазов А.А.* Эволюция образной системы и лингвосемантические трансформации в удмуртской поэзии половины 1970-х – начала 2010-х гг.: автореф. дис. … д-ра филол. наук. Ижевск, 2016. 41 с.

*Ауэзов М.О.* Мысли разных лет. Алма-Ата: Наука, 1959. 556 с.

*Әхмәтйәнов К.Ә.* Поэзияла матурлыҡ һәм ҡаһарманлыҡ. Өфө: Башҡ. кит. нәшр., 1982. 304 б.

*Әхмәтйәнов К.Ә.* Поэтик образлылыҡ. Өфө, 1994. 160 б.

*Веселовский А.Н.* Историческая поэтика. М.: Высшая школа, 1989. 406 с.

*Галин С.А.* Фольклор һәм заман. Өфө: Башҡ. кит. нәшр., 1972. 112 б.

*Далгат У.Б.* Литература и фольклор. М.: Наука, 1981. 248 с.

*Жирмунский В.М.* Сравнительное литературоведение. Л.: Наука, 1979. 493 с.

*Иткулова Л.А.* Нравственный выбор в башкирской сказке (Философско-мировоззренческий анализ). Уфа: БашГУ, 2002. 136 с.

*Кунафин Г.С.* Башкирская поэзия XIX – нач. XX в.: Вопросы жанровых и идейно-художественных особенностей. Уфа: Гилем, 2011. 480 с.

*Медриш Д.Н.* Литература и фольклорная традиция. Вопросы поэтики. Саратов, 1980. 296 с.

*Мелетинский Е.М.* Введение в историческую поэтику эпоса и романа. М.: Наука, 1986. 317 с.

*Нурланова К.Ш.* Эстетика художественной культуры казахского народа. Алма-Ата: Наука, 1987. 556 с.

*Пропп В.Я.* Фольклор и действительность. М.: Наука, 1976. 326 с.

*Путилов Б.Н.* Героический эпос и действительность. Л.: Наука, 1988.

*Сөләймәнов Ә.М.* Өс мөғжизә. Өфө: Китап, 2009. 296 б.

*Сөләймәнов Ә.М., Хөббитдинова Н.Ә.* Әҙәби әҫәрҙе тикшереү юлдары. Өфө: Китап, 2012. 168 б.

*Султангареева Р.А.* Башкирский фольклор: семантика, функции и традиции. Уфа: Башк. энцикл., 2018.

*Сухих С.И.* Методология литературоведения; комплексный и системный методы анализа литературы // Вестник Нижегородского университета им. Н.И. Лобачевского. 2012. № 6(1). С. 298–303.

*Томашевский Б.В.* Пушкин и Франция. Л., 1960. 498 с.

*Харисов А.И.* Литературное наследие башкирского народа (XVIII–XIX вв.). 2 издание, дополненное. Уфа: Китап, 2007. 416 с.

*Хөббитдинова Н.Ә.* Башҡорт әҙәбиәтендә фольклор. Өфө: Ғилем, 2005. 163 б.

*Хөббитдинова Н.Ә.* Фольклор в башкирской литературе: художественно-эстетический аспект (XIII – начала XX века). Уфа: Гилем, 2016. 276 с.

*Хөббитдинова Н.Ә.* Габдулла Тукай иҗатында милли-мәдәни антропологик образлар: сәнгатьчә универсалияләр һәм интертекстуальлек // Фәнни Татарстан. 2022. № 3. Б. 46–54.

*Хөсәйенов Ғ.Б.* Быуаттар тауышы. Башҡорт әҙәбиәте тарихы, теорияһы һәм тарихи поэтика буйынса очерктар. Өфө: Башҡ. кит. нәшр., 1984. 299 б.

*Шәрипова З.Я.* Әҙәбиәт ғилеме һәм заман. Өфө: Китап, 2001. 320 с.

*Яхин А.Г.* Изучение системы взаимодействия устного народного творчества и литературы // Проблемы взаимосвязи фольклора, литератур и литературных языков народов Приуралья и Поволжья: сб. тез. / Н.Т. Зарипов (отв. ред.). Уфа, 1978. С. 3.

*Яхин А.Г.* Система татарского фольклора. Казань: Таткнигоиздат, 1984. 200 с.

***Хөббитдинова Нәркәс Әхмәт кызы,***

*филология фәннәре докторы, М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университетының Башкорт фольклоры гыйльми тикшеренү үзәге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 82.091

*Гази Кашшаф*

## ИБРАЙ ГАЗИ ИҖАТЫ

В этом году исполняется 115 лет со дня рождения известного литературоведа, критика, педагога и прозаика Гази Кашшафа (Миргази Султанович Кашшафутдинов) (1907–1975). Гази Кашшаф является одним из немногих писателей, сумевший оставить после себя богатейшее литературно-научное наследие. Его первые критические статьи начали появляться еще в студенческие годы. Уже в тридцатые годы своими статьями-рецензиями об отдельных писателях, их произведениях и театральных постановках он зарекомендовал себя как высокообразованный критик с тонким пониманием литературно-художественного мира. Труды ученого в области литературоведения и критики отличаются теоретической обоснованностью, обширностью аналитического обзора и актуальностью поставленных проблем.

В статье представлен критический анализ Гази Кашшафа на творческую деятельность другого, не менее именитого классика татарской культуры – Ибрагима Гази (1907–1971), где наиболее ярко раскрывается аналитический талант мастера.

**Ключевые слова**: Гази Кашшаф, Ибрагим Гази, критика, литературно-художественное наследие.

Ghazi Kashshaf is one of the few writers who managed to leave behind rich literary and scientific heritage. His first critical articles began to appear in his student years. Already in the thirties, with his articles-reviews about individual writers, their works and theatrical productions, he established himself as a highly educated critic with a subtle understanding of the literary and artistic world. The works of the scientist in the field of literary criticism are distinguished by their theoretical validity, the extensiveness of the analytical review and the relevance of the problems posed. The article presents a critical analysis of Gazi Kashshaf on the creative activity of another, no less eminent classic of Tatar culture – Ibrahim Gazi (1907–1971), where the analytical talent of the master is most clearly revealed.

**Keywords:** Ghazi Kashshaf, Ibrahim Ghazi, criticism, literary and artistic heritage.

Ибрай Газиның бу көнгә кадәр совет укучысына таныш булган, эшче яшьләр, әдәбият укучылары тарафыннан яратып укыла торган хикәяләре: «Кич алтыда», «Көмеш сулы Нурминкә», «Бармак» һәм «Бригадир кыз».

Бу хикәяләр бөтенесе киез итек фабригы тормышын яктырталар. Аның аерым-аерым цехларына керәләр. Аерым-аерым хезмәт процессына тукталалар. Һәм шул хезмәт белән мәшгуль булган эшчеләрне-ударникларны, яшьләрне гәүдәләндерәләр. Аларның производстводагы, өйдәге, клубтагы, бакчалардагы тормышларын яктырталар.

Ибрай Гази безне бер производство – киез итек фабригы – тормышы белән таныштыра. Ләкин алар бер үк төсле булып, бер-берсенә

ошап чыкмыйлар. Язучы безгә бөтен әсәрләрендә диярлек бер производствоны бирсә дә, һәрбер әсәр саен шул безнең – «башкасы» белән таныштыра. Бер хикәясендә без аның котельный, слесарьный цехларын күрсәк, икенчесендә механический цехын, клубын, бакчасын һ.б.ларын күрәбез. Һәркайсының үзенә герое бар, һәрбер станокның үз хуҗасы, һәрбер цехның үз көрәшчесе бар. Бу язучының бу производствоны яхшы белүен күрсәтә. Язучы билгеле бер производствоны үзенең серияле әсәрләрендә бөтен яктан таныштырырга тырыша.

Ибрай Газиның башка язучылардан аерыла торган сыйфаты – аның әнә шул югарыда әйтелгән тормышны бик җиңел итеп язуында. Аңарда һичбер көчәнү юк. Комсомолларча үз эшенә ышану, шатлык, күңел көрлеге, җиңел ирония, сатира – аның һәрбер геройны сурәтләгән җөмләсендә сизелә. Күңелле-кызганычлы вакыйгалар да, куркынычлы-шатлыклы моментлар да җиңел бер төзелеш белән агалар. Әсәрнең әдәби спецификасы үз чиген югалтмый. Язучы үзе дә, теге яки бу төр вакыйгага карата лирик хисләнүгә бирелеп, җанын кирегә әйләндереп чыгарырга тырышмый яисә артык сикереп, күккә очарга да теләми. Ул һаман шул тыныч кыяфәтен югалтмый, күңел көрлеген ябыктырмый гына көлүен, иптәшләрчә генә «тешләвен» дәвам иттерә.

Теге яки бу вакыйганың гәүдәләнүен биргән вакыттагы җиңелчә һөҗү аның исем сайлавында да сизелә. Мәсәлән, «Бригадир кыз»дагы – Телшаянов, «Көмеш сулы Нурминкә»дә – Кузгалаков, икенче бер хикәясендә – Байраков һ.б., кыска гына әйткәндә, язучы хәзерге тормышның катлаулы күренешләрен матур итеп яза белә, шул күренешләр белән укучыны кызыксындыра ала. Геройларын тулы итеп күрсәтә ала. Җиңел, тигез тел моның өчен яхшы корал булып тора.

Әгәр дә без И. Газиның әсәрләренә аерым-аерым тукталып, ныклы тикшерүдән соң нәтиҗә чыгарсак, җыелган нәтиҗә, һичшиксез, югарыда әйтелгән фикергә кайтып калыр иде. Тик без бу урында тикшерелү объекты итеп «Бригадир кыз» хикәясен генә алабыз. Башка хикәяләренә тукталу да фәкать язучының иҗат юнәлешен күрсәтү өчен генә.

Чыннан да, Ибрай Газиның беренче хикәяләреннән берсе булган «Кич алтыда»ны алып карасак, анда әле без язучының остарып җитмәгәнен, теге яки бу вакыйганы схема төсендә генә биргәнен күрәбез. Ләкин шулай да бу әсәрендә үк инде язучының тема сайлый белүе, вакыйгаларны схематик төстә булса да оештыра белүе күзгә ташлана. Аз гына булса да, матур, производство образлары сайлый белүе иҗади эшенә җитди каравын күрсәтә.

«Кич алтыда» әсәренең төп әйтергә теләгән фикере – социализм ярышының практик эш өчен дә, кешене тәрбияләүдә дә зур әһәмияткә ия булган корал икәнен күрсәтү. Моның өчен язучы комсомоллар коллективын ала. Шул коллектив эчендә актив эшләүче Миргалиевне бирә, аның социализм ярышы өчен бригада төзүгә ашкынуын, талпынуын, пафосын матур гына күрсәтә. «Кытай, Марокко турында гына сүз боткасы оештырудан бушамаган» комсомоллар ячейкасы –

ярыш нәтиҗәсендә, производство эше белән ныклы бәйләнеп, җанлы чынбарлык белән кулга-кул тотынып эшли башлаулары, комсомолны сыйнфый дошманга алыштырып, читкә ташланган Таһирны производствога, комсомолга кайтара.

Тик бу әһәмиятле момент язучы тарафыннан күрсәтелми, фәкать әйтелә генә. Таһирның Нәгыймәгә китү күренешен биргәннән соң, бик озак вакытлар үткәч, аның кире комсомолга кайту күренешен әйтү белән чикләнелә. Шундый ике төрле адым ясаган Таһирның тормыш белән бергә үсә баруы эш процессы белән бергә психологик процессны үзгәртүе бөтенләй шәүләләнми. Әгәр дә әсәрнең төп әйтергә теләгән фикерен искә алсак – һичшиксез, Таһирның сурәтләнү моменты бик зур җитешсезлек булып әверелә. Һәм ул шулай да. Бу әсәрдә без тулы кеше күрмибез, төгәлләнгән типлар монда юк. Монда фәкать фабриктагы яшьләрнең төрле вакытта төрлечә ишетелгән тавышлары гына бар. Коллектив эчендәге геройлар да төзсез-затсыз (обезличенный) авазлар эченә күмелә.

Типларны гәүдәләндерүдә «Көмеш сулы Нурминкә» хикәясе дә шул ук җитешсезлек белән авырый. Әсәрдә санап бетергесез геройлар катнаша, тик туры рәвештә формалашканы юк дәрәҗәсендә аз. Баш каһарман Фәридә генә безгә бер кадәре тулырак бирелә. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел, чөнки Фәридә аша язучы эшче яшьләрнең производство өчен көрәшүдәге батырлыкларын күрсәтергә тырыша. Фәридә Нурминкә суын фабрикка кертү турында проектлар, чертежлар төзү белән шөгыльләнә. Бу – мөмкин эш. Чөнки фабрик өчен су бик кирәк, «артезиан коесы әле өлгерерлек түгел... шуның аркасында алынган заказларның үтәлмәве мөмкин. Фәридә проекты – мәсьәләне хәл кылачак, тик директор белән фабком рәисе каршы торалар».

Соңыннан карт слесарь Җамай да кушылгач, директорны җиңәләр. Озак та үтмичә: «Фабрикка барып тоташырга өлгермәгән чуен торбадан көмеш сулы фонтан бәрде». Заказ үтәлә.

Әсәр турыдан-туры төп фикергә бәйләнмәгән вакыйгалар белән тулы. Шулар хисабына әсәрне тулыландару, геройның ничек эшләвен күрсәтү мөмкин булыр иде, әлбәттә.

Бер кыска гына хикәя эченә: производстводагы эшчеләргә тулы характеристика бирү, промфинплан өчен көрәшү, сыйнфый көрәш, авылны яңабаштан яңа нигезгә корып җибәрү һ.б. ларны кертү, яктырту мөмкин булмаган эш. Нәтиҗәдә, аларның берсе дә тулы булып чыкмый.

«Бригадир кыз»да инде без Ибрай Газиның баштагы хикәяләрендә ачыктан ачык сизелеп торган әнә шул җитешсезлекләрдән котылуга таба барганын күрәбез.

«Бригадир кыз» – үзенең күләме белән зур, эшләнеше белән башка хикәяләреннән өстен торган әсәр. Бу әсәрдә язучы төрле нәрсәгә таралу, сибелүне бетергән. Кайвакыт читкә чыкканда да ул төп фикерне тулылауга ярдәм итү күзлегеннән эшләнгән. Мәсәлән, «Бригадир

кыз» хикәясендә ФЗӨ яшьләренең экскурсиягә баруы кебек момент турыдан-туры әсәрнең композиция үсешенә бәйләнмәгән вакыйга төсле, ләкин бу вакыйга соңыннан бик матур рәвештә каһарманнарга да, әсәрнең төп уена да бәйләнә. Каһарманнарның характерын тулыландыру өчен ярдәм итә. Ә көмеш сулы Нурминкә»дәге тайпылуларда без мондый бәйләнүне күрмибез.

«Бригадир кыз» безгә нәрсә бирә? Әсәр безгә иң башлап производствода ныклы политик җитәкчелек булмауның аны таратуга таба алып баруын күрсәтә. Эшләп чыгаруның кимүен, дисциплинаның җимерелүен, прогулларның үсүен әйтеп бирә. Шул ук җитәкчелек юклык аркасында оештыручының булмавы сәбәпле яшьләр арасында нишләргә белмәү, тормышта череп таралу, аң-белем, фикер үсештә туктап, туңып калулар булу һәрбер укучыга күрсәтелә.

Шушы төп моментны язучы безгә оста рәвештә күрсәтә алган. Әсәрнең үзен укып чykканнан соң, һәрбер укучы ныклы политик җитәкчелек кирәклегенә төшенә, ышана алырлык рәвештә матур эшләнгән.

Әсәрнең төп әйтергә теләгән фикере дә шул. Тик бу фикер хикәянең исеме белән бәйләнмәгән төсле. Ләкин бу өстән караганда гына шулай. Чөнки – бригадир кыз – Галия, әнә шул җитешсезлекләргә каршы куелган иҗаби – яхшы тип итеп алына. Прогулчы Адаевларга, үзара тәнкыйтьтән куркучы Касыймнарга, гыйшык колы булып йөргән Назыйровларга каршы – Галия бөтен яктан җитешкән бер кыз – комсомолка итеп күрсәтелә. Бөтен җитешсезлекләргә каршы көрәшүче итеп сурәтләнә һәм Галия тибы баш рольләрнең берсен уйный.

Хикәядә зур гына бер фабрикның иң авыр хәле тасвир ителә. Партколлектив секретаре курска укырга киткәч, фабрик коллективын комсомол коллективы секретаре Касыймга тапшыралар. Ә ул эшлми. Эшчеләр сүзенә колак салмый. Массадан аерым яши. Принцип өчен үлә торган бер кеше. Һәм шундый «принципиальный» кеше булулыгын әсәрнең ахырына чаклы саклап алып бара. Шул «принцип» аркасында – эшчеләр обществосында булган хулиганлыкны тикшерми, тикшермичә йөреп, Рәхимәнең поезд астына ташлануына сәбәп була. Суга батып үлүче яшьләр турында да газетага яздырмый, төп сәбәпнең ачылуыннан курка. Шулай ук пар казанын шартлатуда иң төп гаепле машинистны, үзенең җизнәсе булганы өчен, судка да бирдерми, урыннан да алдырмый... Аның гаепләре күп. Шул гаепләрне бюро аның үзенә күрсәткән вакытта да, Касыйм һаман үз «принцыбында» кала. Үзе белгән, үзе аңлаган җитешсезлекләр турында да сөйләргә, сөйләндерергә яратмый. Ул җитешсезлекләрне бер кешегә дә әйтмичә, һичкайчан фаш итеп «массаны паникада бирдермичә» генә бетерергә тырыша, дөресрәк әйтсәк – уйлый, тик булдыра алмый. Шуның өстенә Касыйм – диктатор сурәтендә генә «җитәкләргә» яратучы. Ул – команда белән генә эш итүче.

Касыйм янына директор Вәлиевне китереп кушкач, картина тагы да ачыклана төшә – язучы директорны шушылай сурәтли.

Билгеле, шундый җитәкчелектән соң нинди нәтиҗә булуы үзеннән үзе ачыла. Шуңа күрә фабрикта өзеклек, секретарь «юлбашчылыгы» астында экскурсиягә баручылардан өч кеше суга батып үлә. Аның артыннан тагы бер авария – моторның стройдан чыгуы гәүдәләнә. Болары гына аз әле, моннан башка тагы пар казаны шартлый, Рәхимәнең поезд астына ташлануы, яшьләрнең клубка барып ни эшләргә белмичә сугышулары, хулиганлык кылулары – һәркайсы укучы алдыннан тулы образлар аша бер-бер артлы шуа тора.

Менә шуның өчен дә, җитәкчелекнең булмавы аркасында, Адаев кебек кешеләр фабрикның үзәк фигурасы булып йөри. Инициативадан мәхрүм булган, мәхәббәт колына әверелгән Назыйровлар ни эшләргә белми аптырый.

Әсәр әнә шул ике типны гәүдәләндерә. Ныклы политик җитәкчелек булмау нигезенә үскән Адаев белән Назыйровның бөтен эчке-тышкы тормышларын ачып сала. Болар икесе дә – авыру типлар. Ләкин болар икесе бертуган түгел. Болар бер-берсенә каршы көрәшәләр. Адаевны тасвирлаганда язучы безгә аның бөтен эчке-тышкы тормышын күрсәтеп, җәмгыятькә зарарлы бер кеше итеп чыгара.

Адаев – слесарь. Ләкин ул – эшчеләр сыйныфына кушылып китмәгән бер тип. Ул фабрикны да ташлап бетерми, авылын да ташламый. Аның бөтен уе мал җыюда. Кайда күбрәк акча эшләргә мөмкин, һичбер тоткарсыз аны шунда җибәрсеннәр. Ул Магнитогорскига да барып эшләп карасын. Америкага да китсен.

Адаев образында без «эшче слесарь» маскасы астына өретелгән, ләкин үзенең бөтен уе белән эшче сыйныфына дошман булган бер типны күрәбез. Ул бик тулы итеп эшләнгән тип. Аның карашын «бишьеллык план»га карата да, үз хатынына карата да, башка хатын-кызларга, эшче-ударникларга, яшьләргә карата да ачыктан-ачык күреп була.

Чыннан да, ул – хәзерге җәмгыять өчен артык бер кеше. Ул үз эшенә һичбер төрле күңел бирмәү генә түгел, хәтта аз гына да мәсьүлият алып бармый. Әнә шул мәсьүлиятсезлек – иң кирәкле урында гына Адаевны дошман ягына, ягъни Адаевның үз сыйныфы ягына чыгарып ташлый.

Ләкин Адаев кебек эшләү, Адаев фикерләре белән йөрү, кайчан гына булмасын, билгеле бер чиккә китереп терәргә тиеш. Әнә ул шулай булып чыга да. Адаевның баштагы пассивлыгы, ягъни социализм төзелешенә каршы актив рәвештә көрәшүчеләр сафына китереп кертә. Менә шушы процесс пассив төзүчедән актив җимерүчегә әверелү – язучы тарафыннан матур итеп бирелгән, ышанырлык итеп күрсәтелгән. Әсәрнең кыйммәте дә шунда.

Адаев – әсәрдәге иң зур тип һәм иң начар, бозык типларның берсе. Икенче яктан тагы җитешмәгән типлар бар. Анысы – фабриканың күп тиражлы газета редакторы Назыйров.

Назыйров үз эшендә Адаевка каршы гына көрәшә. Аны газетасында басып чыгара. Шуның өчен Адаев та редакторга ачу тотып йөри. Алар икесе ике сыйныф балалары, икесе ике карашлы. Ләкин

шулай да Назыйров җитешкән тип түгел. Ул гаять йомшак, инициативасыз, килде-китте генә эшләүче бер кеше. Ул массадан аерылган – «массовик». Газеталары да, масса катнашкан газета түгел, фәкать үзе язган газета гына. Үзе мәкалә җыя, үзе хәбәр ясый, үзе газета чыгара. Эшче-хәбәрчеләр оешмаган, ул аны оештырмый, эшчеләр арасына керми, шуның өчен фабриктагы эшләрне дә аннан-саннан гына белә. Эшчеләр язган хәбәрне, төзәтергә иренеп, басмый калдыра. Галия турында уйлаганда гына ул актив. Актив – гашыйк. Гашыйкның да беренче колы. Шул гыйшык хыялларына чумса, Назыйров бөтен дөньясын, бөтен эшен оныта. Галия генә булсын! Аның мәхәббәте һичбер аңга утырып җиткән кеше мәхәббәтенә ошамый. Ул балаларча мәхәббәт белән сөя. Аның сөюендә һичбер тормышка яраклы фикер юк. Әнә шундый мәҗнүннәрчә сөюе аркасында ул бик күп хата ясый да.

Шулай да Назыйров – хәзерге яшьләр арасында сирәк булса да очрый торган тип. Автор хәзерге яшьләрдәге авыру якларны авырттырмыйча дөрес итеп күрсәтә. Назыйровның шундый капма-каршылыклы кеше булуы шул фабрик, шул җитәкчелек белән ныклы рәвештә бәйләнә.

Чыннан да, Назыйровның эшчеләр арасыннан аерылып яшәвен, үз инициативасын югалтуын, авыру җитәкчелеккә буйсынуын искә алсак – һичшиксез, аның камыр характеры үзенә сылашыр.

Әсәр әнә шундый авыру якларны ача. Шуларны оста рәвештә күрсәтә. Вакыйгаларны кызыксындырырлык итеп оештыра.

Шул типларга капма-каршы итеп Галия тибы куела. Яшьләрдән бригада оештыра. Фабрикны өзеклектән чыгару өчен көннәр-төннәр йокламый удар төстә эшли. Гомумән, Галия тибы җиңел йөрәкле, җитез, тырыш, производство өчен чын күңелдән янып йөрүче кеше булып сурәтләнә. Ләкин Галияне гәүдәләндерүдә язучының методы үзенә башка. Галияне сурәтләү, аның бөтен килеш-килбәтен күрсәтү эше Галия турында бөтенесеннән сөйләтү юлы белән эшләнә. Бөтен фабрик Галия турында сөйли. Клубка барса да, фабрикага килсә дә, урамда йөрсә дә яшьләр аның киңәшен тыңлый. Хатын-кызлар аңа үзләренең зарларын сөйлиләр, киңәш сорыйлар. Менә шулар бөтенесе укучы башына матур образлардан җыелган бер кеше – Галия тибын пичәтли. Язучы үзе Галиянең эшенә, аның ничек эшләвенә бик аз туктала [...]

Галияне сыйфатлау эшендә язучы күбесенчә шундый юл алган. Начар, бозык кешеләрнең эчке-психологик якларын ярып салу тонында – яхшы тип, яхшы эшче күрсәтү методы өстенлек алган.

Ләкин Галия тибы «Көмеш сулы Нурминкә»дәге Фәридә тибы кебек кенә тасвирланмый. Галия Фәридәгә караганда тулы бирелә. Фәридәнең цехта эшләве белән Галиянең эшләвен чагыштырганда, Галиянең бригадирка икәнлеге ачык күренә. Бригада эше өчен янып хисләнә алуы, бригаданың алдынгылыгы өчен көрәшүе ачык күрсәтелә. Фәридә кебек бөтен яктан иясез сүзләр аша гына гәүдәләндерелми.

Ләкин әсәрдә җитешсез яклар да юк түгел. Иң элек Галиянең бирелеп бетмәвен – Назыйров, Адаевлар кебек үк тулы төстә гәүдәләндермәвен

әйтергә кирәк. Шулай ук, язучы Галияне бөтен җитешсез якларны күрүче, аны бетерү өчен йөрәге белән янып йөрүче итеп тасвирлыйтасвирлый да, шул «янып йөрүче» итеп кенә калдыра. Галияне шул җитешсезлекләр белән көрәштерми кала.

Шуның белән бергә әсәрнең зур кимчелеге булып, түбәндәге момент искә алынырга тиеш: фабрик начар хәлдә, өзеклек, авария өстенә авария, яшьләр арасында череп таралу һ.б.лар – шуларның барысын фәкать Галия генә күрә. Башкалар күрмиләр кебек. Әсәрдә күренүенчә, фабрик ул кадәре булырга тиеш түгел иде. Фабрикта кадр эшчеләр, чыныккан көрәшчеләр булырга тиешлеген:

– «Ә 1905 елда бу чокырга җиде эшчене аткан иделәр», – дигән сүзләр күрсәтеп тора. Димәк, фабрикның көрәш тарихы зур. Ә шулай да бөтен җитәкчелекне комсомол коллективы секретаре Касыймга тапшыралар. Бу – булырга мөмкин, ләкин китапның оешу формасында укучы ышанырлык ук итеп күрсәтелмәгән.

Әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше матур, шома, җиңел укыла. Производствоны яхшы белгән, аны яхшы өйрәнгән кеше тарафыннан язылганы күренеп тора. Производство образлары кертү, эшчеләргә генә хас булган жаргон белән сөйләтү, кү тәренке күңелле яшьләрнең дә үзләренә хас сүзләре, җырлары урнаштырылу – әсәрнең матурлыгын куертмый түгел, куерта. Ләкин стильне шомартасы урыннар бар. Ибрай Гази хикәяләрендә күп вакыт бер үк җөмлә, бер үк образлар, бер үк әсәрдә берничә тапкыр кабатлана. Бу момент язучы тарафыннан искә алынырга тиеш, чөнки андый кабатланган җөмләләр укучының кызыксынуын киметүдән башкага ярамыйлар.

* * *

Безнең советлар илендә искиткеч зур эшләр башкарыла. Зур бөек нәрсәләр тормышта, күз алдында үсә. Тормышның үзгәрүе тагы да тизрәк бара. Шул тормышны үзгәртә-үзгәртә үзләренең психикаларын, дөньяга карашларын алмаштырып, хезмәткә ихтирам итүләрен арттыра баручы хезмәт ияләре массасы үзләренең тулы йөзләрен әдәбият аша күрергә тели.

Ибрай Гази үзенең хикәяләрендә әнә шул зур үзгәрешне җитешмәгән яклар, бозык кешеләр фонында күрсәтергә тырыша. Ике контрастны алып, араларындагы аерымлыкны билгеләргә омтыла. Шул омтылышта без язучының үсә баруын күрәбез. Аның күп җитешсез яклары бар, ләкин ул һаман яңа әсәре саен аларны киметә бара, яңа хикәясе саен тулырак образлар таба, яңа образ тапкан саен – язучылык буявын куерак төшерә.

*«Совет әдәбияты» журналы, 1933 ел, № 10*

*Текстны басмага филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*
***Гарипова Ләйлә Шамил кызы** әзерләде*

УДК 9-05

***Ф.Ю. Йосыпов***

## В.В. РАДЛОВНЫҢ КАЗАН ЧОРЫ ФӘННИ, ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

В статье рассматривается Казанский период научной, педагогической деятельности одного из основателей русской тюркологической науки всемирно известного ученого Василия Васильевича Радлова (нем. *Фридрих Вильгельм Радлофф*), который в течение своей шестидесятилетней научной деятельности охватил практически все области тюркологии: диалектографию и диалектологию, лексикографию и лексикологию, сравнительную и историческую фонетику и грамматику тюркских языков, куманский язык, текстологию и издание тюркской письменности на руническом, уйгурском, арабском алфавитах, тюркский фольклор, этнографию, историю, археологию.

**Ключевые слова:** В.В. Радлов, Казанская учительская школа, тюркские языки, образцы народной литературы тюркских племен, диалектология татарского языка, памятники древнетюркской письменности.

W. Radloff, worldwide known Turcologist, has accomplished numerous important works on almost every field related to Turcology such as dialectography, dialectology, lexiocography, lexicology, comparative historical phonetics and grammar of Turkish, transcription and facsimile of Turkish texts written with Runic, Uigur and Arabic alphabets, Turkish folklore, Turksih ethnography, Turkish history and archaeology. This study elaborates W. Radloff's scientific researches.

**Keywords:** W. Radloff, Kazan teaching skool, Turcology, the dialectology of Tatar Turkish, folklore, old Turkish Manuscripts.

Россия тюркология фәненә нигез салучыларының берсе булган дөньякүләм атаклы Василий Васильевич Радловның гыйльми эшчәнлеге төркият фәненең барлык өлкәләрен дә: диалектология һәм диалектографияне, лексикология һәм лексикографияне, төрки телләрнең хәзерге һәм тарихи фонетикасы, грамматикасын, рун һәм гарәп алфавитында язылган язма истәлекләрне фәнни өйрәнеп, аларны бастырып чыгару эшчәнлеген, төрки халыкларның этнография, археология фәннәрен үз эченә ала. Тюркология әдәбиятында күпсанлы фәнни мәкаләләр һәм биографик очерклар В.В. Радловның иҗади мирасын өйрәнүгә багышланган, алар галимнең киңкырлы эшчәнлеге, аның тормышы һәм фәнни хезмәтләре хакында теге яки бу дәрәҗәдә күзалларга ярдәм итәләр. Галимнең тормышы, гыйльми эшчәнлеге өч дәвергә бүлеп өйрәнелә: В.В. Радловның Алтай чоры (1859–1871), В.В. Радловның Казан чоры (1881–1884), В.В. Радловның Санкт-Петербург чоры (1884–1818) эшчәнлеге. Галимнең фәнни эшчәнлеген барлау үзе исән вакытта ук башланып китә, һәм һәр чор шактый җентекләп өйрәнелә. Аның Казан чоры эшчәнлеге буенча да шактый фәнни эзләнүләр башкарылган. Шулар арасында Н.И. Ильминский

[Ильминский, 1873, с. 370–374], И.А. Бодуэн де Куртенэ [Бодуэн де Куртенэ, 1909, с. 191–205; 1963, с. 146–202], Л.Я. Штернберг [Штернберг, 1909], А.Н. Самойлович [Самойлович, 1912, с. 707–712; 1919, 1937], В.В. Бартольд [Бартольд, 1977, с. 175–186] хемәтләрен күрсәтергә кирәк. В.В. Радловның Казан чоры татар галимнәреннән Г. Исхакый [Исхакый, 1909, № 68], Р. Фәхретдин [Фәхретдин, 1909, № 10], Г. Шәрәф [Шәрәф, 1917, 5-10/01], Ф.Ю. Юсупов [Юсупов, 2012, с. 4–7; Yusupov Ferit, 2014, s. 292–311; Yusupov Ferits, 2013, 27 (13 A), pp.); З.Т. Шәрәфетдиов [Шәрәфетдиов, 1984, б. 84], Л.Н. Закирова [Закирова, б. 291] хезмәтләрендә яктыртыла.

**Берлиннан Санкт-Петербургка сәяхәт**

В.В. Радлов 1858 елда Берлин университетының философия факультетын тәмамлый. Шул ук елны, Йен университетында «Диннәрнең Азия халыкларына йогынтысы» дигән темага докторлык диссертациясе яклап, философия фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә ала. Берлин университетында укыганда, Радловның остазлары – дөньякүләм билгеле тел галиме, чагыштырма тел белеменә нигез салган Франц Бопп; гомуми тел белеме белгече Август Фридрихович Потт, төрек, чагатай, чуваш, фарсы, япон, кытай, маньчжур, фин, венгр телләре буенча танылган галим, фольклорчы, Урал-Алтай тел белеменә нигез салучы Вильгельм Шотт, мәһшүр географ һәм Көнчыгыш халыкларының этнографиясен тирән белүче Карл Риттер.

В.В. Радлов, университетны тәмамлаган елны ук остазы В. Шоттның Россиядәге дусты һәм коллегасы, чыгышы белән немец милләтеннән булган якут теле белгече Оттон Николаевич Бётлинг исеменә язылган тәкъдим хаты белән Россиягә – Санкт-Петербургка килә. Берлин университетындагы остазлары Радловка Көнбатыш Себер иңкүлегендә яшәүче, моңа кадәр беркем тарафыннан да өйрәнелмәгән төрки халыкларның, ул вакыттагыча әйтсәк, татар кавемнәренең рухи мәдәниятен өйрәнергә киңәш итәләр. Ләкин, Россия империясе тәртипләре буенча, чит ил ватандашларына илнең эчке өлкәләрендә яшәргә рөхсәт ителмәгәнлектән, Вильгельм, Германия ватандашлыгыннан ваз кичеп, Россия ватандашлыгын кабул итәргә мәҗбүр була. 1958 елның 14 маеннан, немец егете *Фридрих Вильгельм Радлофф* Василий Васильевич Радлов булып китә.

**В.В. Радлов эшчәнлегенең Алтай чоры (1859–1871)**

Санкт-Перебургта Россия Фәннәр академиясе белән төзелгән бишьеллык контракт буенча, В.В. Радлов кышларын Барнаул шәһәрендәге реаль училищедә немец һәм латин телләре укыта, җәйләрен Көнбатыш Себердәге төрки халыкларны өйрәнү белән шөгыльләнгән фәнни экспедицияләрдә уздыра. Ул, Алтайга килүгә үк, җирле төрки халыкларның телләрен өйрәнүне, аларның фольклор үрнәкләрен җыюны, җирле халыкның көнкүрешләре белән танышуны, Көнбатыш Себердәге тарихи һәйкәлләрне барлауны үзенең беренче чираттагы бурычы итеп билгели. Аннан соңгы елларда

В.В. Радлов алтайлыларны гына түгел, ә бәлки алар белән күршедәш Көньяк Себер, Урта һәм Үзәк Азиянең төрки телле халыкларын да комплекслы итеп өйрәнүгә зур игътибар бирә. Фәнни эшчәнлегенең Алтай чорында В.В. Радлов әлеге халыкларның телләре, халык иҗаты үрнәкләре, борынгы тарихлары буенча гаҗәеп бай материаллар туплый, биредәге төрки халыкларның ыруглык төзелешен ачыклауга мөнәсәбәтле материаллар таба. Бу фәнни эзләнүләренең нәтиҗәсе буларак, Себердәге төрки кавемнәрнең тарихы турында тулы белешмә әзерли. Аның «Этнографический обзор турецких племен Сибири и Монголии» (Иркутск, 1929) дигән бу хезмәте галимнең вафатыннан соң гына басылып чыга. Замандашларының фикеренчә, үзе туплаган бай фактик материаллар нигезендә язылган дөньякүләм әһәмияткә ия бу хезмәт фәндә зур вакыйга итеп кабул ителә. Әлеге эзләнүләре белән В.В. Радлов Россия тюркологиясен ул вакытта ук бик югары баскычка күтәрә.

1868–1870 елларда ул ун ел дәвамында туплаган материалларын гомумиләштерү эшенә керешә. 1866 елдан ел саен экспедицияләрдә үзе туплаган материалларга нигезләнгән хезмәтләрен бастыра башлый [Штернберг, 1909, с. I–XXV]. Аның басылып чыккан һәр хезмәте рус һәм дөнья тюркологиясенең ул вакыттагы зур казанышы буларак кабул ителә. Шундыйлардан, беренче чиратта, түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк:

1. *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. I част. Поднаречия Алтая: алтайцев, телеутов, черновых и лебединских татар, шорцев и саянцев. СПб., 1866. 418 с.

2. *Радлов В.В.* Наречия тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Поднаречия абаканские (сагайское, койбальское, качинское), кызылское и чулымское (кюэрик). СПб., 1868. XXI. 712 с.

3. *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. III. Киргизское наречие. СПб., 1870. 776 с.

### В.В. Радлов эшчәнлегенең Казан чоры (1871–1884)

В.В. Радловның Казан чорында язылган шактый гына хезмәтләре барлыгы билгеле. Аларның күпчелеге галимнең мәгариф эшчәнлеген яктыртуга багышланган. Шундыйлардан Я. Ханбиков [Ханбиков, 1968, с. 42–49], А. Мәхмүтова [Махмутова, 1982, с. 96 ], Д. Заһидуллина [Загидуллина, с. 105–118], И. Заһидуллин [Загидуллин, 1992, с. 60–82; 2009, с. 49–574]; Л. Закирова [Закирова, 2013, с. 291] хезмәтләрен күрсәтергә кирәк. Галимнең бу чордагы эшчәнлеге татар әдәбияты тарихына, уку-укыту ярдәмлекләренә бәйле рәвештә, М. Гайнуллин [Гайнуллин, с. 307], Ә. Кәримуллин [Кәримуллин, б. 320] мәкаләләрендә чагылыш тапты. Ф.Ю. Йосыповның мәкаләләрендә В.В. Радловның төрки тел белеменә һәм төрки халыкларның халык

авыз иҗатына караган хезмәтләре фәнни анализлана, аның төрки телләрне өйрәнүгә керткән өлеше бәяләнә. Бу хезмәтләрдә шулай ук В.В. Радловның татарларда беренче дөньяви белем бирү системасының барлыкка килү тарихында тоткан урыны яктыртыла.

* * *

В.В. Радлов 1871 елда Себердәге фәнни эшләрен дәвам итү өчен, чираттага контрактын озайтырга дип, Санкт-Петербургка юл тота. Юл уңаенда, Казанда тукталган вакытта, атаклы миссионер, шәркыятьче һәм керәшен татарлары мәктәпләре инспекторы, Духовный академия профессоры Н.И. Ильминский белән очраша. Н.И. Ильминский аны Казан мәгариф округы җитәкчесе П.Д. Шестаков белән таныштыра. Соңгысы Радловка Казан мәгариф округына караган татар, башкорт һәм кыргыз (казакъ. – *Ф.Й.*) мәктәпләре инспекторы вазифасын тәкъдим итә. В.В. Радлов Россиядә Шәрык фәннәре үзәге булган Казан фәнни эзләнүләр алып бару өчен уңайлы булыр дип уйлап, киләчәктә казан татарлары, Идел буе халыкларына багышланган хезмәтләр язуны да күздә тотып, әлеге тәкъдимне кабул итә. Бу вакыйгалар Татарстан Республикасы Милли архивында сакланган материаллар белән дә раслана. Әлеге материаллардан күренгәнчә, Казан мәгариф округы җитәкчесе П.Д. Шестаков 1871 елның 10 мартында Россия мәгариф министры Д.А. Толстойга язган хатында Казан мәгариф округы идарәсе каршында татар, башкорт һәм кыргыз (казакъ. – *Ф.Й.*) мәктәпләре инспекторы вазифасын булдыру, бу урынга Россиянең фәнни җәмәгатьчелегенә яхшы таныш В.В. Радловны тәкъдим итү турындагы үтенечен күндерә [Татарстан Республикасы Милли архивы (НА РТ), ф. 92, оп. 1, д. 10290, л. 1–2].

Д.А. Толстойның 1872 елның 8 гыйнвары күрсәтмәсе буенча, В.В. Радлов Казан мәгариф округының татар, башкорт, кыргыз (казакъ. – *Ф.Й.*) мәктәпләренең инспекторы итеп раслана [НА РТ, шунда ук].

П.Д. Шестаковның без югарыда искә алган хатында бу эшне башкаручы инспекторның татар телен яхшы белергә, башкорт, кыргыз (казакъ. – *Ф.Й.*) халыкларының тормыш-көнкүреше, гореф-гадәт, гамәл-холыклары белән таныш булырга тиешлеге әйтелә. Казан мәгариф округы җитәкчесе фикеренчә, В.В. Радлов бу сыйфатларга ия бердәнбер кеше булып санала. Инспекторга кирәк булган урыннарда мәктәпләр ачу, укытучылар мәктәпләре белән җитәкчелек итү, мәктәпләрне уку кирәк-яраклары белән тәэмин итү хокуклары бирелә. Әлеге күрсәтмәләрнең дәвамы буларак, укытучылар мәктәбенең асылын тасвирлаган рәсми инструкция белән дә танышырга мөмкин. Анда билгеләнгәнчә, башлангыч халык училищелары дип аталып йөртелгән мәктәп-школалар, мөселман мәктәпләреннән, мәдрәсәләрдән аермалы буларак, балаларга башлангыч дөньяви белем нигезләрен бирүгә юнәлтелгән, рус теле мәҗбүри укытыла торган уку йорты булып саналган. Иң мөһиме: әлеге мәктәп-школалар

белән бергә Казан мәгариф округына кергән мөселман мәктәп һәм мәдрәсәләрендә рус сыйныфлары ачу да күздә тотылган.

В.В. Радловның күзаллавы буенча, Казан мәгариф округындагы укытучылар мәктәбе биш ел дәвамында мөселман югары мәктәпләре (мәдрәсәләре) өчен рус теле укытучылары әзерләргә тиеш була [Ханбиков, с. 42–49]. Булачак мәктәпләрнең кагыйдәләре буенча, уку планының төп өлешен рус теле, арифметика, алгебра, геометрия, физика, тарих, география, матур язу, дин белеме, педагогика дәресләре алып тора. Татар теле, миссионер укытучылар төркеменең каршылыгы нәтиҗәсендә, уку планыннан төшереп калдырыла [Ханбиков, с. 42–49].

Барлык әзерлек эшләре тәмамлануга карамастан, Казан укытучылар мәктәбенә берничә ел буена бер генә укучы да кабул ителми. Татар җәмәгатьчелеге, балаларның руслашуыннан куркып, укытучылар мәктәбенә бойкот игълан итә. Казан мәгариф округы, В.В. Радловның да зур тырышлыгы белән, бары тик 1871–1872 елларда гына Казан мәдрәсәләрендә дүрт рус сыйныфы ачуга ирешә. Беренче рус сыйныфы 1871 елда «Госмания» мәдрәсәсендә эшли башлый. Анда 18 укучы кабул ителә [Ханбиков, с. 44].

1873 елның 1 гыйнварында Казанда кызлар өчен татар мәктәбе ачыла. Ләкин укучылар аз (4 кенә) булу сәбәпле 1874 елның 1 гыйнварында ул ябыла [Штернберг, с. XXI; Ханбиков, с. 3].

Казан шәһәрендә татар мәктәбен ачу омтылышы уңышсызлыкка очраганнан соң, В.В. Радлов бу өлкәдәге эшчәнлеген авыл мәдрәсәләренә күчерергә була. 1881 елда Чистай мәдәрәсәсендә рус сыйныфы ачылу бу стратегиянең уңышлы булырын вәгъдә итә. Татар һәм башка милләт авылларында шундый мәктәпләр 1877 елда Мамадыш өязенең Яңа Шөнәр авылында [НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 13147, л. 4, 24], 1978 елда, икенче указлы мулла Мөхәммәт-Сафа Биккенин тырышлыгы белән, хәзерге Татарстан Республикасының Апас районы Чирмешән авылында [Биккенин, б. 8–15], Самара губернасының Иске Үрембаш [НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 13147, л. 24], Уфа губернасының Бөре өязе Аканеево, Талбазы авылларында – башкорт мәктәпләре, Чистай мәдрәсендә [НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 13147, л. 39] рус сыйныфлары эшли башлый.

В.В. Радлов татар җәмәгатьчелегенең, беренче чиратта, дини даирәнең татар укытучылар мәктәбенә карата тискәре мөнәсәбәтен бераз булса да йомшарту максатында ислам дине буенча керү имтиханын билгели. Россия мәгариф министрлыгына бу турыда шикаять язган миссионерларга, Казан мәгариф округы җитәкчесе П.Н. Масленников исеменә язган аңлатмасында В.В. Радлов ислам бары тик мөселман диненә каршы көрәшү максатында гына укытылачак дип ышандыра [Казанская татарская учительская школа, с. 5].

Киресенчә, министрлык полиция идарәсенә һәм муллаларга мондый мәктәпләрдә һәм рус сыйныфларында укучыларга иң яхшы шартлар тудыру һәм аларны мөмкин кадәр тизрәк руслаштыру өчен

кулдан килгәннең барысын да эшләү турында күрсәтмәләр җибәреп тора [НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 10290].

Патшаның 1882 елның 5 февралендәге указында, В.В. Радловның татар мәктәпләре инспекторы исеменнән 1882 ның 15 апрелендә шәһәр муллаларына һәм мәдрәсә мөдирләренә җибәрелгән рәсми циркулярында мәктәпләрнең дәүләт контроле астында булуы бәян ителә, татар мәктәпләре инспекторына ул сораган мәгълүматларны биреп барырга кушыла. 1882 елның 22 декабрендә В.В. Радлов, губернатор Л.И. Чернышев белән бергәләп, шәһәрнең барлык мәдрәсәләрен йөреп чыга, дин әһелләренә, мөдәррисләргә, шәкертләргә, җыелган халыкка барлык мәктәпләрнең дә Халык мәгарифе министрлыгына буйсынуы, уку-укытуга караган барлык эшләрнең дә инспектор тарафыннан башкарылачагы турында әйтелә [Загидуллин, 1992, с. 60]. В.В. Радлов татар мөселманнарының мәдрәсәләрдә рус телен көчләп укытуга каршы язылган шикаяте уңаеннан язылган аңлатмасында беркайда да, бернинди дә көчләп укыту юк дип белдерә [НА, ф. 92, оп. I, д. 15539, л. 6–7]. Шунысы бик гыйбрәтле: И.К. Заһидуллинның сүзләренә караганда, әлеге хәлләрдән соң татар мәктәпләре инспекторы дин әһелләре белән бәйләнешләрен өзә, алардан муллаларның шәхси мәгълүматларын һәм мәдрәсәләрдәге вазгыять турында хисап таләп итеп торуын туктата [Загидуллин, 1992. с. 60–83; НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 15519, л. 4–7; НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 15539, л. 6–7].

Казан укытучылар мәктәбе чын-чынлап бары тик 1876 елның 13 сентябрендә генә эшли башлый. В.В. Радлов кадрлар әзерләү эшен укытучылар коллективы туплаудан башлый. Җирле халык ышанычын казану өчен, татар укытучылары коллективын булдырырга кирәк була. Бу эшкә Габдел Каюмов (Каюм Насыйри), Шиһаб Әхмәров, Ибраһим Терегуловлар алына. В.В. Радлов Татар укытучылар мәктәбенең беренче инспекторы итеп Гали Мәхмүдовны билгели, үзе уку-укыту бүлеген җитәкли. В.В. Радлов шул заманның Казан шәһәрендәге барлык интеллектуаль көчләрен Татар укытучылар мәктәбендә эшләүгә җәлеп итәргә омтыла. Күренекле татар тарихчысы, дин эшлеклесе Ш. Мәрҗани, мәсәлән, ислам дине дәресләрен алып бара, танылган мәгърифәтче Каюм Насыйри укыту методикасына өйрәтә һәм студентларның педагогик практикасын җитәкли. В.В. Радлов педагогика, дидактика, тарих фәннәрен укыта [Шәрәфетдинов, б. 73; Казанская татарская учительская школа, с. 35–37].

Болардан тыш, укытучылар мәктәбендә Казан университетының күренекле галимнәре В.А. Богородицкий, П.Ф. Ломоносов, Л.М. Любимов, П.В. Траубенберг, С.А. Волберг, Д.Н. Адо, М.Г. Лексин, М.А. Васильев, А.Н. Анастасиев һәм башкалар эшли.

В.В. Радлов Татар укытучылар мәктәбенә татар зыялылары белән аралашкан, татар мәдәниятенә хөрмәт белән караган шәхесләрне дә тартырга омтыла. Шундыйлардан шул заманда Казан әдәбият сөючеләренә яхшы таныш булган рус шагыйре, татар язучыларының, шул

исәптән Г. Тукайның әсәрләрен рус теленә тәрҗемә иткән П Радимовны күрсәтергә мөмкин.

Казан Татар укытучылар мәктәбе 1876 дан башлап 1917 елга кадәрге эшләү дәверендә 389 рус теле укытучысы әзерләп чыгарган [Казанская татарская учителькая школа, 2005, с. 5; Закирова, с. 32]. Аны тәмамлаучылар Казан губернасының һәм соңрак ТАССРның халык хуҗалыгы тармакларында уңышлы хезмәт куялар. Алар арасыннан танылган профессорлар Мозаффар Мөштәри, Гыйлем Камай, Фатих Мөхәммәдьяров, күренекле тел галимнәре Мөхетдин Корбангалиев, Мөхәммәтхан Фазлуллин, Гыйбадулла Алпаров, татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакый, беренче татар пролетар язучысы Гафур Коләхмәтов, шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй, журналист Хөсәен Ямашев, татар пролетар «Урал» газетасын оештыручы Галимҗан Сәйфетдинов, дәүләт эшлеклесе Садри Максуди һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин [Казанская татарская учительская школа, 2005].

Татар мәктәпләре өчен махсус дәреслекләр, программаларның булмавы уку-укыту эшендә зур кыенлыклар тудыра. В.В. Радлов 1872–1879 елларда яңа ачылган Татар укытучылар мәктәбе өчен заман таләпләренә җавап бирә торган дәреслекләр әзерләп бастыра.

**Рус теле һәм чит тел дәреслекләре.** Күрүебезчә, Казан укытучылар мәктәбендә рус теле укытуга аеруча зур игътибар бирелә, чөнки әлеге мәктәпнең максаты мөселман татар балалары укый торган мәдрәсәләр өчен рус теле укытучылары әзерләүдән гыйбарәт була. Моңа кадәр Россиядә рус теле бары тик рус балаларына гына укытылып килгәнлектән, В.В. Радлов бу мәктәпләрдә Европада киң таралган чит телләр укыту методикасын кулланырга була [Закирова, с. 14]. Татар укытучылар мәктәпләре өчен аның тарафыннан төзелгән рус теле дәреслекләре, Россиядә беренче буларак, милли аудитория шартларын күздә тотып язылган беренче уку-укыту кулланмалары булып саналалар [Радлов В. Грамматика русского языка, 1878; Радлов В. Первая книга для чтения, 1874; Радлов В. Разговорные уроки по картинкам, 1878]. В.В. Радлов, форсаттан файлаланып, татар мәктәпләре өчен чит тел (немец теле) дәреслеге дә язарга була. Ул аны Европада шул заманда бик актив кулланылган Лувье методына нигезләнеп яза. Әйтергә кирәк, Радловның бу дәреслеге кулланылган методы ягыннан Россиядә беренче тәҗрибә генә түгел, татар мәктәпләрен күздә тотып язылган бердәнбер чит тел дәреслеге дә булып исәпләнә [Радлов В. Учебник немецкого языка по методу Лувье, 1872].

В. Радлов Казан укытучылар мәктәбе өчен татар теле дәреслекләрен дә үзе төзи. Шундый дәреслекләрнең берничәсенә күз салыйк:

**«Белек»** – кече яшьтәге мәктәп балалары өчен төзелгән беренче дәреслек. Ул 1872 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыга. Дәреслек «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» сүзе белән ачылып китә. Аллаһның барлыгы һәм берлеге аңлатыла [Радлов, Белек, б. 3]. Китапның эпиграфы да уңышлы сайланган. Ул төрки халыкларның күпчелеге өчен таныш «Котадгу белег» әсәреннән

алынган: «Белек кадерен белек белүр, окуш сүз кешидин ядкәр калур» (Белемнең кадерен белемле белер, язылган сүз кешедән ядкяр булып калыр) [Радлов, Белек, б. 4].

Дәреслек казан татарлары шивәсендә балаларга аңлаешлы итеп, автор әйтүенчә, халык сөйләшә торган телдә гади җөмләләр белән язылган. Бу хикәяләр, мәкаләләр җыентыгы алты бүлектән тора: үгет-нәсыйхәтләр бирүче гыйбрәтле хикәяләр; үсемлекләр, хайваннар һәм минераллар турындагы хикәяләр; мәсәлләр; Вакыт, Жир, Кояш, Ай турындагы хикәяләр; география, рус тарихына караган мәкаләләр. Соңгы бүлектә Ольга, Олег, Ярослав, Владимир Мономах турындагы, Мәскәүгә нигез салыну, Явыз Иван, Борис Годунов, Минин һәм Пожарский, Иван Сусанин, Петр I һәм Екатерина II хакындагы хикәяләр урын ала. Бу дәреслекнең максаты – мәктәп балаларын укырга, язарга һәм әдәби телдә дөрес итеп сөйләшергә өйрәтү. Моннан тыш, дини-әхлакый тәрбия бирү дә күздә тотыла. Дәреслекнең күп кенә уңай яклары булуга карамастан, күпчелек мәдрәсәләр, христиан дине йогынтысыннан куркып, әлеге әсбапны файдаланудан баш тарталар. Күренекле татар шагыйре Габдулла Тукай үзенең «Мәктәпләрдә милли әдәбият дәресләре» (Казан, 1910) дигән басмасын әзерләгәндә, В.В. Радловның татар балалары өчен дәреслек төзүдәге уңай тәҗрибәсен киң файдалана. Шагыйрь нәкъ менә В.В. Радлов үрнәгенә ияреп, үзенең дәреслегенә татар халкының күренекле шәхесләре, Казан ханлыгы тарихы, Явыз Иван, соңгы патшабикә Сөембикә һ. б. турындагы язмаларны кертә. Кайбер очракларда ул В.В. Радлов китабындагы әсәрләрне үзенекендә дә куллана. Мәсәлән, «Белек»тә бирелгән «Төлке белән виноград» хикәятен файдаланып, шул ук исемдәге шигырь дә язып, үзенең дәреслегенә урнаштыра. Татар әдибе М. Гафури В.В. Радлов җыентыгындагы «Кеше белән аю» әсәре буенча үзенең «Адәм белән аю» вариантын иҗат итә [Закирова, с. 60–61; Хаҗиев, б. 87]. Беренче мәртәбә В.В. Радлов һәм М. Гафури тарафыннан кулланылган бу әсәр бүгенге көнгә кадәр, татар фольклоры үрнәге буларак, балалар өчен нәшер ителә торган җыентыкларда урын алып килә.

В.В. Радлов «Белек» дәреслеге белән татар телен, әдәбиятын укыту методикаларына гына түгел, бәлки татар лингводидиктикасы, әдәбияты белеме, татар фольклористикасы фәннәренең үсешенә дә зур этәргеч бирә. Авторның «Белек» дәреслеген төзүдәге тәҗрибәсе аның 1874 елда басылып чыккан «Первая книга для чтения» китабында да [Радлов, 1874, с. 171] файдаланыла. Әлбәттә, бу кулланма татар теле дәреслеге генә түгел, бәлки балаларны рус теленә өйрәтү барышында, текстны рус теленә тәрҗемә иткәндә ярдәмче чара буларак кына кулланыла. Ул Казан укытучылар мәктәбенең беренче сыйныфында укучы булачак рус теле мөгаллимнәрен рус телле текстларны тиз укырга өйрәтүгә, аларның русча сөйләмнәрен баетуга, сүз байлыгын арттыруга багышлана. В.В. Радлов тарафыннан татар телендә бирелгән материаллар укучыларны ана теле мохите

белән бәйләргә ярдәм итә, миссионерлар теләгенә каршы килеп, кешене үзенең ана теленнән мәңгелеккә аерудан саклап кала [Закирова, с. 64–67]. Кулланмада тәкъдим ителгән биремнәрнең укучыларның сүзлек байлыгын арттыруда, татар әдәби телен үзләштерүдә уңай нәтиҗәләргә китерүе шик уятмый. «Белек» хрестоматиясендәге кебек үк, бу кулланмада да тәрҗемә итү өчен бирелгән текстлар алга таба үзләштерү максат итеп куелган тематиканы үз эченә ала. Мәсәлән, беренче дәрестә мәктәп-школа темасын үткәндә, балаларның сыйныфтагы уку кирәк-яраклары, сыйныф җиһазларының исемнәрен, татар теленә таянып, рус телендә белүләре максат итеп куела. Кулланма авторы рус теле лексикасын үзләштерүгә юнәлтелгән эш алымнарын, татар телендә бирелгән әдәби текстлар («Бала белән күбәләк», «Мәктәпкә чакыру» һ.б.) белән тирәнәйтергә омтыла, әлеге максатка яңа сүзләрне укучы сөйләмендә куллану күнекмәләрен активлаштыру юлы белән ирешелә. Йорт хайваннары темасы да шул рәвешле үтелә. Биредә дә дәреслек авторы татар укучысының игътибарын рус телендә күпчелек исемнәрнең төп (нейтраль) формадан тыш еш кына эмоциональ-экспрессив кушымчалар белән кулланылуына да юнәлтә: корова-коровушка, кошка-кошечка... Әлеге кулланмада В.В. Радлов үзен талантлы методист итеп күрсәтә: һәр очракта балаларга үзләштерү өчен тәкъдим ителә торган материалларны үзенең методик киңәшләре белән тулыландырып бара.

Татар җәмәгатьчелеге В.В. Радловның «Белек» хрестоматиясен, нигездә, хуплап каршы ала. Бары тик дин әһелләренең бер өлеше генә бу китапны «миссионерлар мәкере» дип кабул итә, мәдрәсәләрдә куллануны катгый рәвештә тыя.

**«Хисаблык».** В.В. Радловның өченче китабы – «Хисаблык» – арифметика курсын үз эченә ала. Автор бу дәреслеген төзегәндә, укучыларны алгебра курсына әзерләү максатын да куя. Шунлыктан, алдагы тәҗрибәләр күрсәткәнчә, Казан Татар укытучылар мәктәбе укучыларының югарырак сыйныфларда алгебра фәнен рус телендә язылган дәреслек буенча укыганда да кыенлык кичермәүләре ачыклана.

Әлеге дәреслекләрнең сыйфаты һәм үзенчәлекләре турында Н. Ильминский түбәндәгеләрне яза: «Книги написаны на татарском языке, чисто народном, лишь с незначительной прибавкой некоторых арабских слов, сделавшихся уже общеизвестными для всех магометан благодаря широко распространенной в народе магометанской грамотности, и притом с правильною орфографией, а не по местному народному произношению; алфавит открыл этим книгам доступ во все магометанские селения не только ближайших к Казани губерний, но и отдаленных местностей Сибири; им предстоит обширный круг читателей» [Ильминский, с. 370–374].

В.В. Радлов язган «Белек» дәреслегенең уңыш казануы кулланма авторының татар әдәбияты, балалар өчен махсус төзелгән мәҗмугалар тарихын тирән күзаллавы турында сөйли. Белгәнебезчә, XIX гасыр башларында кульъязма китаплар урынын Казан

университеты типографиясендә басылган әдәби һәм уку әсбаплары да ала башлый. В.В. Радлов дәреслекләре бу чордагы башка авторларныкыннан энциклопедик характерда булулары белән аерылып тора. Ул үзенең дәреслекләре белән мөселман татар мәктәпләренең дөньяви мәктәпләргә күчү этабын башлап җибәрә [Загидуллина, 1992, с. 105–118]. Танылган татар педагогы В. Хаҗиев «Белек» китабын укучыларны әйләнә-тирә дөнья белән таныштырып, аларның иҗади фикерләвен үстерергә ярдәм итә торган беренче басма дәреслек, дип бәяли. [Хаҗиев, б. 80]. Дәреслекләр авторының замандашы профессор И. Готвальд «Белек» җыентыгы моңарчы татар әдәбиятында булмаган өлкәләрне ачып җибәрәчәк, дип өметләнә [Каримуллин, 1983, с. 249. Күренеле татар әдәбиятчысы М.Х. Гайнуллин аны татар дидактик әдәбиятының матур үрнәге дип атый [Гайнуллин, б. 196].

В.В. Радловның Казандагы башка мөселман уку йортларыннан аерылып торган Татар укытучылар мәктәбе белән бәйле эшчәнлеген татар дин әһелләре дә, татарларны руслаштыру һәм христианлаштыруны төп максат иткән миссионерлар да уңай бәяләмиләр. Билгеле булганча, дин әһелләре генә түгел, бәлки татар халкының күпчелеге мәктәп-мәдрәсәләрнең Россия мәгариф системасына күчүен татарларның ислам идеологиясеннән христиан идеологиясенә күчүе дип кабул итәләр.

Миссионерлар да инспекторның Казан Татар укытучылар мәктәбен ачуга бәйле эшчәнлеген кабул итмиләр. Ул вакытта татарларны руслаштыру өлкәсендә актив эшчәнлек күрсәткән Е. Малов үзенең көндәлекләрендә В.В. Радловны татар балаларын Россиягә түгел, бәлки, фән алга киткән дигән булып, Көнбатыш Европага мәхәббәт тәрбияләүдә гаепли. Аны шундый җаваплы эшкә куеп, Россия хөкүмәте бик зур хата ясады, ул башкарган эш яхшылыктан бигрәк зыян гына китерде, дип бәяли [Мурадов, с. 152–160].

Татар зыялылары В.В. Радловның Казанда мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеген киресенчә хуплыйлар. Мәсәлән, Г. Исхакый 1909 елда «Әлислах» газетасының 66 нчы санында Чыңгыз псевдонимы белән басылган мәкаләсендә болай дип яза: «Василий Васильевич Радловның Татар укытучылар мәктәбе булдыруга багышланган эшчәнлеге татар мәгарифе үсешендә мөһим адым булып санала: аның бу өлкәдәге эшчәнлеге белән татар мәгарифе дини мәктәпләрдән дөньяви уку-укыту системасына таба юнәлеш ала, татарларда хатын-кызларга да белем бирү буенча беренче адымнар ясала, татар мәктәпләрен дөньяви дәреслекләр белән тәэмин итү чоры башлана, татар мәктәпләрендә татар, рус, чит телләр укыту методикасы фәннәренең нигез ташлары салына» [Исхакый, 1909, № 66].

*(Дәвамы бар)*

**Әдәбият**

*Ахметова-Урманче Ф.В.* По следам В.В. Радлова // Фәнни эзләнүләр юлында. Казан: Фикер, 2000. Б. 205–218.

*Әхмәтова-Урманче Ф.* Татар эпосы. Дастаннар. Казан: Раннур, 2004. 640 б.

*Әхмәтҗанов М.И.* Илдан белән Гөлдан дастаны хакында // Әдәби мирас. Икенче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. Б. 44 .

*Әхмәтҗанов М.И.* Себер ханлыгына кагылышлы билгесез татар чыганаклары // Фән һәм тел. 2003. № 2.

*Байрамова Л.К.* Научные контакты В.В. Радлова, И.А. Бодуэн де Куртенэ и Н. В. Крушевского // В.В. Радлов. Духовная культура тюркских народов. Первая международная интернет-конференция (21 марта 2012 года): Сборник трудов. Казань: Казанский университет, 2012. С. 16–18.

*Бартольд В.В.* Памяти В.В. Радлова. (1837–1918) // Бартольд В.В. Сочинения. Т. 9 (Работы по истории востоковедении). М.: Наука, 1977. Б. 175–186.

*Биккенин Р.* Мухаммед-Сафа Биккенин и Василий Васильевич Радлов: Из истории первого в Казанской губернии татарского начального училища // Гасырлар авазы = Эхо Веков. 2006. № 1. Б. 8–15.

*Бодуэн де Куртенэ И.А.* Заметки на полях сочинения В.В. Радлова (1909) // Живая Старина. 1909. Вып. 3. С. 191– 205.

*Бодуэн де Куртенэ. И.А.* Николай Крушевский, его жизнь и научные труды // Бодуэн де Куртенэ И.А. Избранные труды по общему языкознанию. Т. I. М., 1963. С. 146–202.

*Валеев Р.М.* Казанское востоковедение: истоки и развитие (XIX – 20-ые гг. XX в.). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1998. 180 б.

*Гайнуллин М.Х.* Татарская литература XIX века. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. С. 307.

Джаным. Антология сибирских татар / Сост.: Ф.В. Ахметовой-Урманче и А.В. Преловского. М.: Новый Ключ, 2007. С.186–189.

*Загидуллин И.К.* Составлен со знанием дела, но имеет ряд существенных недостатков (Проект инструкции инспекторам татарских, башкрских, киргизских школ. 1876 г. // Гасырлар Авазы = Эхо веков. 2009. № 2. С. 47–52.

*Загидуллин И.К.* Татарская школа и русификаторская политика царизма во второй половине XIX в. // Народное просвещение у татар в доoктябрьский период. Казань, ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1992. С. 60–68.

*Загидуллина Д.Ф.* Из истории преподавания татарской литературы в дооктябрьский период // Народное просвещение у татар. Казань ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1992. С. 105–118.

*Закирова Л.И.* Василий Васильевич Радлов. Казанский период деятельности. Казань: Ихлас, 2013. С. 291.

*Ильминский Н.* Новые учебные руководства для татар магометан г. Радлова // Журнал Министерства народного просвещения. 1873. С. 370–374.

*Исхаки Г.* Василий Васильевич Радлов // Әлислах. 1909. № 68.

Казанская татарская учительская школа в 1976–1917 гг.: Сборник документов и материалов. Казань, 2005. 256 б.

*Каримуллин А.Г.* Татарская книга пореформенной России. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. 320 б.

*Катанов Н.Ф.* Предания тобольских татар о прибытии в 1572 г. мухаммеданских проповедников в г. Искер // Ежегодник Тобольского губернского музея. Тобольск, 1897. Вып. 7. С. 51–61.

*Кононов А.Н.* В.В. Радлов и отечественная тюркология // Тюркологический сборник. М.: Наука, 1972. С. 7–15.

*Махмутова А.Х.* Становление светского образования у татар (Борьба вокруг школьного вопроса 1861–1917). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1982. С. 82.

*Мурадов В.* Ефим Малов о Ш. Марджани, К. Насыри, В.В. Радлове // Гасырлар Авазы = Эхо Веков. 1999. № 1/2. С. 152–160.

НА РТ (Татарстан Республикасының милли архивы), ф. 92, оп. I., д. 10290.

НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 10290, л. 1–2.

НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 13147, л. 24.

НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 13147, л. 4, 24.

НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 13147, л. 39.

НА РТ, ф. 977, оп. ИФФ, д. 1249, л. 1–49.

НА РТ, ф. 977, оп. ИФФ, д. 1249, л. 21.

НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 15519, л. 4–7.

НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 15539, л. 6–7.

*Радлов В.В.* Белек. Балалар укыр өчен чыгарылган китап. Казан: Казан ун-ты типографиясе. 1872. 232 б.

*Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи. Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар / сост. д-р филол. наук Ф.Ю. Юсупов). Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 517 с.

*Радлов В.В.* Первая книга для чтения – Казань: Тип. Казан. ун-та, 1874. 171 с.

*Радлов В.В.* Грамматика русского языка, составленная для татар Восточной России. Часть. I. Этимология. Казань: Тип. Казан. ун-та, 1878. 114 с.

*Радлов В.В.* Материалы для разговорных уроков по способу наглядного обучения инородческих школ. Казань, 1978. 87 с.

*Радлов В.В.* Учебник немецкого языка по методу Лувье. Казань, 1872. 110 с.

*Радлов В.В.* О языке куманов по поводу издания куманского словря. СПб.: Тип. Имп. Академии наук. 1884. 53 с.

*Самойлович А.Н.* Радлов как турколог (речь, произнесенная в публичном заседании Российской Академии Наук 12 мая 1919 г.) // Новый Восток. Кн. вторая. М., 1922. С. 707–712.

*Тенишев Э.Р.* В.В. Радлов – фонетист и грамматист// Тюркологический сборник. М.: Наука, 1972. С. 32–41.

*Фәхретдинов Р.* В.В. Радлов җәнапларының илле еллык (1859–1909) бәйрәме // Шура. 1909. № 10.

*Ханбиков Я.* В.В. Радлов (1837–1918) // Русские педагоги Татарии и их роль в развитии просвещения и педагогической мысли татарского народа. Казань: Министерство просвещения РСФСР; КГПИ, 1968. С. 42–49.

*Хаҗиев В.* Талантлы тюрколог // Мирас. 2000. № 4. Б. 77–82.

*Шәрәф Г.* Төрек телләренең олуг галиме В.В. Радлов // Кояш. 1917. № 5, 10 гыйнвар.

*Шәрәфетдинов З.Т.* Казан лингвистика мәктәбе һәм аның педагогик традицияләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 103.

*Юсупов Ф.Ю.* В.В. Радлов – выдающийся тюрколог России // Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре: фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы. Казан: Ихлас, 2011. Б. 136–185.

*Юсупов Ф.Ю.* В.В. Радлов – великий тюрколог России // Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племен... Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. С. 3–29.

*Юсупов Ф.Ю.* В.В. Радлов – основоположник Российской филологической науки // Научный Татарстан. 2012. № 2. С. 173–195.

*Юсупов Ф.Ю.* В.В. Радлов яркий представитель Казанской лингвистической школы // В.В. Радлов и духовная культура тюркских языков. Первая

Международная интернет конференция. Сборник трудов. ИФИ. 21 марта 2012. Казань, 2012. С. 4–7.

*Юсупов Ф.Ю.* Деятельность В.В. Радлова в формировании российской тюркологической науки // «Занкиевские чтения»: материалы Всероссийской научно-практической конференции. Тобольск: ТГСПА им. Д.И. Менделеева, 2013. С. 152–157.

*Юсупов Ф.Ю.* В.В. Радлов – основоположник тюркологической науки России. Международный тюркологический симпозиум, посвященный памяти выдающегося тюрколога, доктора филологических наук, профессора, академика РАН Эдхяма Рахимовича Тенишева. Сборник статей. Казань, 2013. С. 85–88.

*Gronbech K.* Codex Cumanicus. Kopenhagen, 1936.

*Radloff W*. Vergleichende Grammatik der Türksprachen. Erster Teil. Phonetik der nördlichen Türksprachen» . Leipzig, 1882. 77 s.

*Yusupov Ferit Yusupoviç.* «Rusya Türkolojisinin Kurucusu – V.V. Radlov» (Çev. Fatih Ekici), Atatürk Üniversitesi Edebiyat Fakültesi Sosyal Bilimler Dergisi. S. 52, Erzurum 2014. S. 291–311.

*Yusupov Ferits Yusupovich*. Contemporary issues of textual analysis of turkic-tatar literary monuments of western Siberia (2013, World Applied Sciences Journal, 27 (13 A). P. 492–496).

***Йосыпов Феритс Йосыф улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор*

УДК 9-05

***Л.Р. Мортазина***

# ГАЛИМӘТЕЛБӘНАТ БИКТИМЕРИЯ – МӘГЪРИФӘТЧЕ ҺӘМ ПЕДАГОГ

Данная статья посвящена исследованию жизни и педагогического наследия татарской просветительницы и писательницы Галимательбанат Биктимерии. В статье выделены основные идеи Биктимерии в области воспитания, размышления о роли женщин в сохранении семейных ценностей и благополучного климата в семье, о ее месте в татарском обществе. Анализированы труды педагога, посвященные различным аспектам жизни мусульманского общества конца XIX – нач. XX в. – вопросам женского просвещения, отношений в семье, воспитания детей и матерей, правовому положению женщины в семье и социуме, расширения прав наследования и др.

**Ключевые слова:** просветительница, писательница, педагогическое наследие, воспитание, женское просвещение, семья, Галимательбанат Биктимерия.

This article is devoted to the study of the life and pedagogical heritage of the Tatar educator and writer Galimatelbanat Biktimeria. The article highlights the main ideas of Biktimeria in the field of education, reflections on the role of women in maintaining family values and a good relationship in the family, about her place in Tatar society. The works of the teacher are analyzed, devoted to various aspects of the life of the Muslim society of the late 19th – early 20th centuries – issues of women's education, the development of family relations, the upbringing of children and mothers, the preservation of women's rights, etc.

**Keywords:** educator, writer, pedagogical heritage, education, women's education, family, Galimatelbanat Biktimeria.

XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында татар җәмгыятендә күзәтелгән яңарыш хәрәкәте мәдәният, мәгариф үсешенә зур йогынты ясый. Бу чорда хатын-кызлар арасында да мәгърифәтчелек фикерләре киң тарала башлый, хатын-кызның җәмгыятьтәге урынын билгеләү, аны укыту, тәрбияләү мәсьәләләренә игътибар арта. Нәтиҗәдә кызлар өчен моңарчы күрелмәгәнчә яңача мәктәпләр күпләп ачыла, алар өчен махсус дәреслекләр төзелә, заман рухына туры килә торган мөгаллимәләр әзерләнә, кыз балаларны тәрбияләү, һөнәр өйрәтү иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсенә әверелә. Хатын-кызлар арасында кулына каләм алып, әдәби әсәрләр иҗат итүчеләр, газета-журналларда хатын-кыз проблемаларын яктыртып мәкаләләр язучылар күзәтелә башлавы да шушы дәвергә карый. «Татар әдәбиятының беренче карлыгачлары» дип бәя бирелгән әдибәләр хатын-кызларның хәлләрен, зар-моңнарын, авыр тормышларын тасвирлаганнар, бу хәлдән чыгу юлларын эзләгәннәр, башка ханымнарга ярдәм итәргә тырышканнар. Хатын-кызның гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге хәлен яхшырту, хокукларын яклау һәм саклау һ.б. бик күп мәсьәләләрне хәл итүдә төп

юлның аң-белемдә икәнлеген яхшы аңлаган мәгърифәтче ханымнар үзләренең әсәрләрендә, язмаларында шушы теманы күтәргәннәр. Тик җәмгыять, җәмәгатьчелек хатын-кызларның әдәбиятка килүләренә, ирләр белән беррәттән матбугатта язышуларына бик үк әзер булмый әле. Алар язган китапларның күбесе басылмый, бөтенләй югалу очраклары да була [бу хакта тулырак: Татар..., б. 4–5].

Үзләре язган әсәрләрне аерым китап итеп бастырып чыгарган хатын-кыз мәгърифәтчеләрнең тәүгеләреннән Хәнифә Гыйсмәтуллина, Хәбирә Насыйрия, Галимә Рәхмәтуллина һәм Галимәтелбәнат Биктимерияне күрсәтергә мөмкин [Гайнуллин, 1988, б. 3]. Аларның әсәрләрендә хатын-кызларга белем һәм тәрбия бирү, балалар тәрбиясен яхшырту, гаиләдә һәм җәмгыятьтә ханымнарның тоткан урыны һ.б. бик күп мәсьәләләр күтәрелә. Хатын-кызларның гаиләдәге хәлен яхшыртуга аеруча зур игътибар бирелә, шул чор өчен моны тормышка ашыруның төп шартлары һәм юллары билгеләнә. Болар – хатын-кызның гаиләдәге урынын, дәрәҗәсен күтәрү, моның өчен аларның гаиләдәге бурыч һәм вазифаларын, хокукларын аңлату; әниләрнең бала тәрбияләүдәге мөмкинлекләрен һәм бурычларын күрсәтү («бала тәрбиясе аналар кулында»); килен-каенана мөнәсәбәтләрен җайлау һ.б.

Татар вакытлы матбугаты барлыкка килгәнче үк кулына каләм алган, хатын-кыз, балалар һәм гаилә тәрбиясенә багышланган китаплар бастырып чыгарган мәгърифәтчеләр арасында мәшһүр педагог һәм әдибә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар иҗтимагый, әдәби һәм педагогик фикерләре үсешендә тирән эз калдырган Галимәтелбәнат Биктимерия (1876–1906) дә бар.

Галимәтелбәнат Лотфулла кызы Биктимерия (Биктимерова) 1876 елның ноябрендә Казан губернасы Чар өязе (Татарстанның хәзерге Әтнә районы) Кышлау авылында[1] имам һәм ахун Лотфулла бине Сибгатулла бине Габделкадыйр әс-Сөләймани гаиләсендә дөньяга килә. Бар гомерен милләтнең киләчәге булган балалар тәрбиясенә багышлаган Лотфулла хәзрәт халык арасында «хәсән холыклы, гакыллы һәм галим» зат буларак билгеле була [Фәхреддин, 2010, б. 334]. Ул, алдынгы фикерле педагог буларак, кыз балаларны тәрбияләүгә аеруча зур әһәмият биргән, аларга ир балалар мәктәпләрендә укытыла торган фәннәрне өйрәткән. Лотфулла хәзрәтне, хаклы рәвештә, авыл җирлегендә кыз балаларны җәдитчә укытуга башлап юл салучыларның берсе дип санарга мөмкин [Биктимирова, 2002, б. 31]. Яңача укытудагы тәҗрибәне ул үз кызларын укытып туплаган, аларга заманы өчен бик яхшы, төпле белем биргән [Фәхреддин, 2010, б. 334], аның хәтта мөгаллимәләр әзерләү өчен махсус укыту планы – программалары, кулланмалары булган, «һәм шулай үзенә күрә бер хосусый мәктәп – дарелмөгаллимат булдырган» [Мәхмүтова, 2012, б. 24].

[1] Р. Фәхреддин авылны элеккеге исеме белән Котаймас дип күрсәтә.

Лотфулла ахунның үз кызларының тәрбиясенә җитди каравы көтелгән нәтиҗәләрне биргән – Р. Фәхреддин сүзләренә караганда, ул аларның «һәммәсен гыйлем вә мәгълүмат сахибәләре итеп җитештерде вә һәммәсе дә мөгаллимәлек вазифаларын башкарып тордылар» [Фәхреддин, 2010, б. 438–439]. Кызы Гайшә Уфада кызлар мәктәбендә мөгаллимәлек итә, ахун Җиһангир Абызгилдинның җәмәгате буларак та билгеле; Гафифә Алмата шәһәрендә имам Хөсәен никахында булып, шулай ук гомерен кыз балаларга тәрбия бирүгә багышлый [Фәхреддин, 2010, б. 335]. Фатыйма Касыйм шәһәрендә имам Фатыйх Дәүликамовның җәмәгате була [Фәхреддин, 2010, 438].

Башлангыч белемне атасыннан алган Галимәтелбәнат 12 яшьләрендә үзлегеннән гарәп телен, шәригать белемен өйрәнә башлый. Гарәп әдәбияты белән таныша, фарсы теле белән кызыксына, хисап, география фәннәре буенча башлангыч гыйлем ала [Әмирхан, 1907, б. 65]. Гарәп телен бик яхшы үзләштерүе аның соңрак язган китапларында да чагылыш таба – үз фикерләрен раслау өчен, ул еш кына гарәп телендәге хәдисләрдән өзекләр китерә, гарәп-фарсы алынмаларын бик мул куллана. 16 яше тулу белән, Галимәтелбәнат мөгаллимәлек эшенә керешә, әтисе мәктәбендә кыз балалар укыта, бу өлкәдә тәҗрибә туплый [Мәхмүтова, 2012, б. 24].

1895 елда кыз Рязань губернасының Касыйм өязе (хәзерге Рязань өлкәсенең Касыйм районы) Яубаш авылы имамы Мөхәммәдгариф бине Биктимергә кияүгә чыга һәм ире гаиләсенә күченеп китә [Фәхреддин, 2010, б. 438]. Яңа урында үзенең педагоглык эшен дәвам итә, балачактан озата килгән хыялын тормышка ашыруга ирешә – кызлар өчен җәдит мәктәбе ачып җибәрә, шунда укыта. Күп тә үтми, бу мәктәп тирә-юньдә алдынгы, үрнәк кызлар мәктәпләренең берсе булып китә.

Г. Биктимерия, яшь булуга карамастан, кызлар укыту эшендә шактый тәҗрибә туплаган гыйлемле мөгаллимә була. Хатын-кызлар мәгарифенең үсешенә бары тик заманча белем алган, педагогиканың нәзари һәм гамәли закончалыкларын белгән, шул ук вакытта укыту һәм тәрбиядә ислам кыйммәтләренә һәм милли традицияләргә таянып эш иткән укымышлы педагоглар ярдәмендә генә ирешергә мөмкин булуын яхшы аңлаганга, ул мөгаллимәләр әзерләү өчен ике еллык кызлар мәктәбе ачарга карар кыла, аның уку программаларын әзерләү эшенә керешә, анда, һичшиксез, география, табигать, тарих кебек дөньяви фәннәрне кертергә кирәк, дигән фикергә килә [Гайнуллин, 1988, б. 42]. Тик бу карар, кызганычка каршы, тормышка ашарга өлгерми кала – 1906 елның 29 ноябрендә ул бакыйлыкка күчә [Фәхреддин, 2009, 142].

Г. Биктимерия үзен, иң беренче чиратта, педагог-практик, мөгаллимә буларак таныта. Мәгърифәтчелек эшчәнлегенең икенче бер яссылыгы, һичшиксез, хәбәрчелек (журналистлык) эше. Ул – XX гасыр башында татар матбугатында исеме күренгән гүзәл затларыбызның тәүгеләреннән берсе. Татар телендә беренче басмалар дөнья

күрә башлаган чорда ук ул матбугат, әдәбият һ.б. темаларга багышланган мәкаләләре белән «Өлфәт», «Бәянелхак» газеталарында күренә башлый [Биктимерия, 1906, Өлфәт...; Биктимерия, 1906, Истизах; Биктимерия, 1906, Мөхтәрәм...]. Шундый язмаларның берсендә Галимәтелбәнат ханым газета мөхәррireннән мөселманнар өчен сурәткә төшү һәм сурәтләрне өйдә тотуның дөрес булу-булмавын тәфсилле итеп аңлатып бирүен үтенеп яза. Бу мәкаләне язуга Дума депутатларының, «мәшһүр риваятьләрдә» бу хакта тыелуга карамастан, сурәтләре газетада басылып чыгуын күрү этәргеч бирә [Биктимерия, 1906, Истифсар]. Шул ук мәсьәлә авторның икенче бер язмасында да күтәрелә. «Бәянелхак» газетасында басылып чыккан мәкаләсендә ул шул ук басманың 20 нче санында дөнья күргән, сурәткә төшүнең дөрес булмавын хәдисләргә таянып раслаган язмага нисбәтән, «памятник кылдырмак һәм сурәткә «фотограф» алдырмак һәм өйдә тотмакның мотлакан дөрес булмавын» яза, мөхәррирнең бу хакта тагын да тәфсиллерәк итеп аңлатып язуын үтенә [Биктимерия, 1906, Мөхтәрәм...]. Гомумән алганда, Г. Биктимерия бу мәсьәләгә тискәре караган дип уйларга җирлек бар. Заманының шактый танылган шәхесләреннән берсе булып җитешкән чорда да ул сурәткә төшү һәм аны матбугат чараларына урнаштыруга каршы булган. Бу фикерне раслау өчен, Ф. Әмирханның Г. Биктимерия вафатыннан соң «Тәрбиятел-әтфаль» журналында чыккан язмасында аның «Петербургта Черная речка дачасында үзенә белдертмичә, кача алган рәсемен» урнаштыруы турындагы сүзләрен китерергә мөмкин [Әмирхан, 1907, б. 65].

Г. Биктимериянең мәгърифәтчелек эшчәнлегендәге тагын бер мөһим юнәлеш – ул да булса язучылык эше. Тик шуны искәртеп китү мөһим: ул – әдәби әсәрләр, шигырьләр язучы әдибә булу өстенә, педагогика, тәрбия, хокук темаларына багышланган фәнни-популяр китаплар авторы да. Мәгърифәтче ханым бу эшне мөгаллимәлек эшчәнлеге белән бер үк вакытта алып бара: 1892 – 1903 елларда Галимәтелбәнат ханымның тәрбия һәм мәгърифәтчелек темасына караган «Тәргыйбел-бәнат фи тәгълимел әдәбият» («Хатын-кызларны әдәбият өйрәнүгә кызыксындыру»), «Хөснел-васыять» («Күркәм васыять»), «Мәгашәрәт адәбе» («Аралашу кагыйдәләре») исемле китаплары басылып чыга [Гайнетдинов, 1985, б. 408]. «Әхлаке җәлалия» («Бөеклек әхлагы») һәм «Ләвамигыль-ширакъ» («Укучыларны хурлаучылар») дигән исем астында әзерләнгән китаплары, кызганыч, дөньяга чыгарга өлгерми кала, күзләре һәм куллары авыртуга дучар булган мөгаллимә-галимә [Әмирхан, 1907, б. 65] 30 яшендә үк вафат була. Бу турыдагы хәбәрне «Тәрбиятел-әтфаль» журналы хәбәр итә [Тәрбиятел-әтфаль, 1907, б. 17]. Шул ук журналның 4 нче санында Фатих Әмирханның Галимәтелбәнат Биктимериянең вафаты мөнәсәбәте белән язган «Галимәтелбәнат (Тәрҗемәи әхвале мөшаһир)» дигән мәкаләсе басылып чыга [Әмирхан, 1907, б. 65].

Галимәтелбәнат Биктимериянең китаплары кыз балаларны укыту һәм тәрбияләү, аларның гаиләдәге вазифаларын аңлату, хокукларын

яклау, җәмгыятьтә тоткан урыннарын билгеләү, бөтен бер гаиләнең бәхетле яки бәхетсез булуының төп сәбәпчеләре булган ханымнарга – аналарга һәм ир хатыннарына юл күрсәтү һ.б. мәсьәләләргә багышланган. Аның фикеренчә, хатын-кызны укыту һәм аңа дөрес тәрбия бирүнең максаты аның үзен белемле һәм мәгърифәтле итү генә түгел, ә тәрбияле ана һәм хатын ярдәмендә гаиләнең, балаларның, һәм, гомумән, җәмгыятьнең, милләтнең алгарышына ирешү, чөнки хатын-кыз – ул төп тәрбияче, гаиләнең бәхетле, рухи яктан сәламәт булуы аның акыллы эш итүенә бәйле [Татар..., 2021, б. 12].

1897 елда дөнья күргән «Мәгашәрәт адәбе» китабына язган сүз башында Г. Биктимерия үз алдына куйган максатын түбәндәгечә билгели: «Фикерем исә җенестәшемез улган хатыннар таифәсе арасында гыйлем вә мәгърифәт таратмак вә анларны мәгълүмат сахибләре (ияләре) итмәктер. Чөнки хатыннар дөньяда улган инсаннарның ярымнарыдыр. Гаиләнең бәхет вә сәгадәтләре хатыннарның гакыллы вә гыйлемле булуларына багланмыштыр. Хатыннар тәрбияле балалар җитештерәләр. Аларның тәрбияләре сәбәбендә дөньяга олуг затлар булыныр. Әгәр дә бер хатын укыр исә, үзенең кем идеген вә хезмәте нидән гыйбарәт идеген белер, балаларын гүзәл тәрбия кылыр, ире илә яхшы вә Аллаһы Тәгаләнең әмерләренә муафыйк тереклек итәр. Вә бу сәбәпле үзе һәм ире вә балалары бәхетле булырлар» [Биктимерия, 1898, б. 3].

Г. Биктимерия искә алынган китабында гаилә мөнәсәбәтләренең күп якларына туктала, шул ук вакытта хатыннар белән ирләр, каенана һәм киленнәр, үги аналар һәм үги балалар арасындагы кире мөнәсәбәтләрне һәм аларны бетерү юлларын күрсәтергә омтыла. Аның фикеренчә, бу каршылыкларны хәл итүнең иң беренче һәм иң дөрес юлы – хатын-кызга тиешле (ислам кыйммәтләренә нигезләнгән, милли горреф-гадәтләрне кире какмаган, шул ук вакытта заманча рухта булган) тәрбия һәм белем бирү. Гаиләдә туган аңлашылмаучылыкларны уңышлы хәл итү күп очракта хатын-кыз – акыллы, яхшы холыклы, тәрбияле әни, килен, каенана кулында булган. Аның фикеренчә, кыз балаларда күркәм холык тәрбияләү үтә мөһим, чөнки «күркәм холык – олуг фазыйләттер. Аның хакында шәригатебездә мөкатдәс әмер ушандак (шулай ук) вәгазь вә нәсыйхәтләр әйтеленер» [Биктимерия, 1898, б. 3].

Әлеге китабында Г. Биктимерия язучы һәм педагог кына түгел, ә гаилә психологы буларак та үзен күрсәтә алган. Гаилә эчендәге психологик халәт, сәламәт рух аның яшәешендә төп факторларның берсе булып тора, шуңа да аны саклап калу мөһим. Ир белән хатын үзара аңлашып, бер-берсенә юл куеп яшәгәндә генә моңа ирешергә мөмкин. Әлбәттә, биредә дә төп корал хатын-кыз кулында – аның тәрбиялелегендә, белемендә, итагатьлелегендә һ.б. «Ир илә хатын арасында улган тереклектә мәслихәт улмас исә, – дип яза әдибә, – һәр икесе өчен олуг хәсрәт вә зур мәшәкать улыр. Мәгыйшәтнең ләззәте бетәр, рәхәте китәр, тәдбирләр (алдан күрелгән эш) бозылыр –

җөмлә өй җәмәгате арасында дошманлык заһир улыр, балалар тынычсызланырлар. Моннан исә күп хәерсез эшләр мәйдан алыр» [Биктимерия, 1898, б. 3]. Автор фикеренчә, хатыннарның гаиләдә үз-үзләрен тотышлары, холыклары ирләренең холыклары формалашуга да тәэсир итә: «тәҗрибәләргә күрә, хатыннарның гүзәл холыклы булмаклары сәбәбеннән, ирләре дә гүзәл холыклы булыр. Әгәр дә хатыннар явыз холыклы булырлар исә, ирләренең холыклары һәм бозылыр» [Биктимерия, 1898, б. 3]. Моның өчен ир хатыныннан психолог булу таләп итеlә: ул иренең «табигатен вә холкын белмәк вә моның өчен күп мәртәбәләр сынамак тиештер. Соңрак шуңа муафыйк эш кылмак лаземдер». Әлбәттә, ул һәрвакыт ханымнар ягында, һәм алардан ирләренә кол булуны таләп итми, тик акыл белән, уйлап эш итәргә чакыра. Шул чакта алар «шәригатебез итагатьле хатыннарга «изге хатыннар» исемен биреп, гамәлләре бәрабәренә һәм күп саваплар вәгъдә итмештер» [Биктимерия, 1898, б. 3–4]. Һәм, әлбәттә инде, чын мәгърифәтчеләрчә нәтиҗә ясый: «Инде безнең халкыбыз, дигәнебезчә хатыннары изге булуларын теләсәләр, хатыннар турында бәхетле булырга рәгъбәт кылсалар (теләсәләр), кыз балаларыбызны яхшы мөгаллимәләрдән укытырга вә ислам тәрбиясе илә тәрбия итәргә иҗтиһад кылсыннар! «Ислам тәрбиясен күргән кызлар – ирләренә гакыллы киңәшчеләр, балаларына яхшы үстерүче аналар булачаклары кеби, ирләренең тәүфыйкларына сәбәпчеләр, малларына каравылчы, ирләреннән артык йорт җыярга тырышучы бәндәләр булырлар» [Биктимерия, 1898, б. 8].

Инде күренгәнчә, гаиләдәге сәламәт рухны булдыруда, гаилә башлыгы белән җылы мөнәсәбәтләрне саклауда төп рольне хатын-кыз уйный. Гаиләдә тәрбияләнгән балаларның тәрбиясе, яхшы холкы, гүзәл табигате, белеме һәм тәрбиясе, һәм, димәк, нинди кеше булып җитешәчәге өчен дә, иң беренче чиратта, ата-ана, аеруча әни кеше җаваплы. Чөнки «тәрбия илә бер баланы алтын итмәк тә мөмкин, балчык ясамак та мөмкиндер» [Биктимерия, 1898, б. 17].

Г. Биктимериянең әлеге китабын үз заманы өчен хатын-кызлар өчен язылган иң мәшһүр китапларының берсе дияргә мөмкиндер. Аңа зур бәя биреп, Р. Фәхреддин: «Язучы Галимә ханым, бер өй әһеленә аналык хезмәте итдеке кеби, никадәр кыз балаларга мөгаллимәлек һәм итмәктәдер. Фикеренең бәлә нд (югары) идекене белмәк өчен, рисаләсенең башында улган бер-ике сүзне укымак җитсә кирәк. Вакыйган (чынлыкта) бер-ике сүзләрдер: ләкин миллион сүзләрдән хәерле сүзләрдер. Фикерне эшләтмәк яки гыйльме илә гамәл итмәк нияте илә ханым әфәнде ошбу рисаләсен дә һәм язмыштыр... Гүзәл хезмәттер. Тәбрик итәмез!» – дип яза [Биктимерия, 1898, б. 21].

1899 елда басылып чыккан «Хөснел васыять» дип исемләнгән икенче китабында Г. Биктимерия инсан өчен үтә әһәмиятле булган тагын бер мәсьәләгә туктала. Бу – васыять һәм аның төрләре, аны калдыручы һәм васыять атап язылган кешеләр, үтәү шартлары. Васыять калдыруның ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын ассызыклап, ул:

«Бер кемсә васыять кылып вафат булса, гөнаһлары кичелер, изге вә шәһит булып, раст юл үзерендә вафат булыр», – дип яза [Биктимерия, 1899, б. 3]. Авторны аеруча борчыган нәрсә – ул васыятьтә өлеше булган хатын-кызларның хакы. Татар тормышында мирас бүлешкәндә хатын-кызларны читтә калдыру күренеше дә сирәк булмаган. Бу аларның хокукларын бозуга китергән, мондый хәл шәригать кануннары буенча да хупланмаган. Ислам тәгълиматы белән бик яхшы таныш булган Г. Биктимерия бу мәсьәләдә дә дини кыйммәтләргә таянуның әһәмиятен ассызыклый: «Хатын-кызларны мирастан мәхрүм кылмак – Рәсүлуллаһтан мөкаддәм (элек) җаһилият (наданлык) халкының гореф вә гадәтләреннәндер. Җаһилият халкы үзләренең ким гакыллары берлә ирләрен хатын вә кызлар вә сабыйлардан артык дип уйлап, мирасның барчасын ирләргә генә тәкъсим кылып (бүлеп), бичара хатын-кыз, сабыйлары мирастан мәхрүм калалар иде» [Биктимерия, 1899, б. 8]. Мөселманнар, автор фикеренчә, һичшиксез, бу хаталардан азат булырга тиешләр. Әлеге китап шул максатны истә тотып язылган.

Галимәтелбәнат Биктимерованың вафатыннан соң татар вакытлы матбугатында аңа багышланган язмалар дөнья күрә. «Тәрбиятел әтфаль» журналында, «Өлфәт» газетасында педагогның вафаты турындагы хәбәрләр, тормышы һәм эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр басыла [Идарәи.., 1906; Тәрбиятел-әтфаль, 1907, б. 17]. «Өлфәт» газетасы, аның татар хатын-кызлары тормышында тоткан роленә зур бәя биреп, «Галимәтелбәнат ханым гомумән ватанымыз өчен Җәнабе Хак тарафыннан күндерелмеш бер әнгам (зат) улдыгыннан, башка ханым әфәнделәр өчен хосусан бер рәһбәр (юл күрсәтүче) иде ки, милләтемезнең киләчәк сәгадәт зие (иясе) вә рухы булган галимә вә тәрбияле аналарга наил булачагы кеби дәһа бөек-бөек мөхәррирләр вә ханымнар өчен дәһа котлы рәһбәрләр җитешәчәге күз уңында күренмәктә иде. [...] Галимәтелбәнат ханым кеби рәһбәрләр җитештермәк милләтнең бурычы вә вазифаи мөкаддисәседер», – дип язып чыга [Галим нисван вә..., 1906]. Язучы һәм «Тәрбиятел-әтфаль» журналының җаваплы сәркатибе Ф. Әмирхан да Г. Биктимериянең әдәби иҗат эшчәнлегенә зур бәя бирә: «Әгәр хатын-кызларымыз арасында бу ханым кеби мөхәррирләре вә хакларын химая итүчеләр (яклаучылар) булса иде, бәлки алар да үз хакларын белерләр вә ирләрнең аларга булган илтифатызлыкларын бетерергә мәҗбүр итәрләр иде». Язучы педагог ханымның кешелеклелек сыйфатларына тукталып, гаять күркәм холыклы, һәркемгә яхшы мөгамәләле, шәфкатьле иде», – дип яза [Әмирхан, 1907, б. 65].

Шулай итеп, Галимәтелбәнат Биктимерия – XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар иҗтимагый һәм педагогик фикер үсешендә шактый тирән эз калдырган затларыбызның берсе дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Ул татар җәмгыятендә хатын-кызның роле турында фикерләре белән матбугатта чыгыш ясаган ханымнарыбызның тәүгеләре арасында иде, гаиләнең бәхете генә түгел, милләтнең киләчәге дә

тәрбияле, белемле хатын-кыз кулында икәнлеген гавамга аңлаткан мәшһүр мәгърифәтчеләребезнең берсе булып милләт тарихына кереп калды.

**Әдәбият**

*Әмирхан Ф.* (журналда авторның исеме күрсәтелмәгән). Галимәтелбәнат (Тәрҗемәи әхвале мөшаһир) // Тәрбиятел-этфаль. 1907. № 4. Б. 65.

*Биктимерия Г.* Мәгашәрәт адәбе. СПб.: «И. Бораганский вә компаниясе» матбагасы, 1898. 23 б.

*Биктимерия Г.* Хөснел васыять. СПб.: «И. Бораганский вә компаниясе» матбагасы, 1899. 20 б.

*Биктимерия Г. (Галимәтелбәнат әл-Биктимерия әл-Җаубашия).* Өлфәт кирәк // Өлфәт. 1906. 5 гыйнвар.

*Биктимерия Г.* Истизах // Өлфәт. 1906. 2 февраль.

*Биктимерия Г.* Истифсар // Өлфәт. 1906. 4 май.

*Биктимерия Г.* [Мөхтәрәм мөхәррир әфәнде!] // Бәянелхак. 1906. 27 июнь.

*Биктимирова Т.Ә.* Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында. Казан: Печатный Двор, 2002. 140 б.

*Гайнуллин М.* Өмет йолдызлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 278 б.

*Гайнетдинов М.* Поэзия // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. Б. 377–416.

Галим нисван вә Галимәтелбәнат ханым // Өлфәт. 1906. 11 декабрь.

*Идарәи «Өлфәт».* Әхбар // Өлфәт. 1906. 6 декабрь.

*Мәхмүтова А.Х.* Вакыт инде: без дә торыйк... (Җәдитчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 366 б.

Татар тәрбиясе: Г. Биктимерия һәм Ф. Сөләймания хезмәтләрендә гаилә тәрбиясе мәсьәләләре / төз.-авт. Мортазина Л.Р., Зиннәтуллина А.Ә. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2021. 380 б.

Тәрбиятел-этфаль. 1907. № 1. Б. 17.

*Фәхреддин Р.* Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. 304 б.

*Фәхреддин Р.* Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. 648 б.

*Фәхреддин Р.* Мәшһүр хатыннар. Оренбург: Тип. М.-Ф.Г. Каримова, 1904. 448 б.

***Мортазина Ләлә Рәис кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*Милли мәгариф тарихы һәм теориясе бүлеге*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 82.091(01)

***Ф.Ш. Хуҗин***

# БОРЫНГЫ БАБАЛАРЫБЫЗ НИНДИ ТЕЛДӘ СӨЙЛӘШКӘН?

## Профессор Марсель Бакировның «Тайны происхождения наших предков (историко-лингвистическое исследование)» дигән китабын укып чыккач туган фикерләр

В статье дана оценка, с точки зрения ученого-историка, новой монографии известного татарского филолога, профессора М.Х. Бакирова «Тайны происхождения наших предков (историко-лингвистическое исследование)» (Казань: Татар. кн. изд-во, 2022. 391 с.), посвященной выявлению этнических корней тюркского языка и их носителей, в первую очередь, далеких предков татар и чувашей. В первой части книги основное внимание уделено проблемам формирования языка булгарского этнического массива (булгар, хазар, сувар, барсил и др.); показана роль Древнего Кавказа и Среднеазиатского Турана в качестве связующих звеньев с первоначальной родиной тюрков – Передней Азией. Во второй части представлен лексико-семантический (отчасти этимологический) словарь, основу которого составляет нововыявленный материал самого автора, подтверждающий переднеазиатское происхождение тюркского этноязыкового мира. Автор рецензии высоко оценивает открытия профессора М.Х. Бакирова и надеется, что основанная на новых надежных фактах концепция ученого поможет решать некоторые остро дискуссионные проблемы формирования этнических основ современных тюркских народов.

**Ключевые слова:** этногенез, прототюрки, волжско-булгарский язык, лексико-семантический словарь, Ближний Восток, Передняя Азия, Среднеазиатский Туран.

The article evaluates, from the point of view of a historian, a new monograph by the famous Tatar philologist, Professor M.H. Bakirov «Secrets of the origin of our ancestors (historical and linguistic research)» (Kazan: Tatar Publishing House, 2022.391 p.), dedicated to identifying the ethnic roots of the Turkic language and their speakers first of all, the distant ancestors of the Tatars and Chuvash. In the first part of the book, the main attention is paid to the problems of the formation of the language of the Bulgar ethnic array (Bulgar, Khazar, Suvar, Barsil, etc.); the role of the Ancient Caucasus and the Central Asian Turan as connecting links with the original homeland of the Turks – Near Asia is shown. The second part presents a lexico-semantic (partly etymological) dictionary, the basis of which is the newly revealed material of the author himself, confirming the Near-Asian origin of the Turkic ethno-linguistic world. The author of the review highly appreciates the discoveries of Professor M.H. Bakirov and hopes that the scientist's concept based on new reliable facts will help to solve some of the hotly debated problems of the formation of the ethnic foundations of modern Turkic peoples.

**Keywords:** linguistics, ethnogenesis, proto-turks, Volga-Bulgar language, lexico-semantic dictionary, Near East, Central Asian Turan.

Геродот (б.э.к. V гасыр) грек тарихының, Фабий Пиктор (б.э.к. III гасыр) Рим тарихының атасы санала. Россия тарихы фәненең чишмә башы елъязмачы Несторга (XII гасыр), Болгар тарихыныкы Йакуб ибн Ногманга (XI–XII гасырлар) барып тоташа. Бу тарихчыларның барысын да бернәрсә берләштерә – аларның һәрберсе үз тарихларын «безнең борынгы бабаларыбыз кемнәр?» дигән сорауга җавап эзләүдән башлап җибәрәләр. Шуны да ассызыклап әйтергә кирәктер: әле тарих фәне һәм профессиональ тарихчылар килеп чыкканчы һәр ыруг-кабиләнең, һәр халыкның үзләренең борынгы бабалары турында белгәннәре безнең көннәргә кадәр килеп җиткән легенда-риваятьләрдә, дастаннарда, халык иҗатының башка жанрларында чагылыш тапкан. Әмма халык хәтере барлык очракта да объектив чынбарлыкка туры килеп бетми. Бүгенге фәндә «этногенез» (халыкларның килеп чыгышы) төшенчәсе белән атап йөртелә торган бик катлаулы һәм дәвамлы процесс халык иҗаты әсәрләрендә, бигрәк тә генеологик легендаларда бик җиңел аңлатыла: «без – бүреләр (торналар, еланнар, аккошлар...) токымы», «бабаларыбыз – Нугай нәселеннән», «без – болгарлар» һ.б. Шәҗәрәләрдә исә генеологик җеп кайвакыт Адәм белән Хәувага кадәр сузыла. Әмма шундый самими-наив карашлар да күп очракта гыйльми тикшеренүләргә дөрес юнәлеш бирә алалар.

Россия халыкларның этногенезы белән бәйле проблемалар тарих фәнендә XVIII гасырдан башлап өйрәнелә башлады – хөкүмәт әһелләренә, чиновникларга чикләре меңләгән чакрымнарга сузылган империя халыклары белән «дөрес» идарә итү өчен аларның тарихы, яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, телләре турында да бераз мәгълүмат кирәк иде. Теге яки бу халыкның килеп чыгышы турында беренчел чыганаклар шул чорда тупланды. Бу чыганаклар башлыча тарих, тел һәм этнография материалларыннан гыйбарәт иде. Соңрак, XIX гасырның икенче яртысыннан башлап, бу эшкә археологлар да җәлеп ителде. Әмма һәркем үз юнәлеше буенча эшләде, тупланган материалларны анализлап, чагыштырып карап, аңлашып, бердәм фикергә килү булмады.

Хәл узган гасыр урталарында гына үзгәрә башлады, галимнәр төрле характердагы чыганакларны комплекслы рәвештә өйрәнү кирәклеген күтәреп чыктылар. Халыкларның килеп чыгышы мәсьәләләренә багышланган фәнни конференцияләргә тарихчылардан, этнографлардан, телчеләрдән һәм археологлардан башка антропологларны, фольклорчыларны, соңгы елларда хәтта табигать фәннәре, гамәли сәнгать һәм этномузыка белгечләрен дә чакыра башладылар. Һәр белгеч үз концепциясен алга сөрде, фикерләр туры килмәгән очракта көч аның сәбәпләрен эзләүгә, яңа материаллар туплауга юнәлдерелде. Төрле фән белгечләре үз юнәлешләре буенча актив эшләде, тикшеренүләрнең яңа ысулларын тәкъдим итте.

Этногенез проблемаларын өйрәнгәндә галимнәр лингвистика – тел чыганакларыннан элегрәк тә актив рәвештә файдаланып килде. Бу

аңлашыла да, чөнки халыкның күпгасырлык тарихы телдә (лексикада гына түгел, фонетика һәм морфологиядә дә) чагылыш тапмый калмаган. Узган гасырның икенче яртысында бу өлкәдә тикшеренүләр тагын да ныграк җанланып китте. Мисал өчен күренекле галимнәребез М.З. Зәкиев [Закиев, 2008], Д.Г. Тумашева [Тумашева, 1977], Л.Т. Мәхмүтова [Махмутова, 1982; 1985], Д.Б. Рамазанова [Рамазанова, 1996], Х.Р. Курбатов [Kurbatov, 1994], Р.Г. Әхмәтҗанов [Ахметьянов, 1981; 1988], Ф.С. Хәкимҗанов [Хакимзянов, 1987] һ.б. телчеләрнең билгеле хезмәтләрен искә төшереп үтәргә була. Чуваш галимнәре исә, Н.И. Ашмариннан башлап Н.И. Егоровка кадәр, этногенетик тикшеренүләрдә тел чыганакларын беренче планга куеп киләләр [Ашмарин, 1902; Егоров В., 1953; Федотов, 1986; 1990, с. 32–59; Егоров Н., 2017]. Хронологик яктан караганда, татар телчеләре башлыча болгар чоры белән чикләнделәр. Бары тик М.З. Зәкиев кенә тагын да борынгырак чорларга үтеп керә алды һәм төрки телләр тарихын, кайбер чит ил һәм Россия галимнәренең тикшеренүләренә таянып, хәзерге Ирак җирлегендә б.э.к. III меңьеллыкта яшәгән шумер-аккадлардан башлап өйрәнү кирәклегенә басым ясады.

2019 елда Татарстан китап нәшриятында әдәбият һәм тел белгече, фольклорчы Марсель Бакировның «Прототюрки: изначальная прародина, ранние племена и язык, история и этнокультура» (Казань, 2019. 463 с.) дигән фундаменталь хезмәте дөнья күргән иде. Биредә ул үзен, күп көч куеп үзе туплаган лексик-семантик һәм өлешчә этимологик чагыштырма сүзлек материалларына таянып, иң борынгы төркләр һәм аларның телләре, фәндә ныклап урнашкан концепция авторлары карашынча, Алтайда түгел, бәлки Якын Көнчыгышта, ягъни Азия кыйтгасының көньяк-көнбатыш өлешендә формалаша башлаган дигән теория тарафдары буларак танытты. Галимнең раславынча, безнең борынгы бабаларыбыз саналган һуннар иң элгәреге төркләр түгел, алар Якын һәм Алгы Көнчыгыштан Туран җирләренә күчеп утырган борынгы төркләр (бабалары сак, массагетлар) составыннан аерылып чыкканнар һәм Үзәк Азиядә, ягъни хәзерге Монголия, Байкал аръягы җирләрендә өлешчә монгол телле кабиләләр белән кушылганнар. Бу фикерне М.Х. Бакиров ышандырырлык итеп, абруйлы белгечләр фикеренә таянып, тел, археология һәм антропология өлкәсенә караган яңа фәнни фактлар белән исбатлады. Һәм, басым ясап әйтергә кирәк, әлеге хезмәтендә тюрколог галимебез төркләрнең этногенез һәм борынгы этник тарихы ике зур этаптан торганлыгын ышандырырлык итеп раслады, шул исәптән Якын һәм Алгы Көнчыгышта узган башлангыч этабында төрк баба теленең һәм иң элгәреге төркләрнең нинди үле яки борынгы этник төркемнәр катнашлыгында яралганлыгын ачыклауга үзеннән зур өлеш кертте [Дәүләтшин, 2019, б. 166–174; Азертюрк, 2021, с. 282–285].

Узган ел Татарстан китап нәшриятында профессор Марсель Бакировның борынгы бабаларыбызның килеп чыгышына багышланган тагын бер саллы китабы басылып чыкты: «Тайны происхождения

наших предков. Историко-лингвистическое исследование» (Казань, 2022. 391 с.). Аның бу китабын мин, Идел болгарлары археологиясе белән шөгыльләнүче галим буларак, бигрәк тә кызыксынып укып чыктым, чөнки автор биредә күбрәк болгар, хәзәр, барсил, савир/сувар телләре турында сүз алып бара, бик тә бәхәсле «болгар-чуваш теле», чувашларда болгар мирасы мәсьәләләренә дә киң туктала. Автор күтәргән проблемалар, ул проблемаларны чишүгә юнәлдерелгән яңа фактлар, шул фактларны анализлау нәтиҗәсендә туган гөман-фаразлар, моңарчы аз билгеле булган чыганаклар белән расланган төпле фикерләр телче һәм тарихчы галимнәрнең генә түгел, милли тарихыбызга битараф булмаган киң катлау укучыларыбызның да игътибарын җәлеп итәр дип уйлыйм.

Китапның беренче өлешендә гомумболгар этник берләшмәсен тәшкил иткән аерым компонентларның (болгар, сувар, барсил һ.б.) телләре тикшерелә. Билгеле булганча, лингвистикада төрки телләрне ике төп төркемгә бүлеп өйрәнү кабул ителгән: 1) *р*-телле угор-болгар төркеме (боларга борынгы болгар, сувар, хәзәр, бәҗәнәк һәм хәзерге чуваш телләре керә); 2) *з*-телле угыз, икенче төрлерәк әйтсәк, гомумтөрки төркеме (кыпчаклар, төрек, азәрбайҗан, төрекмән, татар, башкорт, уйгур, казакъ, кыргыз һ.б. телләр). Россия һәм чит ил тюркологиясендә чувашлар – болгар төркеменең бүгенгә кадәр сакланып калган бердәнбер халкы, дигән фикер өстенлек итә, ә бу исә аларга, ягъни безнең чуваш күршеләребезгә, Идел болгарлары мирасын тулысынча үзләренеке итеп күрсәтергә җирлек бирә. Татарларның болгар мирасына катнашы юк, имеш, алар – килмешәк монгол-татарлар токымыннан. Чуваш тарихчылары – бүген дә шул «теория» тарафдарлары (кара: Болгары и чуваши, 1984; Димитриев, 2004).

Билгеле булганча, чувашларда һәм, XIV гасыр кабер ташларындагы язмаларга караганда, болгарларда да башка төрки халыклар телендә кулланыла торган [з] авазы урынына [р] авазы (ротацизм күренеше), [ш] авазы урынына [л] авазы (ламдаизм), [к] авазы урынына [х] авазы кулланыла. Мәсәлән, татар телендәге *кыз* сүзен чувашлар *хӗр* диләр (болгар ташларында – *хир*); *ишек* (тат.) – *элик* (болг.) – *алӑк* (чув.) – *эшик* (гомумтөрк.). Әмма шул ук эпитафия язмаларында гомумтөрки телгә хас з-авазлы сүзләр дә урын алган. Кабер ташларында кулланылган, моңарчы ике төрле эпитафик стиль итеп саналган бу тел аерымлыкларын М. Бакиров функциональ яктан киңәйтеп һәм җирле сөйләм белән бәйләп, болгар теленә хас булган ике төрле сөйләш (наречие) чагылышы итеп карый. Әлеге кабер ташларын, бәхәссез, мөселман динендәге болгарлар куйган, димәк, ике сөйләш төркемендәге кешеләр, ягъни мөселманнар, бер-берсен яхшы аңлаганнар, чөнки *р*-телле болгарлар да, *з*-телләре дә бер үк дәүләттә яшәгәннәр (сөйләшләрнең бер-берсенә тәэсире: тат. *кыз-кы**р**кын, яткы**р**у-яткы**з**у, җитке**р**-җиткез**, *күз-кү**р*** һ.б.).

Моңарчы игътибар үзәгеннән төшеп калган аерым фәнни хезмәтләргә һәм яңа дәлилләргә таянып, М.Х. Бакиров раславынча, бүген

чувашлар сөйләшә торган *р*-тел элгәреге төрки телләр арасында иң борынгысы түгел, ул җирле фин-угор телләре катнашында соңрак формалашкан дип әйтә алабыз. Ә менә төрки дөньяда элек тә, хәзер дә күпчелекне тәшкил итүче угыз-кыпчак тибындагы *з*-телләрнең барлыкка килүе исә, чыннан да, борынгырак чорларга карый. Соңгы елларда аларның беренчел ватанын кыю һәм яңача фикерләүче галимнәр Якын Көнчыгышта, хәзерге Ирак-Иран җирләрендә дип күрсәтә [Закиев, 2003; Азертюрк, 2018].

*Р*-телле угыр-болгар катламы кайда формалашкан соң, *з*-телле гомумтөрки катламыннан аерыла торган тел тармагы буларак кайчан һәм ничек барлыкка килгән? Бу сорауларга М. Бакиров, тарихи һәм лингвистик чыганакларга нигезләнеп, төпле җавап бирә: *р*-телдә сөйләшә торган халыкның анаватаны – Туран, ягъни Амудәрья һәм Сырдәрья елгаларының Арал диңгезенә коя торган түбән агымнары тирәсендәге җирләр, хәзерге Казакъстанның көньяк-көнбатыш өлкәләре. Б.э.к. IV–III меңъеллыкларда әлеге туран җирендә Якын Көнчыгыштан, төгәлрәге, хәзерге Иран-Ирак территориясеннән күчеп килгән һәм үзләреннән соң кельтеминар археологик культурасын калдырган халыклар – борынгы дравидлар яшәгән. Алар биредә Көньяк Себер якларыннан килеп чыккан угорлар белән кушылганнар. Дравид кабиләләренең төрки халыкларга хас агглютинатив диалектларда сөйләшкәнлегенә һәм дә телләрендә архаик төрки сүзләрнең шактый күп сакланып калуына нигезләнеп, галим үзенең элегрәк чыккан китабында алар (борынгы дравидлар) көнбатышта формалашкан иң элгәреге төрки дөньяның бер катламы – этник компоненты булган дигән нәтиҗәгә килгән иде. Фонетик күренеш буларак ротацизм һәм ламдаизмның иң борынгы үрнәкләрен М. Бакиров нәкъ менә шул дравидлар телендә таба. Аның фикеренчә, ротацизм күренеше беренче башлап угорларның – хәзерге ханты, манси, венгр халыкларының элгәреләре белән борынгы төркләр үзара аралашкан катнаш нигездә барлыкка килгән. Туран җирлегендә дравидларның һәм Якын Көнчыгыштан күчеп килгән башка элгәреге төркләрнең борынгы угорлар беләр очрашуы-керешүе, шул очрашулар җирлегендә туган катнаш тел кулай җирлек булган. Археология материаллары күрсәтүенчә, соңыннан алар акрынлап Үзәк Азия, Көньяк Себер далаларына күчеп китәләр. Бу якларда элек-электән яшәгән төрки һәм монгол телләрендә дравидлар белән уртак ротацизм үрнәкләре очравын, кайберләренең хәтта болгар теленә үтеп керүен галим шул күчену-аралашуларга бәйләп карый.

Алай гына да түгел, М. Бакиров яклаган гомуми караш буенча, Төньяк Кавказда, ә аннары Дунай һәм Урта Идел буенда үз дәүләтләрен корып яшәгән болгарларда *р*-телле сөйләшнең булуы да – угор телләре йогынты ясау нәтиҗәсе. Ачыклап әйткәндә, бу йогынты Кавказга Тураннан һәм Себердән угор һәм төрки телләр катнашлыгыннан торган оногур/унугыр һәм сабир/сувар кабиләләренең күчеп килүе белән бәйләнгән. Болгар телендә ике арадагы бәйләнеш, ягъни угор тәэсире, нигездә, фонетика өлкәсендә – аерым сүзләрнең

әйтелешендә, авазлар чиратлашуында чагылыш табу белән чикләнгән һәм шуңа күрә болгар халкының *з*-телдә сөйләшкән катламына да аңлаешлы булган. Ә менә автохтон яки җирле фин-угорлар (башлыча марилар) белән кушылып формалашкан чувашларда исә үзара йогынты бик көчле булган һәм чувашларның болгарлардан аерымланып яшәвенә, телләренең башка төрки халыкларга аңлашылмавына китергән. М. Бакиров үзенең тикшеренүләрендә болгар теленең үзенчәлекләре һәм варислары, ни өчен *з*-телле угыз-кыпчак катламының җиңеп чыгуы турында сөйләгәндә менә шуларга басым ясый.

Югарыда әйтелгән фикерләрнең һәм нәтиҗәләрнең археология, антропология һәм генетика материаллары белән дә ярашуын ассызыклап үтү мөһим. Көньяк Себер һәм Казакъстан далаларында бронза чорына караган карасук, андрон археологик культураларын калдырган кабиләләрнең, исемнәре тарихи язмаларда теркәлеп калган саклар, массагетлар, скифлар һәм сарматларның күпчелек өлеше чыгышлары ягыннан Якын Көнчыгышта һәм Алгы Азиядә формалашкан борынгы төрки дөнья белән бәйләнгән. Бу үзенчәлекле карашны куәтләү-исбатлауга да Марсель ага үзеннән шактый зур өлеш керткән. Моның өчен аның төрки дөньяга хас булган этник тотрыклы милли үзенчәлекләрне аерып чыгаруы, аларны тел фактларына өстәп, этносны билгеләүче асыл сыйфат яки күрсәткеч буларак файдалануы (Көнчыгышны изгеләштерү, бүрене һәм бер башлы канатлы мифик елан-сазаганны олылау яки тотемлаштыру, кавемгә нигез салган тотем затның яки бабаның тау куышында яралуы, өс киеменең изүен сул якка эләктерү һ.б) аерым хуплауга лаек. Монографиядә ышандырырлык дәлилләргә нигезләнеп, түбәндәгеләр бик дөрес күрсәтелгән: шул Туран халыклары арасыннан бит инде һуннар, Ашина төркләре, соңрак болгар, хәзәр, бәҗәнәк берләшмәләренә кергән кабиләләр, хәтта уйгурлар һәм башка төркиләр (угызлар) аерылып чыккан.

Марсель Бакиров туплаган чыганаклар күрсәткәнчә, «чиста төркләр» телендә, ягъни угызлар, кыпчаклар, усуннар һәм борынгы кыргызларда, шулай ук VI–VIII гасырларга караган Орхон-Енисей язмаларында *р*-телгә хас элементлар табылмаган, чөнки алар фин-угорлар белән тыгыз бәйләнештә тормаганнар һәм үзара кушылмаганнар. Димәк, төркиләрнең аерым этник төркемнәрендә *р*-телнең формалашуы, чыннан да, аларның күршеләре булган фин-угорларга (башлыча соңгыларына) нисбәтле булып чыга. Яңа тикшеренүләр төрки этногенезын Алтай-Саян төбәгенә бәйләп карый торган традицион теориягә каршы килә, алтай төркеменә кертеп йөртелә торган телләрнең, атап әйткәндә, төрки, монгол, манчьжур тел группаларының, үзара кардәш итеп каралуын да расламый. Чөнки алтай телләрен үзара якынайта торган тел һәм мәдәният өлкәсендәге уртаклыклар яки охшашлыклар этник кардәшлек аркасында түгел, бәлки үзара элемтәләр, аралашулар нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр.

Профессор М. Бакировның ачышлары төрки халыклар анаватанын, алда әйтелгәнчә, Алтай-Саян җирләре белән бәйләүче, шулай

ук чуваш теленә хас *р*-сөйләше, имеш, иң борынгы төрки телләрдә үк барлыкка килгән, *з*-сөйләше исә баштарак чорларда гомумән булмаган дип инанучы тюркологларның фаразга корылган карашларын нык какшата һәм кискен кире кага. Әлеге монографиядә төрки этногенезының Якын Көнчыгышка мөнәсәбәтле башлангыч чорын *з*-телле прототөркиләр белән, ә *р*-тел сөйләше барлыккка килгән урынны Каспий-Арал (Туран) төбәге белән бәйләп аңлатуны һәм дә моны үзе туплаган лексик-семантик чагыштырма сүзлек материаллары һәм тотрыклы этник мәдәният дәлилләре белән исбатлауны олуг галимебезнең иң зур ачышы-казанышы дип саныйм.

Галимнең меңгә якын иң борынгы лексик берәмлекләрне үз эченә алган чагыштырмалы сүзлеге генә түгел, ә аерым сүзләрнең, шул исәптән ономастик тәңгәллекләрнең килеп чыгышына, генетик яки элемтә-контактка нигезләнгән охшашлык-уртаклыкларга мөнәсәбәтле тикшеренүләре дә җитди игътибарга лаек. Менә көтелмәгән шундый архаик бәйләнешләрне ача торган (һәм шәхсән үзем өчен кызык тоелган) берничә лексик оя (тезмә): 1) *массагетлар* – баш (олуг, бөек) саклар: mah (шум.) – олуг / maha (драв.) – зур, бөек / mas (иран) – зур // (м ↔ б / с ↔ ш) → мас < баш (борынгы төрки. – баш, башлык + саг / сак (этнос атамасы) + -ет / -ат (күплек кушымчасы)[1]; 2) Алгы Азиядән чыккан *каспи, кассит* кабиләләре: кас – этноним + -пи, -ит – күплек кушымчалары. *Каспи, Кавказ* – топонимнар. Кавказ тавының элгәреге җирле аталышы – Кап / Каф + каз > кас (с ↔ з). *Казак / казакъ*: а) кас / каз → кез (бор. төрки) – күченеп йөрү(че) + ак / к[2] – күплек кушымчасы; ә) Ка / кап (бор. төрки) – якынлык, кардәшлек + зак > сак (субстрат этноним); 3) амазонкалар – сугышчан яки яугир хатын-кызлар: ам / ама – хатын-кыз + зон (чон, сөн, һун) – халык, кабилә мәгънәсен белдерүче сүзләр + к – күплек кушымчасы. Димәк, М. Бакиров тарафыннан тәкъдим ителгән версия буенча, *казакъ* этнонимының, шулай ук Кече Азиядә һәм Азов (Азак) диңгезе буенда яшәгән амазонкалар атамасының төрки телдә укылышы казакъларның генетик тамырларын һәм аларда сакланган амазонкалык традициясен Туран саклары белән бәйли торган карашлар файдасына хезмәт итә.

М. Бакировның турыдан-туры үзебезнең җирлеккә, болгар-чуваш-татар мөнәсәбәтләренә караган тикшеренүләрендә дә кызыклы күзәтүләр һәм ачышлар шактый. Шундыйлардан мин чуваш һәм татар телләренең ничек формалашуларын, бер-берсенә якын да килмәгән үзенчәлекләрен ачыклауга мөнәсәбәтле табышларын аерып күрсәтер идем. Ә инде галимнең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Урта Азиядә түгел, ә үзебезнең болгар-татар җирлегендә иҗат ителгәнлеген

[1] Күплекне белдерүче архаик -ет / -ат кушымчасының борынгы төрки телдә сакланган эзләре: ир-ат (ирләр), тюрк-ут / түрк-үт (төркләр), алпаг-ут – хәрби яраннар (алп / алпагу – батыр, каһарман).

[2] Чагыштырыгыз: турк / түрк > Тур / Түр (ыруг-кавемгә нигез салучы легендар каһарман) + к (күплек кушымчасы) – төркләр; Туран > Тур + ан (сүз ясагыч кушымча) – тураннар (төркләр) иле.

исбатлауга багышланган фәнни эзләнүләре, күзәтүләре – укучы игътибарын нык җәлеп итә торган үзе бер дөнья! Автор анда моңарчы кул тимәгән яңа материалларны кулланышка кертеп, шул исәптән «Кыйссаи Йосыф»ны әлегә кадәр аз билгеле «Ана вә угыл» дигән болгар чорына нисбәтле поэма (дастан) белән чагыштырып, болгар-татар әдәби теленең ничек формалашуын һәм аның үзенчәлекләрен ача торган ышанычлы нәтиҗәләр ясый.

Марсель ага Бакировның әлеге ачышлары, минемчә, тюркологларны нык уйланырга, элеккеге традицион концепцияләрен яңадан карап чыгарга мәҗбүр итәчәк. Фәндә Идел болгарлары телен бары тик чуваш теле белән генә тәңгәлләштерү өстенлек итә, дидек. Алайса, *р*-сөйләше, ягъни ротацизм элементлары катнашуга карамастан, нигә болгар кабер ташларының теле татарча аңлашылып тора, ә чуваш теле безгә бөтенләй аңлашылмый?! Мондый җитди аермалар асылда чувашларның элек марилар яшәгән, әмма Идел-Кама буе болгарларыннан аерымланып торган төбәктә формалашулары [Серебренников, 1956; 1957] һәм антропологик яктан аларның җирле фин-угор халкының турыдан-туры төрдәше булуы [Алексеев, 1971] М. Бакиров үзәккә алып күрсәткән фактлар җирлегендә генә аңлатыла ала.

Янә килеп, әгәр чувашлар Болгар дәүләтендә яшәгән төп халыкның дәвамчылары икән, кая киткән соң ул вакытта аларда болгарлардан калган дәүләтчелек, шәһәрләр һәм мөселман архитектурасы, язмачылыкка нигезләнгән ислам мәдәнияте? Ни өчен Кол Галидән, «Ана вә угыл» дастаны авторыннан һәм Сөләйман ибн Дауд ас-Саксини-Суваридан башланып киткән матур әдәбият юкка чыккан? Чувашлар – болгарларның исламнан баш тарткан мәҗүси өлеше, дибез икән, Болгар территориясендә шул мәҗүси чувашларның X–XV гасырларга караган берәр зиратын күрсәтегез. Юк бит алар. Авыл-шәһәр урыннары да табылмаган. Нәкъ менә болгарлардан читтә яшәгәнгә күрә дә чувашлар яши торган төбәкләрдә болгар кабер ташлары юк һәм, монография авторы искәрткәнчә, аларның кыпчаклашмыйча үз телләрен саклап калуы болгарлардан аерылып яшәве белән бәйле. «Сувар-чувашларның» X гасыр Сувары да – мөселман шәһәре, «аның үзәк мәйданында биек манаралы мәчет урнашкан», – дип язган замандашлары [Хвольсон, 1869, с. 82]. Әмирләре дә – мөселманнар, суккан дирһәмнәрендә – гарәпчә текст.

Чувашларның мәдәни мирасы, менталитеты белән кискен каршылыкка керә торган менә шундый хәлиткеч аермалар һәм дә М. Бакиров тарафыннан тәфсилләп тикшерелгән ышанычлы яңа фактлар фәндә, ниһаять, чуваш кавемен болгарларның турыдан-туры дәвамчылары итеп карый, хәтта ике арада тигезлек билгесе куя торган ясалма карашлардан баш тартуга китерер дип ышанасы килә. Иң мөһиме, аерым тюркологларның һәм чуваш галимнәренең татарларны икенче планда калдырып, болгарларның законлы һәм төп мирасчысы булуын танымауларына чик куелырга вакыт җиткәндер кебек. Соңгы елларда чуваш археологлары белән Олы Таяба шәһәрлегендә алып барыла

торган казу эшләре нәтиҗәләре дә шушы ук хәерхаһ концепциягә хезмәт итәчәге, минемчә, шиксез.

**Әдәбият**

*Азертюрк Т.* Генезис тюрка и тюркского языка (на основе клинописи). СПб.: Супер, 2018. Т. 1, 2. 1294 с.

*Азертюрк Т.* О вкладе татарского тюрколога в ориенталистику (рецензия на монографию проф. М.Х. Бакирова «Прототюрки: изначальная прародина, ранние племена и язык, история и этнокультура». Казань, 2018) // Филология и культура. Philology and culture. 2021. № 4 (66). С. 282–285.

*Алексеев В.П.* Очерк происхождения тюркских народов Восточной Европы в свете данных краниологии // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, 1971. С. 232–271.

*Ахметьянов Р.Г.* О соответствиях звуков *Р* и *Л* (*Р'* и *Л'*) в зоне татарско-чувашско-русских контактов // Источниковедение и история тюркских языков / отв. ред. Э.Р. Тенишев. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1978. С. 69–76.

*Ахметьянов Р.Г.* Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. М.: Наука, 1981. 260 с.

*Ахметьянов Р.Г.* Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья. М.: Наука, 1988. 220 с.

*Ашмарин Н.И.* Болгары и чуваши / Изв. Общ-ва археологии, истории и этнографии при Импер. Казан. ун-те. 1902. Т. XVIII, вып. 1–3. С. 1–132.

Болгары и чуваши / отв. ред. В.Д. Димитриев. Чебоксары: ЧувНИИ, 1984. 158 с.

*Дәүләтшин Г.* Прототөрки бабаларыбызга юл яручы китап // Казан утлары. 2019. № 7. Б. 166–174.

*Димитриев В.Д.* Вопросы этногенеза, этнографии и истории культуры чувашского народа. Чебоксары: Изд-во Чуваш. гос. ун-та, 2004. 392 с.

*Егоров В.Г.* К вопросу о происхождении чуваш и их языка // Уч. зап. Чув. НИИ. 1953. Вып. VII. С. 64–91.

*Егоров Н.И.* Избранные труды по этнолингвогенезу и этнической истории чувашского народа. В двух книгах. Чебоксары: Новое время, 2017. Кн. 1, 428 с.; кн. 2. 440 с.

*Закиев М.З.* Происхождение тюрков и татар. М.: Инсан, 2003. 446 с.

*Закиев М.З.* История татарского народа. (Этнические корни, формирование и развитие). М.: Инсан, 2008. 560 с.

*Махмутова Л.Т.* Татарский язык в его отношении к древнеписьменному памятнику Codex Cumanicus по данным лексики (краткий анализ и приложение) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. (Материалы и исследования. Вып. 2). Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, 1982. С. 68–153.

*Махмутова Л.Т.* О некоторых татарско-куманских параллелях (по материалам фонетики и грамматики) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. (Материалы и исследования. Вып. 3). Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, 1985. С. 117–142.

*Рамазанова Д.Б.* К истории формирования говора пермских татар. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1996. 240 с.

*Серебренников Б.А.* Проблема субстрата // Доклады и сообщения Института языкознания АН СССР. М., 1956. № 9. С. 33–57.

*Серебренников Б.А.* Происхождение чувашского народа по данным языка // О происхождении чувашского народа. Чебоксары, 1957. С. 40–45.

*Тумашева Д.Г.* Диалекты сибирских татар. Опыт сравнительного исследования. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. 294 с.

*Федотов М.Р*. Народность и язык волжских болгар // Проблемы средневековой археологии Урала и Поволжья / отв. ред. Р.Г. Кузеев. Уфа: Изд-во ИИЯЛ БФАН СССР, 1986. С. 43–48.

*Федотов М.Р.* Чувашско-марийские языковые взаимосвязи. Саранск: Изд-во Саран. филиала Саратов. гос. ун-та, 1990. 336 с.

*Хакимзянов Ф.С*. Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и и их язык. М.: Наука, 1987. 192 с.

*Хвольсон Д.А.* Известия о хозарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и руссах Абу-Али Ахмеда бен Омар Ибн-Даста. СПб., 1869. 199 с.

*Kurbatov H.* Idil-Çulman (Volga-Kama) boylarında eke geçen runik kitabeler // Türk Dünyası Arastırmaları. 1994, Şubat, N 88. S. 104–113.

***Хуҗин Фаяз Шәрип улы,***
*тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы,*
*ТР ФА А.Х. Халиков исемендәге Археология институты*
*баш гыйльми хезмәткәре*

**2023 елның 1 гыйнварында** Казандагы К. Маркс урамы, 23/6 нчы йорт фасадында дирижер Фуат Мансуровка истәлек тактасы ачылды. Әлеге чарада Татарстан Республикасы Мәдәният министры Ирада Әюпова, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм итү фондының башкарма директоры Нурия Һашимова, Казан шәһәре Мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов, Фуат Мансуровның кызы һ.б. катнашты.

Фуат Мансуров – Татарстан АССРның халык артисты (1971), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты (1994), Казакъстан ССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1958), Россия Федерациясенең халык артисты (1998), 1968 елдан – М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт Опера һәм балет театрының баш дирижеры, 1969 елдан – Зур театр дирижеры, 1989 елдан – Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестрының баш дирижеры.

**2023 елның 8 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Россия фәне көненә багышланган тантаналы утырыш узды. Утырышны Татарстан Фәннәр академиясе президенты М.Х. Саләхов Татарстанның фәнни җәмәгатьчелеген котлау һәм доклад белән ачып җибәрде. Аның чыгышы Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең эшчәнлеге, аның алдагы еллардагы төп казанышлары һәм якын арада Татарстан галимнәре алдында куелган бурычларга багышланган иде. Утырышта Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты, ул үзенең чыгышында республика халкының уникаль мәдәни мирасын саклау эшенә Татарстан Фәннәр академиясенең зур өлеш кертүен билгеләп үтте, Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премияләрен, шулай ук аерым галимнәргә һәм хезмәт коллективларына узган елда хезмәт куйган өчен башка бүләкләр тапшырды.

Тантаналы чара уңаеннан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе институтлары тарафыннан фәнни басмаларны һәм электрон проектларны үз эченә алган күргәзмә тәкъдим ителде. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе фойесында оештырылган әлеге экспозиция белән Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов һәм чараның күпсанлы кунаклары танышты.

**2023 елның 10 февралендә** Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «Виктор Фёдоров. Монументаль һәм рәсем сәнгате, графика» (Казан: Заман, 2022) дип аталган, XX гасырның икенче яртысында Татарстан рәсем сәнгатендә әйдәп баручы осталарның берсе Виктор Кронидович Фёдоровның (1940–2001) тууына 80 ел тулуга багышланган яңа альбомны тәкъдим итү чарасы узды. Альбомны төзүче-авторлар – А.И. Фёдорова, Ф.М. Миңнегулова, О.Л. Улемнова; мәкалә авторла-

ры – Д.И. Әхмәтова, Д.К. Вәлиева, Ф.М. Миңнегулова, О.Л. Улемнова. Презентациядә Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре О.Л. Улемнова, Татарстан Республикасы Рәсем сәнгате Дәүләт музее хезмәткәре Д.И. Әхмәтова һәм Д.Д. Хисамова, «Заман» нәшрияты директоры М.Ф. Гарифҗанов, рәссамның альбомны чыгаруда актив катнашкан хатыны Антонина Ивановна, Татарстан Республикасы Милли музееның төп саклаучысы Л.И. Саттарова, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, рәссам М.А. Ваһапов, Россия Федерациясенең атказанган рәссамы Г.Л. Эйдинов, РСФСРның халык артисты Р.Ш. Шәрәфиев, Татарстан Республикасының атказанган артисты Флора Вафина һәм башка мәдәният хезмәткәрләре чыгыш ясады.

**2023 елның 11 февралендә** Казанда «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме – 2022» республика бәйгесе җиңүчеләрен һәм Татарстан Республикасы Махсус дәүләт стипендиясе ияләрен бүләкләү тантанасы оештырылды. Чарада Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры Р.Н. Садыйков, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры И.Г. Һадиуллин, Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе А.Х. Гыйльметдинов, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты В.В. Хоменко катнашты.

«Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме – 2022» бәйгесе 2010 елдан башлап Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ярдәме белән Татарстан Республикасы яшь галимнәре һәм белгечләренең төбәк яшьләр иҗтимагый хәрәкәте тарафыннан Татарстан Республикасының фундаменталь һәм гамәли фән үсешенә зур өлеш керткән иң талантлы яшь галимнәрен бүләкләү максаты белән үткәрелә. Конкурста катнашу өчен югары уку йортларыннан, фәнни һәм җитештерү оешмаларыннан 150дән артык гариза кабул ителде.

**2023 елның 13 февралендә** Дастаннар елы уңаеннан Мәскәү ислам институты һәм Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан төрки мөселманнарның эпик әсәрләренә багышланган «Төрки халык дастаннары – гражданлык һәм милләтпәрвәрлек тәрбияләү чыганагы» темасына Бөтенроссия түгәрәк өстәле уздырылды. Утырышта Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Лилия Хатип кызы Мөхәммәтҗанова, төп фәнни докладчы буларак, «Татар дастаны: жанрның төп үзенчәлекләре» дигән темага онлайн форматта чыгыш ясады. Чарада, теологлар, ислам белгечләре, антропологлар, этнологлар, дини һәм иҗтимагый оешма, хакимият вәкилләре катнашты.

**2023 елның 14 февралендә** Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында Татарстан Республикасында Педагог

һәм остаз елы ачылышы тантанасы узды. Тантаналы чарага республиканың халык укытучылары, танылган педагоглар, укытучылар династиясе вәкилләре чакырылган иде. Чара кысаларында катнашучыларга Россия Федерациясе Мәгариф министры Сергей Кравцов (видеоязма) сәламләү сүзе белән мөрәҗәгать итте. Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов педагогларга күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен дәүләт бүләкләре тапшырды.

**2023 елның 16 февралендә** узган Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президиумы утырышында 2022 елда Д022.006.02 диссертация советы каршында диссертацияләрен уңышлы яклаган галимнәргә – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе фәнни хезмәткәре, «Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Гыйлемшин Флер Фоат улына, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты милли мәгариф бүлеге хезмәткәрләре Гыйниятуллина Лилия Миңнулла кызына һәм Надыршина Ләйсән Рәдиф кызына филология фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсен бирү турында дипломнар тапшырылды. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Мәкъзүм Саләхов аларга киләчәктә да яңа фәнни ачышлар һәм һөнәри казанышлар теләде.

**2023 елның 20 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында «Гомуми белем бирүнең яңартылган стандартларын гамәлгә ашыру шартларында туган тел һәм әдәбият предметларыннан яңа УМКлар» темасына милли мәгариф бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан уздырылган төбәкара түгәрәк өстәлдә Россия Федерациясе төбәкләрендә һәм Татарстанда туган телләрне һәм әдәбиятларны укыту, яңа укыту-методик комплектлары төзү мәсьәләләре турында сүз барды. Түгәрәк өстәлдә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф бүлеге җитәкчесе Энҗе Гыйззәтуллина катнашты. Чарада чыгыш ясарга теләк белдергән галимнәрне, Россия төбәкләренең Мәгариф һәм фән министрлыклары вәкилләрен, методистларны, туган тел һәм әдәбияттан УМК авторларын Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары, филология фәннәре докторы Олег Хисамов сәламләде.

Төбәкара түгәрәк өстәл эшендә видеоэлемтә аша Адыгея, Дагстан, Карачай-Черкес, Марий Эл, Мордовия, Төньяк Осетия-Алания, Удмуртия, Чечня, Саха (Якутия), Коми республикаларыннан һәм Россиянең башка төбәкләреннән вәкилләр катнашты.

**2023 елның 20 февралендә** «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә басмага әзерләнгән фәнни хезмәтләрне тәкъдим итү уңаеннан матбугат конференциясе узды. ТӘһСИнең язма мирасны туплау, өйрәнү һәм фән мәйданына кую буенча эшчәнлеге белән чарада Язма мирас үзәге мөдире, фило-

логия фәннәре кандидаты Илһам Гомәров, текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Әнисә Алиева һәм Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Ләйлә Гарипова таныштырды.

**2023 елның 20 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 2022 елны йомгаклау чаралары кысаларында Сәнгать белеме үзәге «Татарстан скульптурасының актуаль проблемалары» темасына сәнгать белеме буенча укулар оештырды.

Чарада катнашучыларны һәм ТӘһСИ хезмәткәрләрен Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы К.М. Миңнуллин сәламләде һәм сәнгать белеме буенча укуларны ачып җибәрде. Татарстанның Мәдәният министрлыгы массакүләм чаралар белән хезмәттәшлек итү бүлеге җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты А.Ш. Фәйзрахманов тарихи объектларны саклау, торгызу буенча республикада алып барыла торган эш юнәлешләре белән таныштырды. Садри Ахунның тууына 120 ел тулуга багышланган әлеге чара скульпторлар, рәссамнар, сәнгать белгечләре, дизайнерлар, архитекторлар, уку йортлары укытучылары, аспирантлар катнашында узды.

**2023 елның 21 февралендә**, Халыкара туган тел көнендә, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының йомгаклау чаралары кысаларында «Милли яңарышка юл күрсәтүчеләр» дип аталган түгәрәк өстәл узды. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Кече залында җыелган кунакларны һәм ТӘһСИ хезмәткәрләрен Фәннәр академиясе вице-президенты, академик, филология фәннәре докторы Дания Заһидуллина сәламләде һәм Халыкара туган тел көне белән котлады. Чарада катнашучыларга сәламләү сүзе белән шулай ук Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, Татарстан Республикасы халык язучысы, «Җыен» фонды идарәсе рәисе Разил Вәлиев, түгәрәк өстәлне алып баручы – әдәбият белеме бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов мөрәҗәгать итте.

Киң җәмәгатьчелек – язучылар, галимнәр, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашында узган бу чара Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан «Җыен» фонды белән берлектә «Шәхесләребез» сериясендә чыгарылган «Гали Чокрый», «Мәҗит Гафури» һәм «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясеннән Гали Рәхим һәм Галимҗан Шәрәф турындагы китапларны тәкъдим итүгә багышланган иде. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең яңа хезмәтләре белән чарада катнашучыларны Язма мирас үзәге мөдире, филология фәннәре кандидаты Илһам Гомәров, әдәбият белеме өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Айгөл Ганиева, текстология бүлеге фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Гөлназ Хөснетдинова һәм шул ук бүлек фәнни хезмәткәре Фәния

Фәйзуллина таныштырды. Түгәрәк өстәл эшендә шулай ук «Мәҗит Гафури – XXI гасыр» мәдәният фонды советы рәисе Люция Камаева (Уфа), Уфа шәһәре М. Гафури мемориаль музей-йорты мөдире, филология фәннәре кандидаты Гадилә Бүләкова, ТӘһСИнең әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Марсель Ибраһимов, Татарстан Республикасы халык шагыйре Рәдиф Гаташ, КФУ профессоры, филология фәннәре докторы Хатыйп Миңнегулов катнашты һәм чыгыш ясады.

**2023 елның 21 февралендә** Халыкара туган тел көнендә «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә сүз Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнгән электрон сүзлекләр турында барды. ТӘһСИдә эшләнгән «Сүзлекләрнең электрон фонды» (http://suzlek.antat.ru/index.php) һәм «Татарстан Республикасы топонимнары каталогы» (https://toponym.antat.ru) электрон проектлары турында Институтның лексикография бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты Сәфәров Ринат Таһир улы һәм гомуми лингвистика бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Мирхәев Рифат Фирдинат улы сөйләде.

**2023 елның 21 февралендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары, филология фәннәре докторы Олег Хисамов, Россия Фәннәр академиясе Тел белеме институтында эшләп килүче Дискуссия-аналитика клубының онлайн-утырышында катнашып, доклад белән чыгыш ясады. Аның чыгышы Себер татарлары диалекты формалашу үзенчәлекләренә һәм Көнбатыш Себердә яшәүче татар халкының җирле һәм гомуммилли үзтәңгәллегенә багышланды. Онлайн-утырыш Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор Андрей Кибрик җитәкчелегендә узды.

Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институтында Тел сәясәте буенча дискуссия-аналитика клубы 2020 елда оештырылды. Аның айга бер тапкыр үткәрелә торган утырышларында тел сәясәтенең төрле мәсьәләләре карала; клуб эшенә катнашырга теләүчеләр белән беррәттән, башкарма һәм закон чыгару хакимияте органнары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре һәм башка өлкә белгечләре дә чакырыла. Клубның бурычлары – тел өлкәсендә көннән-көн актуальләшә барган сораулар буенча системалы, фәнни нигезләнгән һәм гамәли яктан мөһим карарлар чыгару.

**2023 елның 21 февралендә** Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Төрки лингвокультурология: проблемалар һәм перспективалар» халыкара конференциясе үткәрелде. Конференциядә Үзбәкстан, Төркия, Кытай, Казакъстаннан, шулай ук Саха Якутия, Таулы Алтай, Дагстан республикаларыннан һәм Татарстанның төрле оешмаларыннан 170 тән артык яшь тикшеренүче катнашты. Чарада катнашучыларга Г. Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт

яшь тамашачы театры бинасында Минзәлә татар дәүләт драма театрының З. Бигиев әсәре буенча куелган «Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә» спектакле тәкъдим ителде.

**2023 елның 22 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре татар әдәбияты классигы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тууына 145 ел тулуга багышланган массакүләм мәгълүмат чараларында катнашты. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты, филология фәннәре докторы, академик Дания Заһидуллина, ТӘһСИнең Язма мирас үзәге мөдире, филология фәннәре кандидаты Илһам Гомәров һәм текстология бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты Эльмера Галимҗанова чыгыш ясады. Чара барышында шулай ук Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Гаяз Исхакыйның тууына 145 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли семинар һәм бу нисбәттән басмага яңа китаплар әзерләнү турында игълан ителде.

**2023 елның 22 февралендә** «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты чыгарган «Татары Западного Приуралья в материалах государственных переписей населения 1795–1859 гг. Т. 1. Мензелинский уезд» (Казань, 2022) басмасы тәкъдим ителде. Белешмәлек Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты Идел буе һәм Урал алды тарихы бүлеге хезмәткәрләре: бүлек җитәкчесе, тарих фәннәре докторы Р.Р. Исхаков, өлкән фәнни хезмәткәр, тарих фәннәре кандидаты И.Җ. Фәйзрахманов һәм фәнни хезмәткәр Х.З. Баһаветдинова тарафыннан әзерләнгән. Әлеге хезмәттә Минзәлә өязенең 1795–1859 елларга караган V–X ревизия материаллары буенча статистика материаллары һәм яңа өстәмә тарихи документлар урын алган. Белешмәлек төбәктә яшәүче татар халкы санындагы үзгәрешләрне, сословие һәм дини составын, торак пунктларның урнашу структурасын ачыкларга ярдәм итә.

**2023 елның 25 февралендә** «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты тарафыннан «Көнбатыш Урал буе татарлары. Минзәлә өязе» китабы тәкъдим ителде. Басма Минзәлә өязе буенча 1795–1859 еллардагы җанисәп материалларын үз эченә ала. Китапта бирелгән материаллар архив чыганакларына нигезләнә. Басмада Минзәлә өязенә кергән дүрт йөздән артык татар авылы хакында мәгълүмат бирелә. Китап нәсел шәҗәрәсен тикшерүчеләр, авыллар тарихын язучылар өчен төп чыганак булып хезмәт итәргә мөмкин.

**2023 елның 26 февралендә** Татар китабы йортында яшь прозаикларга һәм тәрҗемәчеләргә Шәриф Камалның әдәби премиясен тапшыру тантанасы оештырылды. «Проза» номинациясендә – Светлана Мөхәммәдиева, Гөлназ Әхмәдиева, «Сәнгати тәрҗемә»

номинациясендә, Шәриф Камалның «Ата» әсәрен тәрҗемә иткән өчен, Марат Гыйльметдинов һәм Ралия Зәйнуллина җиңү яулады. Г. Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры булдырган махсус премиягә Ильяс Хаҗиев лаек булды. Традиция буенча, яңа лауреатлар легендар язучы каләме белән аның язма өстәле артында истәлекләр китабына үз тәэсирләрен язып калдырдылар.

Шәриф Камал декадасының белем бирү һәм мәдәни чаралар циклы кысаларында язучы иҗаты турында дискуссияләр, танылган галимнәрнең лекцияләре, Байгильдиевлар нәселе вәкилләре белән гаилә очрашуы үткәрелде.

**2023 елның 28 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясендә Казакъстанның танылган җәмәгать эшлеклесе, М. Ауэзов исемендәге Фонд президенты, галим һәм мәдәният эшлеклесе Морат Мохтар улы Ауэзов җитәкчелегендәге Казакъстан делегациясе белән очрашу оештырылды. Делегация составында шулай ук Казакъстан Республикасының Казандагы Генераль консулы Исхаков Ерлан Узан улы, «Фатыйма» фильмының сценарий авторы Жаныбаева Калдыгул Акимжан кызы, М. Ауэзов исемендәге институтның халыкара элемтәләр бүлеге җитәкчесе Ананьева Светлана Викторовна, Абай исемендәге университет укытучысы Бакбергенова Роза Кожабай кызы бар иде.

Делегацияне Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты М.Х. Саләхов, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты Д.Ф. Заһидуллина, ТР Язучылар берлеге җитәкчесе Р.Р. Зәйдуллин, ТР Язучылар берлеге әгъзалары, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчесе К.М. Миңнуллин һәм А.Х. Халиков исемендәге Археология институты җитәкчесе А.Г. Ситдыйков каршы алды. Алар академиянең төп эш юнәлешләре, аның фәнни һәм тышкы элемтәләре белән таныштырды. Очрашуда шулай ук үзара хезмәттәшлек перспективалары билгеләнде.

**2023 елның 1 мартында** Татарстан Милли китапханәсендә казакъ әдәбияты классигы Мохтар Ауэзовның татар телендәге китабы тәкъдим ителде. Чарада язучының улы Мурат Ауэзов катнашты.

Басмага язучының өч әсәре кергән: «Караш-Караш» (Выстрел на перевале / Үткәлдәге атыш) һәм «Коксерек» (Серый лютый / Күксирәк) повестьлары, «Килы заман» (Лихая година / Шомлы заман) хикәясе. Күренекле казакъ галиме, язучы, драматург Мохтар Омархан углы Ауэзовның тууына 125 ел тулу уңаеннан әдипнең әсәрләренең тәрҗемәсе Казакъстан Республикасы тышкы эшләр министрлыгының ярдәме һәм Казакъстан Республикасының Казан шәһәрендәге Генераль Консуллыгы инициативасы белән башкарылган. Тәрҗемәне КФУ доценты Гайнуллина Гөлфия Расил кызы башкарган.

**2023 елның 2 мартында** Башкортстанның Стәрлебаш районы Стәрлебаш авылында Башкортстан татарлары конгрессының урындагы төбәк бүлекчәсе җитәкчесе, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы, күптән түгел 70 яшен билгеләгән язучы Хисаметдин Исмәгыйлевнең иҗатына

багышланган чаралар узды. Башкортстан һәм Татарстан Язучылар берлеге җитәкчеләре Айгиз Баймөхәммәтов һәм Ркаил Зәйдулла, Казан, Уфа, Стәрлебаш районыннан язучылар һәм журналистлар катнашында түгәрәк өстәл оештырылдылды. Чит төбәкләрдән килгән кунакларга район китапханәсенә һәм урындагы музейга экскурсияләр оештырылды, район мәдәният йортында «Әйтер сүзем бар» дигән әдәби-музыкаль кичә узды. Тантанада Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, халык шагыйрьләре Марсель Галиев, Газинур Морат, «Казан утлары» журналы баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, проза бүлеге мөхәрире Рафис Корбан, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Айгиз Баймөхәммәтов, Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар язучылары – Руслан Сөләйманов, Дилбәр Булатова, Илдус Фазлетдинов, Мөнир Вафин һ.б. катнашты.

**2023 елның 6 мартында** Казанда Россия мөселманнары Диния нәзарәтенең мәдәният департаменты һәм «Читай» нәшрияты тарафыннан «Кострома татарлары» китабын тәкъдим итү кичәсе үткәрелде. Китап Идел буе Болгар халыклары тарафыннан Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итү кысаларында нәшер ителде, ул татар тарихына багышланган этнографик эшләр циклының дәвамы булып тора.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе бинасында Татарстанның фән, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре катнашында узган чарада тарихчы, Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәтенең мәдәният департаменты җитәкчесе Ренат Абянов, тарихчы, журналист Марат Сәфәров, Бөтендөнья татар конгрессының туган якны өйрәнүчеләр белән эшләү комитеты башлыгы Альберт Борһанов, этнограф, тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков һ.б. чыгыш ясады. Күргәзмәдә Костроманың үзенчәлекле өлеше – Идел ярында урнашкан Татар бистәсе, аның стиле, яшәеше, рус һәм татар халкының уртак тормышы турындагы экспозицияләр тәкъдим ителде.

**2023 елның 7 мартында** «Казан Кремле» музей-тыюлыгының «Манеж» күргәзмәләр залында «Чаян» сатирик журналының 100 еллыгына багышланган күргәзмә ачылды. Экспозициядә журналның 1920–1930 елларда һәм 1941 елда чыккан саннары, шулай ук төрле елларда редакция коллективы һәм «Чаян» рәссамнары белән архив фотолары тәкъдим ителде. Күргәзмәдә шулай ук XX–XXI гасыр рәссамнары – Эрнст Гельмс, Иосиф Бобровицкий, Эрнст Дышаев, Борис Старчиков, Илдар Әхмәдиев һәм башкаларның эшләре урын алган.

«Чаян» журналының беренче саны 1923 елның гыйнварында дөнья күрә. Ул Бөек Ватан сугышы чорында гына чыгудан туктап тора. 1957 елдан журнал татар һәм рус телләрендә бастырыла башлый.

**2023 елның 10 мартында** Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең китап, язучылар, шагыйрьләр, әдәби жанрлар һәм вакыйгалар турында фикер алышу мәйданчыгы булган «Әдәби резиденция» проекты кысаларында «Дастан: сәнгатькәрләр әдәбиятны ничек күзаллый?» дип аталган чара узды. Чарада әдәбият белгеч-

ләре, фольклорчылар, язучылар, тарихчылар, театр эшлеклеләре катнашты. Очрашуда татар дастаннары, бу жанрның төп үзенчәлекләре, «Идегәй» дастанының вариантлары, аның нугай, кыргыз, казакъ дастаннарыннан аермалары һ.б. турында сүз барды.

Әңгәмәдә филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре Л.Х. Мөхәммәтҗанова, тарих фәннәре докторы, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре И.Л. Измайлов, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры театрының баш режиссеры Т.Р. Имаметдинов һ.б. катнашты.

Л.Х. Мөхәммәтҗанова үзенең чыгышында татар дастаннарының фольклор һәм әдәби жанрлар системасындагы урыны һәм роле, аларның үзенчәлекләре, татар китаби дастанының тирән традицияле булуы, милли тарихи-мәдәни процесс белән дастаннар арасындагы бәйләнеш турында сөйләде, төрки һәм татар дастаннарының төрләрен тасвирлап, татарларның эпик иҗаты үрнәкләреннән мисаллар китерде, бүгенге җәмгыятьтә жанр трансформациясе процессларын анализлады.

**2023 елның 14 мартында** «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында «Татар әдәбияты тарихы»ның 1–2 томнарының икенче басмасын тәкъдим итү чарасы узды.

Матбугат конференциясендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты, филология фәннәре докторы Дания Заһидуллина, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы Ким Миңнуллин, институтның әдәбият белеме бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов һәм Язма мирас үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре докторы Гамирҗан Дәүләтшин катнашты.

**2023 елның 14 мартында** Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Идел буе Болгары: этномәдәни һәм сәяси үсеш мәсьәләләре» темасына фәнни семинар үтте. Семинар кысаларында И.Л. Измайловның 2022 елда дөнья күргән «Урта гасыр Болгары» (Измайлов И.Л. Средневековые булгары: становление этнополитической общности в VIII – первой трети XIII века. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2022. 736 с.; 16 с. ил.) һәм «Төрки шәһәр цивилизациясе. Теория һәм тарихтан очерклар» исемле монографияләре тәкъдим ителде. Семинар Татарстан Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының М. Госманов исемендәге Алтын Урданы һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге тарафыннан оештырылды.

**2023 елның 15 мартыннан** Казанда XI Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыены үтте. Җыенда Россиянең 47 төбәгеннән алты йөзләп татар эшмәкәре җыелды. Җыенның өченче көнендә Бөтендөнья татар конгрессы белән Татарстан сәүдә

һәм сәнәгать палатасының уртак «Бизнес берләштерә» проекты тормышка ашырылды. Проектта сигез секция буенча утырышлар узды.

Чара программасы Татарстанда органик авыл хуҗалыгын үстерү ориентирларына багышланган иде һәм барлык катнашучыларда, белгечләр, кече бизнес вәкилләре, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре, фәнни хезмәткәрләр, югары уку йортлары укытучылары һәм студентларда зур кызыксыну уятты. Татар эшмәкәрләре үсемлекчелек, терлекчелек, авыл хуҗалыгы техникасы, авыл хуҗалыгы продукциясен саклау һәм эшкәртү, агрохолдинг һәм агрожитештерү, авыл хуҗалыгында төзелеш, агросәнәгать хезмәтләре, агросәнәгатьттә цифрлы технологияләр юнәлешләре буенча секцияләрдә катнашты.

**2023 елның 15 мартында** Казанда «Ярдәм-Помощь» фонды бинасында Брайль шрифты белән бастырылган Коръән тәфсире һәм «Гыйбадәте исламия» китабы тәкъдим ителде. Әлеге басмалар күрмәүчеләр өчен махсус шрифт белән беренче тапкыр нәшер ителә. Татарстан мөфтиенең социаль мәсьәләләр буенча киңәшчесе, «Ярдәм» гомуммилли ислам хәйрия фонды советы рәисе Илдар хәзрәт Баязитов китапларның түләүсез таратылуын хәбәр итте.

**2023 елның 17 мартында** Габдулла Тукайның Казандагы әдәби музеенда татар язучысы, драматург, шагыйрь, публицист һәм әдәбият тәнкыйтьчесе Әхмәт Фәйзинең тууына 120 ел тулуга багышланган «Тукай хәятына чумып…» дип исемләнгән әдәбимузыкаль кичә оештырылды. Чарада галимнәр, сәнгать әһелләре, студентлар һәм татар мәдәнияте белән кызыксынучылар катнашты.

**2023 елның 28 мартында** Казан шәһәренең «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә III Халыкара нәфис сүз телевизион бәйгесенә йомгак ясалды. Бәйге Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән берлектә «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе тарафыннан оештырылды. Конкурста Татарстанның барлык районнарыннан, Россиянең башка төбәкләреннән, Казакъстан, Белоруссия, Төркиядән 3200 кеше катнашты, шуларның утызы җиңүче исеменә лаек булды.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2023. № 1

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 31.03.2023. Басылды: 18.04.2023.
Офсет кәгазе. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 12. Тираж 300 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшриятында басылды
(нәшрият адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал бушлай таратыла